1°2018

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә.* Диаспора сөйләмендә һәм әдәби телдә фигыль тәңгәллеге . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Сабитова И.И.* Татар сүзьясалышы өлкәсендәге кайбер төшенчәләр турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14

*Булатова Ә.К.* Хәзерге татар телендә семантик деривация күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19

*Таһирова Ф.И.* Сүз чикләрен билгеләү мәсьәләсе *(катлаулы конструкцияләрне сүзлектә вокабула итеп бирү яссылыгыннан)* . . 23

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Миңнуллин К.М.* Төрки телле язучылар милли традицияләр сагында: Мохтар Ауэзов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

*Ганиева А.Ф.* Фатих Хөсни прозасы: жанр табигате һәм милли үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34

*Надыршина Л.Р.* Әхсән Баянов шигъриятендә төп темалар һәм мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

*Чекич Абдулкадир.* Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә мәдәни гегемония темасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

*Насибуллова Г.Р.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар хикәяләрендә әдәби мотивларның чагылышы . . . . . . . . . . . 55

*Юсупова Н.М.* 2017 елда татар шигърияте: стиль тенденцияләре һәм жанрлар үсеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙГА – 140

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар язма әдәби теле нәзарияте: Гаяз Исхакый әсәрләре телен өйрәнү мәсьәләсенә карата . . . . . 77

*Харрасова Р.Ф.* «Ике йөз елдан соң инкыйраз»га бүгенге хәлебездән күз ташлау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

*Мөхәммәтшин З.Г.* Гаяз Исхакыйның әлифба алмаштыруга мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Ямалтдинов И.И.* «Фольклор» терминын фәнни әйләнешкә кертү тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Шәкүрова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Г. Сәгъдинең методик мирасы . 104

*Шәйдуллин Р.В.* Татарстан халыклары тарихы һәм мәдәнияте турында универсаль фәнни-методик комплекс . . . . . . . . . . 115

*Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В.* Федераль дәүләт белем бирү стандартлары: башлангыч мәктәптә комплексы эшләр . . . . . . 119
*Хаббанов И.И.* Телгә өйрәтүдә өстәл уеннарының роле . . . . . 124

## СӘНГАТЬ

*Солтанова Р.Р.* Галиәсгар Камалның «Банкрот»ы: заман рухындагы комедия-фарс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
*Шкляева Л.М.* Чүкеп нәкышьләү остасы Александр Иванов иҗатында сәнгати образларның үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . 133

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Асыл тамырларны барлаганда... *(фольклорчы галим Х. Мәхмүтовка – 85 яшь)* . . . . . . . . . . 137

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Исхакый Гаяз.* Япониядән китеп барышлый *(әдип көндәлегеннән)* . 141
*Фәтхи Альберт.* Габделҗәббар Кандалый шигырьләре җыентыгы . 149

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Бәширова И.Б.* Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа (Ф.К. Сагдеева, Д.Р. Гайнанова) . 171
*Булатова М.Р.* Татар тарихи лексикологиясенә материаллар (Д.Б. Рамазанова) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Юсупова А.Ш., Набиуллина Г.А.* Идентичность глагольных форм в татарском литературном языке и в речи диаспоры . . . . . . . . . 7
*Сабитова И.И.* О некоторых понятиях в татарском словообразовании 15
*Булатова А.К.* Семантическая деривация как процесс в современном татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Тагирова Ф.И.* Проблемы определения границ слова *(с точки зрения отбора сложных конструкций в качестве вокабулы в словарях)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Миннуллин К.М.* Тюркоязычные писатели на страже национальных традиций: Мухтар Ауэзов . . . . . . . . . . . 28
*Ганиева А.Ф.* Проза Фатиха Хусни: природа жанра и национальное своеобразие . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
*Надыршина Л.Р.* Основные темы и мотивы в поэзии Ахсана Баяна . 42
*Чекич Абдулкадир.* Тема культурной гегемонии в произведениях Аяза Гилязова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
*Насибуллова Г.Р.* Отражение литературных мотивов в татарских рассказах конца XX – начала XXI века . . . . . . . 55
*Юсупова Н.М.* Татарская поэзия в 2017 году: тенденции стиля и развитие жанров . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66

## ГАЯЗУ ИСХАКИ – 140

*Баширова И.Б.* Теория тюрко-татарского письменного литературного языка: о вопросах изучения языка произведений Гаяза Исхаки . . 77
*Харрасова Р.Ф.* Современный взгляд на «Исчезновение через двести лет» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
*Мухаметшин З.Г.* Отношение Гаяза Исхаки к смене алфавита . . . 92

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Ямалтдинов И.И.* Из истории введения в научный оборот термина «фольклор» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Методическое наследие Г. Сагди . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
*Шайдуллин Р.В.* Универсальный научно-методический комплекс по истории и культуре народов Татарстана . . . . . . . . . . 115
*Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В.* Федеральные государственные образовательные стандарты: комплексные работы в начальной школе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

*Хаббанов И.И.* Роль настольных игр в обучении языку . . . . . . 124

## ИСКУССТВО

*Султанова Р.Р.* «Банкрот» Галиасгара Камала:
комедия-фарс в духе времени . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

*Шкляева Л.М.* Особенности художественных образов
в творчестве мастера чеканки Александра Иванова . . . . . . . . 133

## ПЕРСОНАЛИИ

*Мухаметзянова Л.Х.* Перебирая сокровища народной мудрости
*(фольклористу Х.Ш. Махмутову – 85 лет)* . . . . . . . . . . . . . 137

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Исхаки Гаяз.* Покидая Японию *(из дневника писателя)* . . . . . . 141

*Фатхи Альберт.* Сборник стихов Габдельджаббара Кандалыя . . 149

## НОВЫЕ КНИГИ

*Баширова И.Б.* Татарский концепт как объект
лингвокультурологического анализа (Ф.К. Сагдеева, Д.Р. Гайнанова) . 171

*Булатова М.Р.* Татар тарихи лексикологиясенә материаллар
(Д.Б. Рамазанова) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***Ә.Ш. Юсупова,***
***Г.Ә. Нәбиуллина***

# ДИАСПОРА СӨЙЛӘМЕНДӘ ҺӘМ ӘДӘБИ ТЕЛДӘ ФИГЫЛЬ ТӘҢГӘЛЛЕГЕ

Статья посвящена изучению языковых особенностей татар, проживающих в Китайской Народной Республике. Изучены особенности употребления личных форм глаголов в речи татар Китая, в частности формы изъявительного наклонения, составляющих специфический пласт языка татарской диаспоры. Выявлена идентичность глагольных форм изъявительного наклонения с татарским литературным языком, а также с близкородственными казахским и уйгурским языками. Лингвистическое изучение поставленной проблемы дает возможность ввести в научный оборот новые данные о грамматических формах, проникших в речь представителей татарской диаспоры в Китае, в результате обоюдной межъязыковой и этнокультурной интеграции с местным населением.

**Ключевые слова:** татарская диаспора, татарский язык, литературный язык, язык татарской диаспоры, глагол, грамматические формы.

Татар халкының төрле сәбәпләр аркасында чит төбәкләргә күчеп китеп, яңа шартларда яши башлавы телнең үсешенә, яңа сөйләшләрнең барлыкка килүенә, һичшиксез, йогынты ясамый калмаган. Тел гыйлемендә җирле сөйләшләрне өйрәнеп язылган күренекле тел галимнәре, диалектологларның (А.Ш. Әфләтунов, Л.Җ. Җәләй, Г.Х. Әхәтов, Д.Г. Тумашева, Ф.Й. Йосыпов, Д.Б. Рамазанова, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Ф.С. Баязитова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.) хезмәтләрендә диалектларны, сөйләшләрне өйрәнүнең тел тарихы, милләтебезнең саклануы, үсеше өчен аеруча мөһим булуына басым ясала. Шунысы куанычлы: соңгы елларда, Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләре белән бергә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең телен өйрәнүгә дә җитди игътибар юнәлтелә башлады [Ахметова, 2004; Юсупова, 2014]. Бер яктан, туган илләреннән аерылып, башка җирләргә күчеп киткән кешеләр, үзләре белән шул чорның телен, аңа хас борынгы күренешләрен дә алып киткәннәр һәм бүгенге көндә дә бу тарихи үзенчәлекләрне саклап яшиләр. Икенче яктан, читтә яшәүче татарлар сөйләме чит телләр тәэсирендә берникадәр үсеш-үзгәреш кичергән. Нәтиҗәдә, башка иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни шартларда яшәгән халыкның сөйләшләрендә яңа күренешләр барлыкка килгән. Бу җәһәттән Кытайда яшәүче татар диаспорасының тел үзенчәлекләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия.

Кытайда яшәүче милләттәшләребезнең күп өлеше Синьцзян, Чанцзи-Хуэй автономияле округларында, Или һәм Чэн

районнарында яшиләр. 2000 нче елгы статистик мәгълүматларга караганда, Синьцзянда 5 меңгә якын татар исәпләнә. Шулай ук Пекин, Тяньцзин, Харбин, Чжэнчжоу, Голҗа, Урумчи һәм Чавучак кебек шәһәрләрдә татарлар яшәве билгеле. Меңнәрчә еллар дәвамында бу төбәккә төрле төрки халык вәкилләре килеп урнашкан һәм биредә үзләренең тарихи эзләрен калдырганнар. Татарлар бүгенге көндә аеруча уйгырлар һәм казахлар белән катнашып, аралашып яшиләр, уйгыр һәм казах язуын кулланалар [Китай – национальность татары]. Нәтиҗәдә, периферияддәге татарларның теле, узган гасырлар белән чагыштырганда, кытай теле чолганышында калып, уйгырлар һәм казахлар белән «тел, лөгать вә әхлак алмашу» тәэсирендә лексик-грамматик яктан күптөрле үсеш-үзгәреш кичергән [Госманов, 1996].

Безнең максат – татарларның әлеге диаспорасы сөйләмендә катлаулы сүз төркеменнән саналган фигыльләрне, төгәлрәге, күп төрле зат-сан, заман категорияләренең кулланылышы белән аерылып торган хикәя фигыльләрне, аларның төрләнешенә бәйле үзенчәлекләрне тикшерү һәм аларның татар әдәби телендәге формалар белән структур-семантик тәңгәллеген билгеләү.

Диаспора сөйләмендә хикәя фигыльләрнең заман формалары һәм зат-сан белән төрләнеше хәзерге әдәби телдән берникадәр аерылып тора. Татар грамматикаларында яшәп килгән традициягә нигезләнеп, өйрәнелә торган төбәктәге татарлар сөйләмендә кулланылган хикәя фигыльләр өч заманга берләштереп тикшерелде. Шунысын искәртеп узу кирәк: заманнарның парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре сөйләм эчендә, ягъни контекстка бәйле рәвештә төрле үзгәрешләр кичерергә мөмкин.

**Хәзерге заман.** Хәзерге заман хикәя фигыль әдәби телдәге кебек үк *-а/-ә, -ый/-и*, юклыкта *-мый/-ми* кушымчасы ялганып ясала. Мәгънәсе ягыннан хәзерге сөйләү моментындагы яисә даими башкарыла торган эш-хәлләрне белдереп килә. Мәсәлән, *Мәүлет айында да татар мәктәбендә уқучы шәкертләрне өйрәтеп, җырлатып **қаршы алалар**; Қазанға күп **барып тора** ул. Бөтен йуғарыдағылар белән әйбәт **аралаша**; Шул икәw утырып сөйләшеп утырғанда, ул да **әченә**, мин дә **әченәм**.*

Тикшерүләрдән күренгәнчә, I зат берлек санда параллель рәвештә аның тулы *-мын/-мен/-мән* һәм кыскартылган *-м* күрсәткечләре кулланыла. I зат күплектә зат мәгънәсе *-быз/-без* һәм *-мыз/-мез* кушымчалары ярдәмендә белдерелә: *оқуймын//оқуймән//оқыйм, оқуйбыз//оқуймыз, барам//барамын, барабыз// барамыз*. Мәсәлән, *Моллаларны, туғаннарны, күршеләремезне **чақырамыз**. Қоймақларны **пешерәмен,** чәлләкте дип әйтәләр; Шулар **тапшырамыз**, шулар үзләре хөкүмәткә барып, һәр йылны рөхсәт ала, фәләнче айның фәләнче йылы **үткәзәбез**, дип хәбәр куйа; Моллаларны, туғаннарны, күршеләремезне – шоларны чақырамыз.* Бу үзенчәлекне татар әдәби теленә һәм

аның сөйләшләренә мөнәсәбәттә караганда, уртаклыклар табарга мөмкин. Татар диалектологиясендә хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек сан күрсәткечләренең тулы һәм кыска вариантларын параллель куллану мишәр диалекты сөйләшләре өчен хас дигән фикер яшәп килә. Хәзерге татар телендә архаиклашкан *-мын/-мен/-мән; -мыз/-мез* кушымчалары XIX–XX гасыр әдәби телендә күзәтелә: *Үземез уйлап карармыз* (Ф. Халиди). Бу кушымчалар фольклор телендә сакланып калган: *Беләмен дип мактанма, синнән дә белгеч табылыр* (мәкаль).

Хәзерге заманның II зат берлек һәм күплек формалары әдәби телдәгечә *-сың/-сең/-сән; -сыз/-сез* кушымчалары белән белдерелә. Мәсәлән, *окуйсың, окуйсыз, барасең, барасыз, киләсең, киләсез* һ.б. ***Хәйрән ҡаласың*** *бит, ә?; Журналларға* ***чығасыз****, иң ахтыҡҡы теләгенә дә рөхсәт итмәсәгез, мин тағын керергә ризамын төрмәгә дип чығып киттем.* III зат берлек сан формасы хәзерге татар телендәге кебек нуль формада килә. Мәсәлән: *килә, бара, укый, эшли.* Сөйләмдә күплек сан формасы еш кына *-лар/-ләр* кушымчасыннан башка әйтелә.

Диаспора сөйләмендә III зат берлектә *-ты/-те* кушымчаларын куллану үзенчәлекле. Бу күренеш бигрәк тә җирле халык авыз иҗаты әсәрләре телендә сакланып калган: *Түрә ҡуштаннан көләте* (көлә), *көлсә дә ишек төбе бирәте* (бирә); *Ҡоры табаҡ аwыз йыртаты* (ерта). *Күз йәше җиргә тамса да кипмәйте* (кипми); *Йахшы ирнең сөйәге ҡәбердә черәйте* (чери), *исме йәшәрте* (яшәрә).

Хәзерге заман хикәя фигыльләргә III зат берлек санда *-ты/-ды* кушымчаларын өстәп әйтү күпчелек кыпчак телләренә – казах, ногай, каракалпак, карачай-балкар, үзбәк, чуваш телләренә хас [Юсупов, 2004, с. 304]. Бу җәһәттән Себер татарлары диалектында *-йды* формасының кулланылуы кызыклы [Тумашева, 1977, с. 134]. Иске татар телендә исә III затта *торур* ярдәмче фигыленнән кыскарган *-дыр/-дер* кушымчасы очрый. Бу күренеш татар әдәби телендә һәм аның кайбер диалектларында, шулай ук фольклор телендә хәзер дә күзәтелә.

Тикшерелә торган сөйләмдә хәзерге заман хикәя фигыльнең аналитик *-ып/-еп/-п йата* формасының киң кулланылуы үзенчәлекле. Бу форма дәвамлы эш-хәлләрне белдереп килә. Мәсәлән: *Шуның белән* ***йөреп йатам*** *инде; Татар мәктәбе* ***салынып йата****.*

Диаспора сөйләменең үзенчәлекле билгеләренең берсе итеп *-ваты* кушымчасының (юклыкта *-маваты*) кулланылуын билгеләп үтәргә кирәк. *-ваты* фигыль формасы бигрәк тә уйгырлар белән тыгыз аралашып яшәгән урыннарда киң таралган; мәгънәсе ягыннан даими, озак вакыт дәвам иткән, үтәлеше сөйләү моментына мөнәсәбәтле эш-хәлләрне белдереп килә. Тулы төрләнеш парадигмасын саклаган *-ваты* архаик кушымчасы өйрәнелә торган диаспора сөйләмендә үзенчәлекле урын тота. Кайбер галимнәр

фикеренчә, ул – эш-хәлләрнең дәвам итүен белдерә торган *-ып йата* кушымчалы аналитик фигыльнең кыскартылган варианты. Тарихи грамматикаларда, әлеге форма этимологик яктан *-а/-ә* хәл фигыле һәм *торур* ярдәмче фигыленә нигезләнеп ясалган аналитик фигыльләрдән килеп чыккан, дип аңлатыла. Борынгы язма истәлекләрдә *-а/-ә торур* архаик формасының кулланылышы, чыннан да, *-ваты* формасының үсеш-үзгәрешен күзалларга ярдәм итә. Хәзерге төрки телләрдә, аерым алганда, уйгыр, үзбәк, каракалпак, алтай телләрендә *-аты* формалы хәзерге заман хикәя фигыльнең кулланылуы билгеле [Баскаков, 2005, с. 274–277]. Галимнәр шулай ук Себер татарлары диалектында *-ади*, *-адыі, -ати* формаларының сакланып калуын күрсәтәләр [Тумашева, 1977]. Шул рәвешле, *-а торур>адур>ады> аты* кушымчаларыннан тарихи үсеш-үзгәреш кичергән *-ваты* формасы Кытайда яшәүче татар диаспорасы сөйләмендә дә сакланып калган. Мәсәлән: *Оглум университетта* ***оқуwатиду****; Мән заводта* ***ишләwатимән****; Сән институтта* ***оқуwатысән****.* Мисаллардан күренгәнчә, *-ваты* формалы хикәя фигыльләргә III затта *-ду* кушымчасы өстәп әйтү күзәтелә.

**Киләчәк заман** хикәя фигыль үзенең күпфункциялелеге, күпмәгънәлелеге һәм грамматик төрлелеге белән аерылып тора. Бу заман формалары *-ы/-и, -ыр/-ер; -ар/-әр/-йәр/-йар/-р*, *-макчы/-мәкчи* кушымчалары ярдәмендә ясала.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең билгесез заман формасы төрки телләрнең иң борынгы формаларыннан санала [Серебренников, Гаджиева, 1986, с. 159]. Ул барлыкта *-ыр/-ер; -ар/-әр/-йәр/-йар/-р*, юклыкта *-мас/-мәс* кушымчалары ялганып ясала. Мәсәлән: *киләрмән, кийәрсән, кийәрмез, килмәс, кимәс, йазмас.* Бу форма хәзерге татар телендәге кебек, киләчәктә булачак эш-хәлләрне белдерә, һәм үзендә катгыйлык төсмере булмау белән характерлана. Кайбер очракларда хәзерге заман мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин, шулай ук киләчәктә булачак эшне фараз кылу рәвешен дә белдереп килә.

Диаспора сөйләменә билгеле киләчәк заманда *-ачак/-әчәк* формасын куллану хас түгел диярлек. Булса да, бик сирәк очрый һәм *-ачак/-әчәк, -йачак/-йәчәк, -аҗақ/-әҗәк* вариантларында кулланыла. Нигездә, катгый киләчәк заман мәгънәсе *-ы/-и, -а/-ә* хәзерге заман кушымчалары (юклыкта *-мый/-ми)* белән белдерелә. Мәсәлән: *Мин барымән. Син қайтысәң.*

Киләчәк заманның төрләнешендә зат күрсәткечләренең тулы (*-мын/-мен*) һәм кыскартылган (*-ым/-ем*) вариантлары икесе дә очрый. Нигезе *-р* авазына тәмамланган очракларда I һәм II затларда бер *-р* авазының кыскаруы күзәтелә: *барымән, барысәң.*

Сөйләмдә киләчәк заманга мөнәсәбәтле *-макчы/-мәкчи/-мәкче* формалы фигыльләр киң кулланыла. Бу форма эш-хәлнең башкарылу алдында торуын, максатын белдереп килә: *Мин*

*өйгә қайтмақчимән. Син бармақчисың. Син ни демәкчисәң?*

**Үткән заман.** Үткән заман хикәя фигыль формалары күптөрле һәм төрле мәгънә төсмерләре белдерәләр.

**Билгеле үткән заман** хикәя фигыль *-ды/-ди/-ду/-дү, -ты/-ти/-ту/-тү* вариантларында кулланыла, юклык формасы *-мады/-мәде, -маду/-мәдү* кушымчасы ярдәмендә ясала. Мәсәлән: *болдум, йолуқмади, алди, кәтти, күтмиди, ултурдуқ*. Төп мәгънәсе буенча тәмамланган, сөйләүченең күз алдында булган эш-хәлләрне белдереп килә: *Бөтенләй гәфләттә йатқан милләтне **уйатту.** Ә татарлар менә шу*ны ***үзгәртту;*** *Сезләр кичә **ашадыңызмы** қызыл чылан?*

Билгеле үткән заман хикәя фигыль кыска зат кушымчалары белән төрләнә. II зат күплектә, гадәттә, *-ңыз/-ңез* варианты кулланыла, хәзерге әдәби телдәге *-гыз/-гез* варианты да күзәтелә. Уйгыр теле тәэсирендә *-лар/-ләр* кушымчасы өстәп әйтү үзенчәлекле: *алдыңызлар // алдиңлар, киттеңезләр // киттиңләр*. Тел тарихына мөнәсәбәттә караганда, бу архаик күренешнең борынгы татар әдәби телендә дә сакланып калуы билгеле.

Диаспора сөйләмендә категорик үткән заман, әдәби телдән аермалы буларак, *-ган/гән* кушымчасы белән белдерелергә дә мөмкин. Бу форма еш кына зат-сан кушымчаларыннан башка кулланыла. Мәсәлән: *Сез Қытайдан қайчан **қайтқан** (кайттыгыз)?; Без кичә театрга **барған** (бардык); Татар кешесе дип қысқа ғына бер миқәлә йаздым, шуны **йазып үткәнем** (язып үттем), үзем дә хәйрән булдым.*

**Тәмамланмаган үткән заман** *-а/-ә, -ый/-и* кушымчасы һәм *иде* ярдәмче фигыле ярдәмендә белдерелә. Кайбер очракларда *-ар/-әр* кушымчалары да ялгана: *кәлә идим – келир идим, бара иди – барыр иди*. Ярдәмче фигыль, гадәттә, төп фигыльгә кушылып әйтелә һәм фонетик үзгәрешләр кичерә: *кәлә идим – кәләттем, бара иди – баратти, оқуй идик – окаттуқ* һ.б.

*Иде* ярдәмче фигыле урынына еш кына *икән* сүзе кулланыла. Кайсы формада килүенә карап, мәгънә төсмерләре дә берникадәр аерыла: *иде* ярдәмендә үткәндә булган эшнең сөйләүчегә билгеле булуы белдерелә, *икән* эш-хәрәкәтнең сөйләүчегә элек мәгълүм булмавын күрсәтә. *Икән* ярдәмче фигыленең башка заман формаларында да өстәлеп әйтелүе диаспора сөйләменең грамматик үзенчәлекләреннән санала: *бара икән, барған икән, барды икән, барыр икән* һ.б.

**Нәтиҗәле үткән заман** әдәби телдәге кебек *-ған/-гән, -қан/-кән* кушымчалары ярдәмендә белдерелә: *күргән, болған, әйткән.* Мәгънәсе ягыннан үтәлгән эшнең нәтиҗәсен белдерә. Шунысы үзенчәлекле: еш кына *икән* ярдәмче фигыле өстәлеп әйтелә. Мәсәлән: *Йамғур күп **булған икән,** клиткәнең эчендә су күп, су күп **булған икән;** Инде төн булған wақытта, **суыта башлаған икән.***

Диаспора сөйләмендә нәтиҗәле үткән заман формасын зат-сан кушымчаларыннан башка да куллану киң таралган: *барған//*

*барганмын, барган//баргансың, барган//барганбыз, барган//баргансыз.* Мәсәлән: *Утуз бешенче йыл дөнйага **килгән**, **туганмын** утуз бешенче йылда.*

Моннан тыш, сөйләмдә нәтиҗәле үткән заманда зат-сан кушымчалары белән төрләнгән *-ып/-еп/-п/-уп/-үп* кушымчалы хәл фигыль формасының кулланылуы үзенчәлекле: *барыпмын, барыпсың*. Юклык формасында – *бармапмын, бармапсың*. Тикшерү барышында диаспораның үз җирлегендә формалашкан *-ыпты* формасы теркәлде, ул, мәгънәсе белән, нәтиҗәле үткән заманны белдереп килә. Мәсәлән: *Сораган күп **белепту**, сорамаган артта **калыпту**; Ул егет бер чақ ултыргач палтасы белән йиәрне (җирне) қазыган икән, бердән палтасы бер тумурдәк нәрсәгә тигепте. Бу йәгет йамны (чоқыр) қазыган икән, йамда тотқычы бар, бер тумар қапқа күренепте. Йәгет тумар қапқаны ачса, эчкә лық бал тутырылган амбар икән; Бу йәгет шуннан башлап утынчылық қылмый, бал сатип көн итепте; Ахырда синең балаларың һарақны эчкән саен эчкәсе килеп, башқача башқарыла алмаган хәлгә җитеп, пақсыз җирләрдә әwәрәләнеп, нәқ чушақ холқын алып аwараланды – дип җаwап бирепте* (халык авыз иҗаты).

Төрки телләр яссылыгында караганда, *-ыпты/-ыпту* формалы фигыльнең уйгыр, казах, үзбәк телләрендә кулланылуы билгеле. Хәл фигыльнең диаспора сөйләмендә күзәтелгән әлеге үзенчәлеге татар әдәби теле һәм аның сөйләшләренә мөнәсәбәттә дә кызыклы. Диалектологлар фикеренчә, *-псың/-пты/-пте* кушымчалары Себер татарлары диалектында субъектив заман формасы ясый. Субъектив үткән заманның мондый формасы казах, үзбәк, азәрбайҗан, карачай-балкар һәм башка хәзерге төрки телләрдә, диалектларда очрый [Тумашева, 1977, с. 99]. Бу күренеш татар мәкальләрендә дә сакланып калган: *Ике хатын **алыпсың**, бер бәләгә **қалыпсың**.*

**Күптән үткән заман** хикәя фигыль, хәзерге татар әдәби телендәге кебек, *-гән/-ган, -кән/-кан иде* формасы белән белдерелә: *әйткән иде, барган иде, кәлгән иде, қайтқан иде, киткән иде.* Күптән үткән заман тәгәлләнгән, шул ук вакытта сөйләү моменты белән бәйләнешле эш-хәлләрне белдереп, кыска төр зат-сан кушымчаларын алып төрләнә.

Аңлашылганча, Кытайда яшәүче татарлар сөйләшендә хикәя фигыльнең күптөрле заман формалары кулланыла: хәзерге заман, билгеле киләчәк заман, билгесез киләчәк заман, билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман, күптән үткән заман, тәмамланмаган үткән заман.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, Кытайда яшәүче милләттәшләребезнең теле үзенең эчке ресурслары исәбенә, шул ук вакытта башка төрки телләр белән үзара бәйләнеш һәм йогынты ясау процессында берникадәр үзгәреш кичергән. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, периферияләге татар сөйләше казахлар, уйгырларның тел күренешләре белән үзара бер-

ләшкәннәр. Шулай итеп, борынгы чорларга барып тоташкан тарихи бергәлек берничә гасырлар буе дәвам итеп килә. Шуңа күрә әлеге юнәлештә фәнни эзләнүләр алып бару зур әһәмияткә ия.

### Әдәбият

*Ахметова Я.М.* Говор татар Финляндии: в сравнительно-историческом аспекте: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 182 с.

*Баскаков Н.А.* Выражение глагольных категорий вида и залога в морфологической структуре слова в тюркских языках // Типология грамматических категорий. М.: КомКнига, 2005. С. 156–170.

*Госманов М.* Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 206 б.

*Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе. Казан: Фикер, 2000. 287 б.

Китай – национальность татары // china.kulichki.net/figures/nationality/038shtml.

*Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З.* Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. М.: Наука, 1986.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка: категория глагола. Казань: Фэн, 2004. 592 с.

*Юсупова А.Ш., Нәбиуллина Г.А., Мөгътәсимова Г.Р., Денмөхәммәтова Э.Н., Фәтхуллова К.С., Җәүһәрова Ф.Х., Батталова А.Д.* Кытайда яшәүче татарлар: тел һәм фольклор. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 2014. 344 б.

***Юсупова Әлфия Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы профессоры, Г. Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе мөдире*

***Нәбиуллина Гүзәл Әмир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145’373

***И.И. Сабитова***

# ТАТАР СҮЗЬЯСАЛЫШЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ КАЙБЕР ТӨШЕНЧӘЛӘР ТУРЫНДА

В статье рассматриваются такие понятия татарского словообразования, как объём (лексический объём), глубина, ширина, валентность словообразовательного гнезда. Лексический объём гнезда выявляет словообразовательный потенциал слова. Понятие глубина словообразовательного гнезда обозначает максимальное число словообразовательных ступеней. Ширина словообразовательного гнезда показывает число производных слов, образованных от исходного слова на первой ступени. Термин валентность гнезда выявляет возможность образования новых слов, относящихся к разным частям речи. На основе анализа словообразовательных гнёзд, образованных от соматических терминов, установлены элементы построения математической модели гнезда.

**Ключевые слова:** татарское словообразование, словообразовательное гнездо, лексический объём, глубина, ширина, валентность словообразовательного гнезда.

Егерменче гасырның 90 нчы елларында татар сүзьясалышының аерым тел белеме тармагы булуы һәм аны мөстәкыйль өйрәнү кирәклеге дәлилләнде. 1993 елда басылып чыккан Татар грамматикасында «Сүзьясалышы» аерым бүлек итеп бирелә. Әлеге хезмәттә, нигездә, сүзьясалыш ысуллары карала [Татарская грамматика, 1993, с. 188–521]. Алга таба татар тел белемендә сүзьясалышы оясы төшенчәсе, аның билгеләмәсе, сүзьясалышы ояларының төрләре һәм аларның төзелеше җентекле өйрәнү объектына әйләнә. Мәсәлән, И.И. Сабитованың 2002 елда басылып чыккан «Словообразовательная характеристика лексики татарского языка: компьютерно-лингвографический аспект» хезмәтендә сүзьясалыш оясы, пары, чылбыры, баскычы, парадигмаларына күзәтү ясала [Сабитова, 2002, с. 72–75]. Э.Й. Хәйруллина диссертациясендә әлеге төшенчәләр сыйфатларга мөнәсәбәтле рәвештә өйрәнелә [Хайруллина, 2006, с. 97–101]. Ф.М. Хисамова тарафыннан язылган «Татар теле морфологиясе» китабының сүзьясалышына караган бүлегендә сүзьясалыш структурасы, тибы, калыбы, оясы, чылбырына анализ бирелә [Хисамова, 2006, б. 34]. Әлеге хезмәттә «Сүзьясалышы» элеккеге традиция буенча морфология кысаларында карала. «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басылган «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»ндә сүзьясалышына караган 20 ләп термин урын алды, мисал итеп сүзьясалыш оялары, пары, омонимиясе,

синонимиясе һ.б.ны күрсәтергә мөмкин [Русско-татарский..., с. 159–161].

Соңгы елларда сүзьясалыш ояларын өйрәнүдә математик алымнар да киң кулланыла башлады. Моның сәбәбен П.Н. Денисов фәннәр арасындагы традицион бәйләнешләрнең объектив рәвештә үзгәрүе белән аңлата. Ул болай дип билгеләп үтә: «Математика алымнары лингвистикага өр-яңа проблемалар алып килде, алар күп кенә элеккеге мәсьәләләргә яңача якын килүне таләп итәләр һәм лингвистик фикерләүнең үзен дә үзгәртәләр» [Денисов, 1963, с. 3].

Әлеге мәкаләдә татар сүзьясалышы өлкәсендә сүзьясалышы ояларын өйрәнүгә бәйле рәвештә күләм, тирәнлек, киңлек, валентлык кебек төшенчәләргә кыскача анализ бирелә. Мисаллар күрсәтеп узган Программа кысаларында нәшер ителгән «Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: „кеше” тематик төркеменә караган лексика» сүзлегеннән алынды [Сабитова, 2015].

Беренче төшенчә – *сүзьясалыш оясының күләме* яки *лексик күләме* (баш сүз белән бергә ояга кергән лексик берәмлекләр саны). Анализ өчен **баш** оясын алыйк. Ояны 336 га якын лексик берәмлек тәшкил итә, шулай булгач ояның лексик күләме 336 га тигез була. **Аяк** оясында 180 ясалма сүз бар, димәк ояның лексик күләме 180 гә тигез. **Күз** оясының лексик күләме 160 ка, **колак** оясының – 44 кә, **борын** оясының – 56 га тигез һ.б.

Ояның лексик берәмлеге сүзнең сүз ясау потенциалын күрсәтә. **Баш** оясына күз салсак, анда, кушымчалап ясалган сүзләр белән беррәттән, күпсанлы кушма сүзләр ясалганын күрәбез. Алар арасында үсемлек атамалары (*акбаш, вакбаш, карабаш, катыбаш, наратбаш* һ.б.), зоология терминнары (*дөябаш, җизбаш, йомрыбаш, китбаш, ташбаш* һ.б.), тән әгъзалары атамалары (*кулбаш, иңбаш, янбаш, оча башы, баш капкачы, баш бармагы* һ.б.) да бар. Бу күренеш татар теленең аналитик тел икәненә ачык дәлил булып тора.

Икенче төшенчә – *сүзьясалыш оясы.* Мисалга **яңак** оясын алыйк. Әлеге ояда бары бер сүзьяслыш баскычы бар. Шуңа да бу ояның тирәнлеге 1 гә тигез:

**ЯҢАК** *и. анат.*
  яңак-**ла**(*у*) *ф.*
  яңак-**лы** *с.*
---
  яңак калкы-**м**-*ы и. анат.*
  яңак сөяг-е *и. анат.*
---
  1

**Сөяк** оясындагы ясалма сүзләр 2 сүзьясалыш баскычына урнашкан. Бу очракта ояның тирәнлеге 2 гә тигез:

**СӨЯК** *и. анат.*
  сөяк-**лән**(*ү*) *ф.*
  сөяк-**ләч** *с.*
    сөякләч-**лән**(*ү*) *ф.*
    сөякләч-**лек** *и.*
---
  1 2

**Тел** оясына ясаган анализ аның 3 сүзьясалыш баскычында урнашкан атамаларны үз эченә алганын күрсәтә. Бу очракта ояның тирәнлеге 3 кә тигез:

**ТЕЛ** *и. анат.*
---
тел-**ен**(*ү*) *ф.*
телен-**мә** *с.*
телен-**мәле** *с.*
---
1 2 3

4 сүзьясалыш баскычыннан торган оялар да бар. Мәсәлән, **күз** оясы. Аның тирәнлеге 4 кә тигез:

**КҮЗ** *и. анат.*
---
күз-**әт** *и.*
күзәт-**ү** *ф.*
күзәтү-**чән** *с.*
күзәтүчән-**лек** *и.*
---
1 2 3 4

Анализ татар телендә сүзьясалышы ояларының тирәнлеге күп очракта икегә тигез булуын күрсәтә.

Сүзлеккә керми калган тагын бер төшенчә – *сүзьясалыш оясының киңлеге* (баш сүздән ясалган ясалма сүзләр саны). Мисал итеп **йөрәк** оясын алыйк:

**ЙӨРӘК** *и. анат.*
йөрәк-**лән**(*ү*) *ф.*
йөрәк-**ләндер**(*ү*) *ф.*
йөрәк-**ле** *с.*
йөрәк-**сез** *с.*
йөрәк-**сен**(*ү*) *ф.*
йөрәк-**се**(*ү*) *ф.*
йөрәк-**сет**(*ү*) *ф.*
йөрәк-**чел** *с.*
---
йөрәк ут-*ы и. бот.*
1

Беренче баскычта баш сүздән 17 сүз ясалган, шуңа күрә ояның киңлеге 17 гә тигез була. **Бармак** оясының киңлеге – 19 га, бавыр оясының киңлеге – 9 га, **аяк** оясының киңлеге – 6 га, **бәбәк** оясының киңлеге – 4 кә, **бәвел** оясының киңлеге 3 кә тигез һ.б.

Теге яки бу сүз төркеменә караган сүзләр гомум категориаль мәгънәгә ия. О.М. Ким фикеренчә, категориаль мәгънә һәрбер аерым алынган сүзнең мәгънәсеннән киңрәк. Сүзнең семантик структурасында чагыштырмача мөстәкыйль булган гомум категориаль мәгънә сүзнең нинди сүз төркеменә караганын ачыклый [Ким, 1978. с. 15]. Мәсәлән, исемнәр предметлыкны белдерәләр. Предметлык төшенчәсе бу очракта затны, конкрет предметларны, күренеш һәм вакыйгаларны, һәртөрле абстракт төшенчәләрне, исемләшкән билге яки эш-хәлләрне белдерә. Фигыль – эш яки хәлнең үтәлү процессын, сыйфат – предмет билгесен, ә рәвеш эш-хәл билгесен яки билгенең билгесен белдерә.

*Сүзьясалыш оясының валентлыгы* сүзьясалыш оясының төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр ясау мөмкинлеген күрсәтә. Мисал өчен **арка** оясын алыйк. **Арка** оясындагы 19 ясалма сүз арасында исем, фигыль, сыйфат һәм рәвешләр бар:

**АРКА** *и. анат.*
арка-**даш** *и.*
аркадаш-**лы** *с.*
арка-**лан**(*у*) *ф.*
---
арка-**лаш** *рәв.*
---
1 2

**Арка** оясындагы 19 ясалма сүз арасында *аркадаш, аркалык*

(исем), *аркаландыру, аркалану, аркалау* (фигыль), *аркалаш, аркан* (рәвеш), *аркадашлы, аркадашсыз* (сыйфат) атамалары бар. Димәк, ояның валентлыгы дүрткә тигез. Ә **беләк** оясының валентлыгы икегә тигез, чөнки **беләк** оясына *беләкле* (сыйфат), *беләксә* (исем) сүзләре керә.

Сүзьясалыш оясының валентлыгын дүрт класска бүлеп карап була.

1) Бер валентлы оя – баш сүздән бары тик бер генә сүз төркеменә караган сүзләр ясауга сәләтле оя. Татар теле сүзьясалышында бер валентлылык күренеше күбесенчә алынмалардан ясалган ояларга хас һәм алар баш сүз белән бер яки ике генә ясалма сүздән торалар. Мәсәлән, **бронхиаль** оясында *бронхиаль биз* (исем) атамасы, **миң** оясында *миңле, миңсез* (сыйфат) сүзләре бар.

2) Ике валентлы оя – үз составында ике грамматик класска караган ясалма сүзләр булган оя. Мисалга **талак** оясын алыйк. **Талак** сүзеннән *талакдар, талак үләне* (исем), *талаклы, талаксыз* (сыйфат) сүзләре ясалган. **Оча** сүзе, үз чиратында, *очалы, очасыз* (сыйфат) һәм *оча сөяге* (исем) атамаларын ясый һ.б.

3) Өч валентлы оя – өч сүз төркеменә караган ясалма сүзләр ясарга сәләтле оя. Мәсәлән, **маңгай** оясында өч грамматик класска караган ясалма сүзләр бар: *маңгайча, маңгай сөяге* (исем), *маңгайга-маңгай* (рәвеш), *маңгайлы, маңгайчасыз* (сыйфат). **Тамак** оясында да өч сүз төркеменә караган атамалары бар: *тамакай, тамакса, тамаклык* (исем), *тамакайлану, тамаксау* (фигыль), *тамаклы, тамакчасыз* (сыйфат).

4) Дүрт валентлы оя – өчтән артык грамматик класска караган ясалма сүзләр булган оя. **Тел, баш, тубык** ояларына *телгеч, телем, телче* (исем), *телле, телсез, телдәр, телчән* (сыйфат), *телдән* (рәвеш), *телү, телләшү, телләнү, телчәнләнү* (фигыль); *башлам, башваткыч, башлык* (исем), *башлы, башсыз* (сыйфат), *баштан* (рәвеш), *башлау, башлану, башсызлану* (фигыль); *тубылдырык, тубык сөяге* (исем), *тубыксыз* (сыйфат), *тубыктан* (рәвеш), *тубыклану* (фигыль) кебек сүзләр керә.

Сүзьясалыш оясының күләмен, тирәнлеген, киңлеген, валентлылыгын ачыклаганнан соң, аның квантитатив формуласын төзергә мөмкин. Ул – оя структурасын сан ягыннан чагылдыра торган формула. Аның беренче саны – ояның валентлыгын, икенчесе – лексик күләмен, өченчесе ояның тирәнлеген күрсәтә. Ул сан алдагы дүртенче саннан кыек сызык белән аерыла. Формуланың дүртенче саны ояның киңлеген күрсәтә. Дефистан соң килә торган сан оядагы сүзьясалыш чылбырларының санын белдерә. Кыек сызыктан соң килгән сан оядагы сүзьясалыш парадигмалары санына тигез. Мәсәлән, **бавыр** оясының квантитатив формуласы **3.19.2/14 – 4/3** кә тигез. Монда 3 саны ояның валентлылыгын күрсәтә: *бавыргалык, бавырчы, бавыргөмбә* (исем), *бавыргалыклы, бавырлы* (сыйфат), *бавырлану* (рәвеш); 19 саны ояның лексик күләменә тигез: *бавыр ... бавырлану, бавырлы,*

*басырсак ... бавыр имгеч, бавыр мүге* һ.б., ягъни оя 19 лексик берәмлектән тора; 2 саны оядагы сүзьясалыш баскычларының максималь санын күрсәтә: **бавыр** – *бавыргалык – бавыргалыклы*, **бавыр** – *бавырсак – бавырсаклы*; кыек сызыктан соңгы 14 саны ояның киңлеге, ягъни беренче баскычта баш сүздән ясалган ясалма сүзләр санына тигез: **бавыр** – *бавыргалык, бавырлану, бавырлы, бавырсак... бавырчы, бавыргөмбә...* һ.б.; сызыктан соңгы 4 саны оядагы сүзьясалыш чылбырларының санын белдерә: **бавыр** – *бавыргалык – бавыргалыклы*, **бавыр** – *бавыргалык – бавыргалыксыз*, **бавыр** – *бавырсак – бавырсаклы*, **бавыр** – *бавырсак – бавырсаксыз*; кыек сызыктан соң килгән соңгы 3 саны оядагы сүзьясалыш парадигмалары санына тигез: **бавыр** – *бавыргалык, бавырлану, бавырлы, бавырсак, бавырсыз, бавырчы ... бавыр мүге*; **бавыргалык** – *бавыргалыклы, бавыргалыксыз*; **бавырсак** – *бавырсаклы, бавырсаксыз*.

Димәк, сүзьясалыш ояларына шушы рәвешле тулы анализ ясау аның математик моделен эшләргә мөмкинлек бирә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: татар тел белеменең сүзьясалышы өлкәсендә билгеле бер дәрәҗәдә тикшеренүләр алып барылса да, бүгенге көндә хәл итеп бетереләсе мәсьәләләр дә шактый әле. Татар теле сүзьясалышы теориясен җентекләп эшләү, һәр сүзьясалыш оясын төрле яклап тикшерү, шул тикшеренүләргә нигезләнеп, аларның типологиясен һәм модельләрен эшләү татар тел белеменең көнүзәк проблемалары булып кала бирә.

**Әдәбият**

*Денисов П.Н.* Принципы моделирования языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1963. 23 с.

*Ким О.М.* Транспозиция на уровне частей речи и явление омонимии в современном русском языке. Ташкент, 1978. 227 с.

Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

*Сабитова И.И.* Словообразовательная характеристика лексики татарского языка: компьютерно-лингвографический аспект. Казань: Фикер, 2002. 144 с.

*Сабитова И.И.* Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «Кеше» тематик төркеменә караган лексика. Казан: ТӘҺСИ, 2015. 160 б.

*Татарская грамматика.* Т. I. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 584 с.

*Хайруллина Э.Ю.* Словообразовательные гнезда имен прилагательных в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук : 10.02.02. Казань, 2006. 297 с.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´373

***Ә.К. Булатова***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СЕМАНТИК ДЕРИВАЦИЯ КҮРЕНЕШЕ

Настоящая статья посвящена изучению семантической деривации, анализу результатов деривационных процессов, определению роли семантической деривации в формировании лексико-семантической системы татарского языка. Без осмысления роли семантической деривации в языке невозможно составить целостного представления о семантическом пополнении и обогащении лексического состава татарского языка.

**Ключевые слова**: лексика, татарский язык, деривация, полисемия, семантика, семантическое калькирование.

Хәзерге татар тел белемендә семантик деривация процессының телнең лексик-семантик системасын формалаштырудагы ролен билгеләү, деривацион процессларны анализлау һәм өйрәнү көнүзәк мәсьәләләрнең берсе санала.

Сүзнең семантик төзелеше гаять хәрәкәтчән, чөнки лексик-семантик вариантлар даими үзгәрештә яши. Бу күренеш исә һәрбер телнең лексик системасы үзенчәлекле сыйфатларга хас булуын раслый.

Рус һәм гомум тел белемендә семантик деривация күренеше күптәннән һәм тирәнтен өйрәнелә. Ю.В. Агеева, А.Ә. Әминова, Л.С. Андреева, Д.И. Арбатский, Е.И. Әюпова, Э.А. Балалыкина, Т.Г. Бочина, М.Ю. Варламова, З.П. Данилова, А.А. Зализняк, О.В. Колочкова, А.А. Кретов, Н.Ф. Кривова, Э.В. Маркова, Г.А. Николаев, Б.И. Осипов һ.б.ның хезмәтләрендә ул төрле яклап анализлана. Татар лингвистикасы өчен бу яңа юнәлеш. Әлеге процессның аерым аспектлары Л.К. Бәйрәмова, И.Б. Бәширова, Ф.Ә. Ганиев, Ф.К. Сәгъдиева хезмәтләрендә искә алына.

Күпчелек очракта, деривация төшенчәсен аерым билгене теләсә нинди икенчел билгеләр ярдәмендә үзгәртү дип аңлыйлар, икенче төрле семантик сүзьясалышы дип тә атыйлар. Семантик деривация – ул сүзнең семантик ясалма, икенчел мәгънәләре, семантик коннотацияләр, алар нигезендә семантик синкретизм барлыкка килү процессы [Татар лексикологиясе, т. I, б. 105]. Семантик деривациянең нигезендә бер үк сүзнең синхрон һәм диахрон яссылыкта төрле лексик-семантик вариантларын бәйләүче мәгънәви үзгәреш мөнәсәбәте ята.

Семантик деривация процессы сүзнең күпмәгънәлелеге күренешенә барып тоташа. Аның асылы аерым сүзнең бер-берсенә бәйле булган берничә мәгънәсенең бергә яшәп килүеннән гыйбәрәт. Семантик деривация һәм полисемия бер үк күренешнең ике – динамик (процесс буларак)

һәм статик (нәтиҗә буларак) аспектын чагылдыра.

Семантик деривация мәгънәви үзгәрешләрнең сан ягыннан күрсәткече булып тора: яңа мәгънәләр сүзнең семантик кырын, күләмен киңәйтә. Мәсәлән, *тавыш* сүзе татар телендә ‘бугаздагы ярылар тирбәнүдән чыга торган һәр шәхеснең үзенә генә хас булган үзенчәлек – көче, тембры, югарылыгы-түбәнлеге белән сыйфатланган авазлар төркеме’ мәгънәсендә кулланыла: *Без аның апасы инде алайса – диде мөдир, Айсинәнең хәленә керегә теләгәндәерәк йомшак* ***тавыш*** *белән* (Н. Көбәш). Вакытлар узу белән, бу сүзнең мәгънәсе киңәеп, ‘шау-шу, кычкырышу, талаш’ лексик-семантик варианты барлыкка килә: *Сезгә дә шундый киңәш бирәм:* ***тавыш*** *чыгарып, гауга ясап йөрү егетлек түгел* (Н. Көбәш). Шулай ук сүз ‘дәүләт, җәмәгать мәсьәләләрен хәл иткәндә, үзенең фикерен белдерү хокукы’ мәгънәсен дә ала: *Гомуми җыелыш карарлары ачык ысул белән* ***тавыш*** *биреп утырышта катнашучы Совет Әгъзалары вәкилләренең күп* ***тавыш*** *җыюы аша: бер Әгъзага – бер* ***тавыш*** *принцибы буенча кабул ителә* (Татарстан Республикасы Хисап палатасы сайтыннан).

Семантик деривация, барыннан да элек, сөйләм күренеше буларак характерланырга мөмкин, чөнки теге яисә бу коннотацияләрнең актуальләшүе әлеге тел берәмлеге кулланылган контекстка кайтып кала. Әлеге очракта телнең үз законнарына яраклыштырылган сүзләрнең мәгънәләрен бутау куркынычы янамый. Чөнки күпмәгънәле сүз аерым бер сөйләм моментында үзенең бер мәгънәсендә генә кулланыла. Мәсәлән, *елга* сүзе ‘башланган урыныннан койган җиренә кадәр, табигый рәвештә салынган үзәне буйлап, туктаусыз агып торган шактый күләмле су агымы’н белдерә: *Аны буйдан-буйга икегә бүлеп* ***елга*** *ага* (Х. Арсланов). Аерым контекстта сүз ‘чиктән тыш күп күләм’ семемасында килергә мөмкин: *Халык язучысы Туфан Миңнуллин хаклы шул: акча* ***елгасы*** *акканда, милләт мәнфәгатьләрен, тамырыннан каерып, хәл итәргә ашыкмадык* («Ватаным Татарстан»).

Шуны да искәртеп китү зарур, кайвакыт семантик үсеш аерым телләрдә параллель бара алмый, кайбер очракларда бер телдәге сүзнең өстәмә мәгънәләре икенче телгә тәрҗемә рәвешендә керергә мөмкин, бу исә семантик калькалаштыру күренешен китереп чыгара. Мәсәлән, *тере* сыйфатының төп мәгънәсе – ‘үсемлек яки хайван рәвешендә бер организм булып яши торган, җанлы’. Рус телендә әлеге лексик берәмлек ‘турыдан-туры, тыңлау моментында трансляцияләнгән яисә башкарылган’ (*живой звук, живая музыка, живая трансляция*) дигән өстәмә мәгънә ала, татар телендә әлеге семема тәрҗемә ителеп кулланыла: *Аңлашыла, чит илләрнең шоулары* ***тере*** *тавыш, тере көйгә уза, ә бездә «Шоу» дип афиша гына языла* («Өмет»). *Бу инде магнитофоннарда һәртөрле тәлинкәләр уйнатып маташу түгел,* ***тере*** *моң!* (Ф. Яхин). ***Тере*** *музыка дөньякүләм танылган*

*дрессировщиклар чыгышының аерылгысыз бер өлеше булып тора* (Универсиада – 2013 блогы). Шулай ук рус теленнән *живые* (деньги) татар теленә *тере* (акча) ‘саф акча, реаль булган акча’ мәгънәсе белән кергән: *Финанс ярдәмгә килгәндә, без хуҗалыкларга «**тере**» акча бирмибез, без аларның матди-техник базаларын ныгытуда булышуны күздә тотабыз* («Ютазы таңнары»).

Семантик калькалаштыру очракларын төгәл раслап булмаска да мөмкин, чөнки даими рәвештә үзара бәйләнештә яшәп килгән телләрдә семантик деривация белән семантик калькалаштыру арасындагы чикләр җуела.

Яңа номинатив берәмлекләрнең барлыкка килүе төрле семантик процесслар ярдәмендә тормышка ашырыла, аларга мәгънә үзгәрешен һәм күчерелмә мәгъНәләрне кертеп карарга мөмкин. Мәгънә үзгәреше яки модификацияләр булганда, референтлар уртак билгеләргә ия. Семантик үзгәрешләрнең сәбәпләре төрле булган кебек, алар үзләрнең табигате буенча аерым закончалыкларга нигезләнәләр, системалашалар. Мәгънә үзгәрешләре түбәндәге төрләргә аерылалар: 1) мәгънә киңәю; 2) мәгънә тараю; 3) энантиосемия (поляр, капма-каршы мәгънәләр барлыкка килү).

Яңа төшенчәләр барлыкка килү, һәрвакытта да телдә яңа сүзләр ясалуга китерми, кайбер очракларда инде кулланышта йөргән сүзләр яңа мәгънә төсмерләре белән байый, сүзнең мәгънәсе киңәя. Аерым сөйләм контекстында яисә тарихи үсеш дәверендә сүзнең семантик күләме артырга, мәгънәсе киңәергә мөмкин. Мәсәлән, *бистә* ‘шәһәрнең эчендә яки кырыенда аерым урнашкан район’: *Киндер суга **бистә** кызлары* (Х. Туфан). Хәзерге вакытта шулай ук шәһәргә карамаган аерым торак пунктын да *бистә* сүзе белән атыйлар: *Алга таба берникадәр вакыт ул Куйбышев (хәзер Самара) заводларының берсендә, төзелештә эшли, Урыссу урамнарын түши һәм **бистә** читендә дамба төзи* («Ютазы таңнары»).

*Караш* сүзенең төп мәгънәсе – ‘карау юнәлеше’: *Ул шунда Солтанга ачуланып, сез үз акылыгыздамы соң дигәндәй, шикле **караш** ташлап алды* (Ф. Яхин). Тарихи планда әлеге сүзнең дә мәгънәсе киңәеп, ‘фикер йөртү рәвеше’ семемасы белән баеган: *Ничек булса да тәмәке тартуга карата тискәре **караш** тудырырга кирәк* («Татарстан яшьләре»).

Сөйләм контекстында яисә тарихи үсеш дәверендә сүзнең аерым мәгънәләре кулланылыштан төшеп калырга да мөмкин, бу – мәгънә тараю күренеше дип атала.

Семантик закончалыклар арасында сүз семантикасының тарихи үзгәрешен чагылдыручы энантиосемия күренеше аерылып тора. Ул турыдан-туры лексеманың кулланылыш үзенчәлегенә бәйле. Семантик деривацияне өйрәнгәндә сүзнең эмоциональ бизәлеше үзгәрүен дә истә тоту зарур. Лексик берәмлекнең поляр семантик мәгънә төсмерләре барлыкка килү, ягъни бер үк сүзнең

капма-каршы лексик-семантик вариантлары булу – барлык телләргә хас күренеш. Ул лексеманың озак кулланылыш үзенчәлегеннән килеп чыга. Мәсәлән, *уйнау* лексемасы уңай коннотациягә – ‘күңел ачу, ял итү максаты белән нинди дә булса уен башкару’ мәгънәсенә ия: *Микәйнең үзенә дә ошый иде алар белән куышып* ***уйнау*** (Р. Мөхәммәдиев). Аерым контекстта ул тискәре төсмерле ‘ярамаган, тыелган нәрсә белән шаяру’ мәгънәсендә дә кулланыла: *Алар дини халык һәм аларның хисләрендә* ***уйнау*** *– ул җинаять кылу* («Өмет»).

*Акыллыбаш* – ‘эшне акыл белән йөртә белгән, тәҗрибәле, төпле акылга ия кеше’: *Аның геройларын хәтта характерлау да мөмкин түгел, алар берничә минут эчендә әле* ***акыллыбаш****, әле чиктән тыш надан һәм ахмак; әле интернационалист, әле милләтче; әле эчкече, әле абсолют аек; әле тыйнак, әле азгын сыйфатында ачыла* («Идел»). Әлеге сүзнең шулай ук ‘үзендә юк акылны кешегә «сатарга» яратучы, белдекле булып кыланучы, надан’ кебек капма-каршы мәгънәсе дә яшәп килә: *Моны уйлап тапкан* ***«акыллыбаш»****лар фикеренчә, үзенә күрә, үсмерләрне начар йогынтылы фильмнардан, тапшырулардан саклау чарасы булырга тиеш иде кебек* («Татарстан яшьләре»). Әлеге мәгънә модификацияләре денотатның алмашынуы белән бергә бара, коннотатив фонның үзгәрүе белән беррәттән, үзара каршылыклы бәяләү характеристикалары барлыкка килә.

Шулай итеп, семантик деривация – сүзнең мәгънәви төзелешендә барган семантик үзгәрешләр процессы. Аны без шулай ук телнең семантик системасы үсешенең аерым бер этабы итеп карый алабыз. Хәзерге вакытта семантик деривация татар телендә яңа номинатив берәмлекләр барлыкка килүнең нәтиҗәле ысулы булып санала.

**Әдәбият**

*Абдуллина Ф.А.* О моделях семантического словообразования в татарском языке // Словообразование в тюркских языках: исследования и проблемы. Казань, 2011. С. 106–110.

*Балалыкина Э.А.* Развитие противоположных оттенков в пределах одного слова в истории русского языка // Семантика русского языка в диахронии. Калининград: Изд-во Калиниград. ун-та, 1994. С.3–10.

Татар лексикологиясе: 3 томда / авт.: М.З. Зәкиев, Г.Р. Галиуллина, Р.Ф. Фәттахова, Ә.К. Булатова / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т. 352 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 1 т. / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова. 475 б.; 2 т. / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.; 3 т. / төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәре*

УДК 81’373.4

***Ф.И. Таһирова***

# СҮЗ ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ
## *(катлаулы конструкцияләрне сүзлектә вокабула итеп бирү яссылыгыннан)*

Статья посвящена анализу различных критериев разграничения сложных языковых конструкций, сходных по форме, но разных по их морфологическому, синтаксическому и лексическому статусу. Проблема особенно актуальна с точки зрения лексикографии, так как каждая языковая единица проходит отбор и фиксируется в словаре именно согласно этим особенностям. Рассматриваются различные критерии дифференциации составного слова, словосочетания и фразеологической единицы. Среди них выделяются наиболее часто предлагаемые различными исследователями графический, фонетический, структурный, синтаксический и др. критерии. Все они рассматриваются с точки зрения приемлемости к татарскому языку, действенности и степени важности.

**Ключевые слова:** лексикография, слово, сложное слово, словосочетание, границы слова, критерии.

Татар лексикографиясе соңгы елларда зур уңышларга иреште, дип әйтергә нигез бар. Ул, сүзлекләрнең басылып чыгуыннан, аларның сан ягыннан үсүеннән генә гыйбарәт булмыйча, яңа басылган һәм төзелеп килгән сүзлекләрнең сыйфатын күтәрүдә, эчтәлеген камилләштерүдә дә чагылыш таба. Хәтта икенчесе бәлки әһәмиятлерәктер дә.

Сүзлекнең сыйфаты нәрсә белән билгеләнә дигәндә, беренче чиратта, ул аның лексикографик стандартларга – материалның бирелешендә эзлеклелек, системалылык, төгәллек кебек принципларга туры килүендә. Бу аспекттан бәяләгәндә яңадан төзелгән һәр сүзлек, элегрәк эшләнгәннәргә караганда, бер адым булса да алга китәргә тиеш.

Икенчедән, сүзлектә теркәлгән материал да аның лексикографик белешмәлек буларак сыйфатын чагылдыра торган фактор. Теркәү берәмлеген тәшкил иткән сүзләр төрле тел берәмлеге булырга мөмкин, шулай да күпчелек сүзлектә мәкалә башы итеп сүз алына. Бу мәкаләдә сүзлектә теркәлергә тиешле берәмлекләрне сайлап алу, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, кайсы берәмлекләрне бирергә, кайсыларын бирү – ялгыш, һәм бу сайлап алу нинди критерийләргә таянып башкарылырга тиеш дигән сорауларга җавап бирү бурычы куелды. Бу сорауларның ни кадәр катлаулы һәм әһәмиятле булуын сүзлек төзү практикасы күрсәтә, һәм аларның чишелеше турыдан-туры сүзлекнең сыйфатын һәм лексикографик яктан, һәм эчтәлеге ягыннан күтәрә торган фактор.

Төгәлрәге, проблема нәрсәдән гыйбарәт соң? Татар теле сүзлекләрендә әле 2000 елларга кадәр вокабула итеп, ягъни баш

сүз, мәкалә башы итеп бербөтен, ягъни кушылып язылган, яки парлы конструкция генә теркәлә иде. Мәсьәләгә болай якын килүнең һәм практик яктан, һәм теоретик яктан бик үк дөрес булмавы ачыкланды. Практик яктан зыяны шул: сүзлектә бирелгән башка берәмлекләр, я берәр махсус билге, я шрифт белән аерып, төп сүзнең мәкаләсе эчендә килә иде, ә бу эзләүне катлауландыра һ.б. кыенлыклар тудыра. Теоретик яктан исә аларның статусы билгеләнмичә калу, төрле статустагы берәмлекләрнең беррәттән, берничек тә аерелмыйча бирелүе, тиеш булмаган конструкцияләр алыну кебек проблемалар кала. Болар барысы да, үз чиратында, түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле:

– Сүз (гадәттә тезмә сүз) белән ирекле сүзтезмәне аеру;

– Сүз (гадәттә тезмә сүз) белән фразеологик берәмлекне аеру;

– Фразеологик берәмлек белән ирекле сүзтезмәне аеру.

Бу мәсьәләләр һәм теоретик, һәм практик яктан мөһим саналалар. Бүгенге көндә әлеге проблема теоретик яктан шактый җентекле тикшерелгән дип әйтә алабыз. Рус тел белемендә ул күптән өйрәнелә. Турыдан-туры шушы мәсьәләгә багышланган хезмәтләрдән түбәндәгеләрне атарга мөмкин: О.С. Ахманованың «К вопросу об отличии сложных слов от фразеологических единиц» мәкаләсе һәм шул ук авторның «О разграничении слова и словосочетания» исемле докторлык диссертациясе; Г.А. Брикның «К определению признаков сложного слова» мәкаләсе һәм «Сложные слова и словосочетания в отношении к общим для них и различающим признакам» дигән темага диссертациясе. Төрки тел белемендә Н.М. Маматовның «Об отличии сложных слов от синтаксических сочетаний» мәкаләсеннән берникадәр мәгълүмат алырга мөмкин. Бу мәсьәлә кайбер галимнәрнең (Ф.Ә. Ганиев, В.Г. Егоров, Л.Ж. Жабелова, А.А. Юлдашев, З.Г. Ураксин, Т.М. Гарипов, Г.Н. Семенова һ.б.ның) кушма сүзләргә багышланган хезмәтләрендә дә кузгатыла. Биредә тагын Г. Х. Ахунҗановның «Татар теленең идиомалары» монографиясен һәм башка гомумирәк характердагы хезмәтләрне атарга була. Күрүебезчә, бу өлкәдә тикшеренүләр бара, әмма мәсьәлә хәл ителгән диярга иртәрәк әле.

Охшаш төзелмәләрне берберсеннән аеру мәсьәләләре, нигездә, сүз турындагы гомуми теориягә карый. Бу өлкәдә рус лингвистлары А.М. Пешковский, А.И. Смирницкий, А.А. Реформатский, В.В. Виноградов, Л.В. Щерба, шулай ук Леонард Блумфилд, Эдуард Сепир, Луи Ельмслев кебек чит ил галимнәре зур өлеш кертәләр. Югарыда билгеләнгән мәсьәләләрне чишү дә сүз турындагы гомуми теориягә таянырга тиеш. Аларның асылы ике проблемага кайтып кала:

1) сүз чикләрен билгеләү;

2) сүзнең үзтәңгәллеге.

Әлеге тикшеренү шуларның беренчесенә – сүз чикләрен билгеләү критерийларына багышлана. Турыдан-туры шушы өлкәдә эшләгән галимнәр «Нәрсә соң ул сүз?», «Нинди берәмлекне сүз дип санарга?», «Сүзне нәрсә бил-

гели?» дигән сорауларга төрлечә җавап бирәләр һәм, сүзне сүз итеп тану өчен кирәк булган критерий буларак, төрле билгеләрне күрсәтәләр. Аларның кайберләренә кыскача күзәтү ясап үтик. Күпчелек галимнәр тарафыннан түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) график критерий; язылыш критерие. *Сүз* ике бушлык арасындагы график билгеләр җыелмасын тәшкил итә. Кимчелеге – тел берәмлеге буларак сүзгә туры килми, чөнки аерым компонентлардан торган сүзләр булса да, алар сүз буларак танылмый. Алар тезмә сүзләр түгел, мәсәлән: рус телендә: *поодиночке* һәм *в одиночку*; немец телендә: *aufstehen* һәм *stehe auf* һ.б. Кыскасы, катлаулы төзелмәләрнең статусы аларның язылышына карап билгеләнә алмый, киресенчә, язылышы аларның статусына туры китерелергә тиеш. Башкача әйткәндә, бу кушылып язылган, димәк, бу – кушма сүз, дип автомат рәвештә кабул итә алмыйбыз, ә, киресенчә, бу – кушма сүз, чөнки билгеле таләпләргә туры килә, шуңа күрә кушылып язылырга тиеш, дип раслый алабыз;

ә) фонетик критерий шулай ук абсолют була алмый, чөнки басым, пауза кебек билгеләр үзгәрүчән. Мәсәлән, мөстәкыйль басымы булмаган сүзләр, өстәмә басымлы берәмлекләр, үзгәрүчән логик басым, синтагма басымы һ.б. факторлар бу очракта исәпкә алынмый;

б) структур критерий. П.С. Кузнецов: «*Сүз* бүленмәс бербөтенне тәшкил иткән авазлар эзлеклелеге, аның элементларын мәгънәгә зыян китермәслек итеп бүлеп, алмаштырып, урынын үзгәртеп булмый», – дип раслый [Кузнецов, 2003]. Әлеге критерий татар теленә чынлап та туры килә һәм күп кенә берәмлекләрне аеру өчен төп критерий була ала. Мәсәлән, *кызыл каз* «фламинго» мәгънәсен белдерә. Ә *кызылрак каз – каз кызыл – сары каз* яки *кызыл үрдәк* кебек үзгәртүләр кертү «фламинго» мәгънәсенең юкка чыгуына китерә. Димәк, *кызыл каз* конструкциясе тел берәмлеге буларак сүз статусына ия.

Ләкин бу критерийны да күп кенә башка телләргә карата кулланып булмый, мәсәлән, рус телендә: *никто* һәм *ни у кого*: *читаю – буду долго читать – я читать буду* һ.б.;

в) морфологик критерийны А.И. Смирницкий кертеп җибәрә. Аның фикеренчә, *сүз* һәр морфологик категорияне, һәр грамматик форманы ала, ә сүзнең аерым кисәге яки сүзтезмә сан, килеш һ.б.ш. белән төрләнә алмый [Смирницкий, 1954]. Мәсәлән: *кызыл каз* «фламинго» – *кызылга казга* була алмый, *кызыл казга* була. Кимчелек – бу критерий сүзне морфемадан һәм сүзтезмәдән аерырга мөмкинлек бирә, ләкин фразеологизмнан аермый;

г) синтаксик критерийны күрсәтүчеләрдән Л.В. Щерба, Е.Д. Поливанов, Л. Блумфилд, И.А. Бодуэн де Куртенэ, Э. Сепир, Р.О. Якобсон кебек галимнәрне санарга була. Алар *сүзне* җөмләнең потенциаль минимумы, ягъни минималь синтаксик берәмлек дип карыйлар. Моның кимчелеге – мөстәкыйль җөмлә кисәге була алмаган ярдәмче сүзләрне аермауда;

д) семантик критерий. А.А. Реформатский, Л. Ельмслев фикеренчә, аерым бер төшенчәне белдергән берәмлек – *сүз* дип атала [Реформатский, 1979; Ельмслев, 2006]. Сүзгә мәгънәнең идиоматиклылыгы хас, башкача әйткәндә, тулы сүз мәгънәсенең аны тәшкил иткән кисәкләрнең мәгънәсе белән бернинди уртаклыгы юк. Әмма бу да *сүзне* фразеологик берәмлектән яки терминологик тезмәдән аерып бетерми, чөнки алар да бер төшенчә белдерә ала. Шулай да күпчелек очракта сүзләр, шул исәптән кушма сүзләр дә, төшенчәне белдерә, атый. Фразеологик берәмлек исә объектны бер яктан характерлый, аңа экспрессив-эмоциональ бәя бирә, икенче объект белән чагыштыру, метафора аркылы субъектның объектка карата мөнәсәбәтен белдерә. Икенче төрле итеп әйтсәк, сүз – атама, фразеологизм – бәяләмә.

Күпмәгънәле төзелмәләр шулай ук *сүз* дип танылырга тиеш. Фразеологиядәге күпмәгънәлелек һәм омонимия очраклары практикада предикатив (фигыль булган) фразеологик берәмлекләрдә генә очрый;

е) сүзьясалыш критерие. Сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясаганда кушма сүзләр фразеологик берәмлекләрдән аерыла. Мәсәлән, аңлатмалы сүзлектә *ач күз* фразеологик берәмлек буларак бирелгән [Аңлатмалы..., 1977, с. 88]. Аннан *ач күзләнү* ясалган. Нәтиҗәдә *күзләнү* сүзе килеп чыккан. Югыйсә сүзьясагыч кушымча *күз* сүзенә генә түгел, *ачкүз* сүзенә кушыла. Димәк, *ачкүз* сүзьясагыч нигез була ала икән, бергә язылырга һәм кушма сүз дип танылырга тиеш, чөнки бер сүздән торган фразеологизм булмый. Нәкъ шул принциптан чыгып, *тимер юл – тимерьюлчы*, *ике йөзле* ‘двуличный’ – *икейөзлелек* ‘двуличие, цинизм’ кебек берәмлекләр дә сүз буларак кабул ителергә тиеш;

ж) логик критерий. Тезмә сүз, гади сүз кебек үк, логика дәрәҗәсендә һәрвакыт төшенчәгә, ә фразеологик берәмлек ешрак фикри нәтиҗәгә (умозаключениегә) туры килә. Фразеологик берәмлек гади сүз белән тәңгәл түгел, ул гади сүзгә җөмлә кисәге булуы, ягъни функциясе ягыннан гына охшаш. Бу күренеш фразеологик берәмлекләрдән әйтемнәрне һәм мәкальләрне аерып чыгарырга да мөмкинлек бирә. Мәкальләр тәмамланган фикерне белдерәләр, димәк җөмлә була алалар, ә фразеологик берәмлекләр – җөмлә кисәге генә булып килә ала. Мәсәлән, *инә күзеннән үткәрү* – фразеологик берәмлек, ә *инә дә бүләк, дөя дә бүләк* – мәкаль [Аңлатмалы..., 1977, с. 401].

«Тезмә термин» белән «терминологик сүзтезмә» төшенчәләрен аермау очраклары еш күзәтелә, гәрчә алар шул ук тезмә сүз һәм иркле сүзтезмә булып торсалар да. Һәм аларны аеру да шул ук критерийларга нигезләнә.

Сүз чикләрен билгеләү, аны телдәге башка берәмлекләрдән аеру критерийлары моның белән генә чикләнми әлбәттә. Кайбер галимнәр фикеренчә, аларның саны 70 ләп исәпләнә.

Йомгаклап әйткәндә, югарыда санап үткән критерийларның

берсе дә барлык төр конструкцияләрне дә аера алырлык бердәнбер критерий була алмый. Һәр очракта төрле критерийгә яки аларның комбинациясенә нигезләнеп эш итәргә тиеш булабыз. Кайвакытта берәмлекләрнең статусын төгәл билгеләү гомумән мөмкин түгел. Бу турыда Л.В. Щерба болай ди: «В природе нет нигде абсолютных границ. Нет их и в языке, и именно потому, что язык постоянно развивается, очень трудно безостаточно разграничить соприкасающиеся единицы. Здесь всегда существовало и существует множество переходных форм» [Щерба, 1974, с. 52]. Соңгы чорда тел белемендә барлыкка килгән яңа синлексикологик теория дә шуны раслый. Гомумән, бу төр тикшеренүләр, нәтиҗәдә, хәзерге вакытта төзелә торган сүзлекләрдә дә, теоретик хезмәтләрдә дә элек булган ялгыш һәм төгәлсезлекләрдән котылу өчен фәнни нигез тудыра һәм алга таба гомуми сүз теориясен үстерүгә өлеш кертә.

**Әдәбият**

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. М.: Сов. энциклопедия. 1966. 606 с.

*Ахунҗанов Г.Х.* Татар теленең идиомалары. Казан: Татар. кит. нәшр. 1972. 118 б.

*Ганиев Ф.А.* Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука. 1982. 149 с.

*Ельмслев Л.* Пролегомены к теории языка. М.: КомКнига, 2006. 248 с.

*Жабелова Л.Ж.* Сложные имена существительные в современном карачаево-балкарском языке. Нальчик: Эльбрус,1986. 108 с.

*Кузнецов П.С.* О принципах изучения грамматики. М.: URSS. 2003. 102 с.

*Реформатский А.А.* Очерки по фонологии, морфонологии и морфологии. М.: Наука. 1979. 102 с.

*Смирницкий А.И.* К вопросу о слове (проблема «тождества слова») // Труды Института языкознания АН СССР. Т. 4. М., 1954.

*Тагирова Ф.И.* Различение сложных слов от сходных конструкций // Гуманитарные науки: Поиски и достижения. Казань: Фикер, 2004. С. 383–390.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 1 т. 476 б.; 1979. 2 т. 726 б.; 1981. 3 т. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 48 б.

Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге: Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

Татарско-русский словарь: в 2 т. Казан: Мәгариф, 2007. Т. 1. 726 б.

Татарско-русский словарь: в 2 т. Казан: Мәгариф, 2007. Т. 2. 726 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. III т.: К. Казан: ТӘҺСИ, 2017. 744 б.

*Щерба Л.В.* Языковая система и речевая деятельность. Л. 1974.

***Таһирова Фәридә Инсан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.122:821.512.145

*К.М. Миңнуллин*

# ТӨРКИ ТЕЛЛЕ ЯЗУЧЫЛАР МИЛЛИ ТРАДИЦИЯЛӘР САГЫНДА: МОХТАР АУЭЗОВ[1]

Анализ творческой эволюции М. Ауэзова на фоне истории татарской литературы указывают на то, что в тюркоязычных литературах плеяда талантливых писателей оказалась на страже национальных художественных традиций. Их произведения вывели из кризиса и изменили многонациональную советскую литературу, вернув искусству слова его священную функцию – развивать духовное начало и эстетический вкус, прививать вековые нравственные ценности, укрепить национальное самосознание.

**Ключевые слова:** Мухтар Ауэзов, тюркоязычные писатели, национальные традиции, татарская литература, казахская литература.

1917 елгы инкыйлаби үзгәрешләр Россия территориясендә яшәүче күп кенә төрки халыкларның дөньяви әдәбияты формалашу дәверенә туры килә. Язма телгә яңа гына күчкән халыкларда матур әдәбият әле туып кына килә бу чорда. Ә татар һәм азәрбайҗан әдәбиятында, XX гасыр башында Көнчыгыштан Көнбатышка юнәлеш тоту, дини карашлардан дөньяви фикерләүгә күчү белән бәйле рәвештә, яңа әдәби парадигма формалаша башлый. Алга таба Россиядәге төрки телле әдәбият үсеше, Совет дәүләтендәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр сәбәпле, сәяси һәм идеологик йогынты басымына дучар ителә.

1920–1930 елларда «әдәбиятны идеологик эшчәнлек өлкәсенә әйләндерү тенденциясе көчәя» [Галимуллин, б. 6]. Күпсанлы газета һәм журнал битләрендә тәкъдим ителгән әдәби әсәрләрдә заман рухына яраклаштырылган «яңа сәнгать» тудыру бурычы куела. Рус әдәбияты Бөтенроссия мәдәни тормышы үрнәге буларак кабул ителә. Бу күренешләр әлегә кадәр яшәп килгән милли традицияләрдән баш тарту фонында бара. Иҗади интеллигенциянең инкыйлабка кадәрге мирасы «пролетар сәнгать» өчен чит булып санала. Мәсәлән, хәтта төрки әдәбият классиклары саналган Габдулла Тукай белән Абай иҗаты да 1920–1930 елларда «пролетар әдәбият» нәзарияте кысаларында анализлануга дучар ителә. 1921 елда татарның күренекле прозаикларының берсе Фатих Әмирхан болай дип яза: «Мин Николай цензурасының иң кара елларында һәм Керенский заманында да газеталарда эшлә-

[1] Мәкалә М.О. Ауэзовның тууына 120 ел тулу уңаеннан уздырылган «М.О. Ауэзов һәм милләтнең рухи яңарышы» Халыкара фәнни сипозиумында (Алматы, 28.09.2017) ясалган чыгышка нигезләнеп язылган.

дем, әмма беркайчан да матбугат ирегенең бу кадәр кимсетелүен күрмәдем, һәм сүз ирегенең тыелуын үземдә татымадым» [Вәлиев, б. 55]. Марксистик-ленинчыл идеология доктринасына тугрылык барлык язучылардан да таләп ителә. Сәнгать өлкәсендәге милли традицияләрне һәм төрки халыкларның СССР территориясендәге матди булмаган, әмма зур кыйммәткә ия мәдәни мирасын юкка чыгару куркынычы әнә шулай туа.

Шундый катлаулы заманда, соцреализм идеологиясе нормага әверелгән шартларда төрки халыкларның бөек акыл ияләре, талантлы уллары зирәклек һәм эстетик уяулык белән әнә шул традицияләрне саклап калу юлына басалар – ачыктан-ачык түгел, ә каләм көче, сүз сәнгате ярдәмендә милли хәзинәләребезнең уникальлеге һәм үзенчәлекле булуы, халкыбыз теленең байлыгы хакында укучыларга җиткерәләр. Моны без казах әдәбияты классигы Мохтар Омархан улы Ауэзов иҗатында ачык күрәбез, аның әсәрләре үз халкының куәтен һәм тарихи, фәлсәфи киңлеген, мәдәниятен дөньякүләм биеклеккә күтәрү омтылышы белән сугарылган. Т. Ахтанов аның хакында шушы ракурстан чыгып болай яза: «Но для нас, казахов, Ауэзов больше, чем писатель, ибо так велико его место в нашем национальном самосознании и духовном возрождении, что творчество этого большого мастера слова выходит за пределы его огромной, чисто литературной деятельности» [Ахтанов]. Нәкъ менә шушындый акыл ияләренең гамәлләре белән 1930–1940 елларда төрки телле әдәбиятта шәхес концепциясе һәм тоталитар күзәтчелек шартларында милли үзаңны үстерүгә юнәлдерелгән дөнья күренеше барлыкка килә башлый. 1960 елларда ул иң биек ноктасына җитә.

М. Ауэзовның әдәби иҗаты 1917 елгы борылышлар чорында башланып, ул үзенең беренче драма әсәрен – төрки дастаннарга хас мәхәббәт темасын, үзара дошманлашып яшәүче ике гаиләдәге егет белән кызның мөнәсәбәтләрен чыгылдырган «Еңлик – Кебек»не яза. Көнбатыш Себердә Совет хакимияте урнашкач, М. Ауэзов илнең иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша башлый, белем ала, иҗат белән шөгыльләнә. «Мазлумнар көне» (1921), «Кем гаепле?» (1923), «Өйләнү» (1923), «Укыган азамат» (1923), «Каралы сылу» (1925) хикәяләре, «Тау кичү вакыйгасы» (1927) повесте, «Каракүз» (1926), «Аҗаган» (1934), «Чик буенда» (1937) пьесалары һәм башка әсәрләре социалистик реализм концепциясенең көчле йогынтысы шартларында аның драматург һәм прозаик булып формалашуын дәлилли.

1930 еллар ахырында СССР территориясендәге төрки телле әдәбиятларның барысының да торышы уртак була: шәхес культы үзара ышанмаучылык һәм курку атмосферасы тудыра; башкача фикер йөртүчеләргә карата идеологик басым һәм сәяси террор янаган заманда барлык иҗади процесслар социалистик

реализмның «бермәдәниятлелек» кысаларына куып кертелә. Рухи сферада озакка сузылган торгынлык чоры башлана, әдәби иҗатның сәнгати-эстетик сыйфаты түбәнәя. Талантлы язучыларның күбесе иҗади кризис кичерә, эчтәлек һәм форма ягыннан соцреализм методы таләпләрен читләтеп узу юлларын эзләү дәвам итә.

1930–1940 еллар чигендәге вазгыять М.О. Ауэзов иҗатында да чагылыш таба. Бу чорны ул түбәндәгечә бәяли: «За спиной уже незаметно накапливалось прожитое, прошлое, наступила пора зрелости. Окончив советский вуз и аспирантуру, я все чаще обнаруживал в самом себе внутренние противоречия, идейные заблуждения, ошибки. Оглядываясь на свой творческий путь, я видел, что он еще не начат по-настоящему. В нем было немало творческих ошибок, и не мною написанное было полезно советскому народу, великой Родине. В 1932 г., решительно осудив свои идейные и творческие заблуждения, я начал работать по-новому, как советский писатель, драматург, прозаик, как исследователь истории казахской литературы, как педагог и лектор в казахских вузах» [Мухтар Ауэзов…, с. 67].

Бу борылыш, күрәсең, әсәр өчен материалны һәм аны соцреализм билгеләгән нормативларга яраштырып тасвирлау ысулларын эзләү нәтиҗәсе була. Һәм әдип аны халык иҗатыннан, тарихтан, үз халкының яшәү рәвешеннән таба. Халыкның зирәк акылына нигезләнгән мәкальләргә һәм әйтемнәргә, хикмәтле сүзләргә, халык җырларының гадилегенә һәм моңына әйләнеп кайту, милли әдәбиятта мифологик һәм фольклор әсәрләрдә гәүдәләндерелгән образларны куллану әдәби иҗатта идея тирәнлеген һәм мәгънәви киңлекне, эстетик югарылыкны, шулай ук милли (этник) үзенчәлекләрне саклап калуга юл ача. Бу характердагы охшашлыклар Советлар Союзындагы төрки телле әдәбиятларның һәркайсында да күзәтелә. Соцреализмның катгый таләпләрен читләтеп, чын халыкчан традицияләргә нигезләнеп иҗат иткән язучылар һәм шагыйрьләр дөньякүләм дәрәҗәдәге әсәрләре белән классиклар сафына бастылар.

Мәсәлән, татар әдәбияты классигы Гомәр Бәширов үзенең автобиографик характердагы «Көзге ачы җилләрдә» (1983–1985) дигән повесть-истәлекләрендә туган көненнән башлап 1950 елларга кадәрге дәвер вакыйгаларын колачлый, һәм бу әсәрдә авторның әдәби иҗатка карашлары формалашу процессы күзәтелә. 30 нчы еллар ахырында ул чын язучы булу өчен нәрсәдер җитмәвен тоя һәм, аларны эзләп, татар авылларына юл тота. Эзләгәнен халык сөйләменнән, аның тормыш-көнкүреш йолаларыннан, фикерләү куәсеннән табуы хакында болай яза: «Фольклор җыю мине җәлеп итә бара. Шул еллардан башлап, мин һәр җәйдә СССР Фәннәр академиясенең Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган, Хәмит Ярми җитәкчелегендәге

фольклор экспедицияләрендә катнаша башладым» [Бәширов, б. 114]. Бу эзләнүләр язучының иҗатына көчле йогынты ясый һәм халыкның рухи мирасына йөз белән борылырга этәргеч бирә. Шундый ук үзгәрешләр Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни һәм башка шагыйрьләребез, прозаикларыбыз иҗаты өчен дә хас күренеш.

М.О. Ауэзов та төрки халыклар тарихын, әдәбиятын һәм халык иҗатын тирәннән өйрәнә, 1928 елдан башлап, гомеренең соңгы чорына кадәр югары уку йортларында казах фольклоры, казах әдәбияты һәм Урта Азия республикалары әдәбияты тарихлары буенча курслар алып бара. Фән белән шөгыльләнә, «Казах халык эпосы һәм фольклоры» (Л. Соболев белән авторлашлыкта), «Әкиятләр», «Кузы-Көрпеш һәм Баян Сылу», «Айтыс» һ.б. темаларга фәнни хезмәтләр яза. Аларның һәркайсы халык авыз иҗатының төп жанрларын өйрәнеп тикшерүгә нигезләнә. Галим кыргыз эпосы «Манас»ның сакланган текстларын, аның хакындагы фәнни мәкаләләрне өйрәнеп, җыелма вариантын тәкъдим итә. Казах әдәбият белеме фәнен формалаштыруда аның казах әдәбияты тарихын яктырткан хезмәтләре аеруча мөһим урынны били.

М.О. Ауэзовның фәнни тикшеренүләре милли тарихның һәм төрки халыклар мәдәнияте тарихының яңа сәхифәләрен ача. «Хан Кене» драмасы (1934), «Абай» (1942–1947) һәм «Абай юлы» (1949) романнары казах халкының язмышын, аның күчмә тормыш бергәлегенә хас милли үзенчәлекләрен бөтен нечкәлекләре белән яктырткан тарихи елъязма, эпопея булып бәяләнә. Әдәбият белгечләре һәм М. Ауэзовның каләмдәшләре бу әсәрләрне казах халкының көнкүреше һәм гореф-гадәтләре, холкы-табигате һәм рухи чагылышы энциклопедиясе дип атыйлар. Романнар төзелеш үзенчәлекләре һәм образлар тудыру механизмы ягыннан төрки халыкларның героик эпосын хәтерләтә. Бу хакта Т. Ахтанов болай яза: «С появлением этих романов у казахских прозаиков началась новая веха в творчестве. Ауэзов раскрыл большие возможности, силу образности и выразительности казахского языка, создал национальные характеры, яркий самобытный колорит» [Ахтанов].

Шул ук вакытта, әлеге әсәрләрне башка төрки халык әдәбиятлары белән янәшә куеп өйрәнү процессында икенче бер күренеш игътибарны җәлеп итә: Совет заманында әдәбият классиклары тарихи тематиканы, шулай ук фольклордан «күчкән» образлар системасын һәм дөньяны күзаллау аерымлыкларын милли сүз сәнгатенең этник үзенчәлеген саклаган хәлдә кабул итәләр. Нәкъ менә тарихи һәм мифологик материаллар әйдәп баручы прозаикларга эпопея белән социаль-психологик романга хас сыйфатларны гармоник рәвештә берләштерергә (социалистик реализм боларны милли әдәбият әсәрләреннән төшереп калдырырга омтылса да), ягъни кеше образын кабиләдәшләрен үз артыннан ияртеп барырга сәләтле,

зирәк һәм акыллы, милли герой югарылыгында бәян итәргә мөмкинлек бирә. Н.Л. Лейдерман социалистик реализмның төп җитешсезлеген «сводит личность к социальной функции, а горизонты эстетического идеала ограничивает миром сугубо социальных ценностей, возводя обезличивание человека в массе в степень героической самоотверженности» [Лейдерман, с. 20], дип билгеләп, иң югары фольклор традицияләре тудырган төрки телле милли әдәбият герое үзәккә куелып, әсәрнең чикләрен милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре дәрәҗәсенә күтәрә. Социализм мәктәбен узган М. Ауэзов, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов кебек төрки телле әдәбият классиклары бу герой аша «туган җир», «борынгы бабаларыбыз җире», «минем халкым» кебек төшенчәләрне мифлаштыруга ирештеләр һәм образлары, символлары, үзенчәлекле алымнары белән әдәбиятка дөньяның традицион күренешен кайтардылар. Нәтиҗәдә милли әдәбиятларның күбесендә матур әдәбиятның милли традицияләренә, дөньяны кабул итү һәм дөньяга карашның милли үзенчәлекләренә кайту процессы башланды. М.М. Голубков аны болай бәяли: «привело к возникновению нового качества литературы <…> благодаря отталкиванию от прежней литературной традиции» [Голубков, с. 17].

Әдипнең башлангыч чор иҗатын анализлаган бүгенге әдәбият белгечләре язганча, «М. Ауэзов – реалист, занятый способами адаптации сознания соплеменников к неотвратимым переменам, ведущим в перспективе к пересотворению целого народа из кочевого в оседлый» [Раннее творчество…]. Бу фикер авторы аның Абай турындагы әсәреннән чыгып, «М. Ауэзов – реалист, занятый способами изменения казахской советской литературы к пересотворению из интернациональной – в национальную» – ди. Бу бәягә Советлар илендәге төрки телле язучыларның күбесе лаек.

М. Ауэзовның иҗади эволюциясен татар әдәбияты тарихы яссылыгыннан чыгып анализлау күрсәткәнчә, төрки телле әдәбиятлар сафындагы талантлы язучылар матур әдәбиятның милли традицияләре сагына басалар. Аларның әсәрләре күпмилләтле совет әдәбиятын кризистан чыгара һәм сүз сәнгатенең рухи башлангычны һәм эстетик зәвыкны үстерү, гасырлардан сакланып килгән әхлакый кыйммәтләрне саклау, милли үзаңны ныгыту кебек изге функцияләрен кабат торгызалар.

М.О. Ауэзов барлык төрки халыкларның да диярлек тарихын һәм хәзерге торышын яхшы белгән язучыларның берсе. Без аның татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимов белән рухи охшашлыгы, Казан белән тыгыз бәйләнештәге Магжан Жумабаев белән үзара мөнәсәбәтләре, татар дөньясы белән шәхси элемтәләре, М. Җәлилне яклап чыгыш ясавы хакында һәрчак искә алабыз.

М.О. Ауэзовның СССР халыклары әдәбиятлары арасындагы үзара бәйләнешләрне һәм

аларның бер-берсен баетуны күздә тоткан проблемаларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре Совет чоры әдәби процессларын тикшерүчеләр өчен нигез хезмәтен үти. Аның югары профессиональ дәрәҗәдәге тикшеренүләре фольклорны, дастаннарны, төрки халыклар әдәбияты тарихын, тел белеме, эстетика, фәлсәфә, музыкаль һәм пластик сәнгать тарихын өйрәнү өлкәсендә күп кенә юнәлешләрнең башлангычын тәшкил итә. Татарлар күзаллавында Әмирхан Еники белән бер рәттәге Чыңгыз Айтматов, Мостай Кәрим һәм Рәсүл Гамзатов, Гафур Голәм һәм Самәд Вургун кебек төрки халыкларның тагын күп кенә талантлы язучылары арасында сәнгатьле сүз остасы, тынгысыз галим, югары интеллектлы шәхес Мохтар Ауэзовның үз урыны бар.

**Әдәбият**

*Ахтанов Т.* Слово о Ауэзове: пер. с казахского В. Аксенова.// http://txt.rushkolnik.ru/docs/index-39782.html?page=52 – дата обращения: 28.08.2017 г.

*Голубков М.М.* Утраченные альтернативы. Формирование монистической концепции советской литературы. 20–30-е годы. М.: Наследие, 1992.

*Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н.* Современная русская литература: 1950–1990-е годы: в 2-х томах. Т. 1: 1953–1968. М.: Академия, 2006.

Мухтар Ауэзов – классик современной литературы: сборник статей. Алма-Ата, 1980.

Раннее творчество Мухтара Ауэзова в контексте литературы Алаш-Орды // Тамыр: искусство, культура, философия. 2014. 18 сентября. http://go.mail.ru/redir?via_page=1&type=sr&redir=eJzLKCkpsNLXL0nMrSzSyy9K17cvsDUytrBgYDA0NTAxMDQ1NTJicEuPsP4ZXvSQUe2aPrfGEgEAtHkP2w – дата обращения: 28.08.2017 г.

*Бәширов Г.* Көзге ачы җилләрдә // Бәширов Г. Тормыш юлында: повесть-истәлек, публицистик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

*Вәлиев Н.М.* Фатих Әмирхан һәм совет хакимияте (әдипнең куен дәфтәрләре), 1921–1926 еллар // Фатих Әмирхан: традицияләр һәм заманчалык. Казан, 2006.

*Галимуллин Ф.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика канунннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева***

# ФАТИХ ХӨСНИ ПРОЗАСЫ: ЖАНР ТАБИГАТЕ ҺӘМ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Фатих Хусни – один из известных писателей, оказавших влияние на развитие татарской прозы. Автор статьи стремится выделить историческую и национальную значимость, а также художественные особенности его творчества. Особо подчеркивается важность того, что в своем творчестве Ф. Хусни обращается к национальным традициям и вносит вклад в обогощение татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** Фатих Хусни, татарская проза, роман, повесть, рассказ, стилевые особенности.

Совет хакимияте урнашкан елларда әдәбиятка килеп, аның таркалу елларына кадәр яшәгән, ягъни бөтен иҗат гомере совет чорына туры килгән Ф. Хөсни – татар халкының милли традицияләрен саклауга, телен баетуга күп көч куйган һәм, иң мөһиме, кешене партиянең бер шөребе итеп карауга кискен каршы чыккан олуг язучыларыбызның берсе.

Ф. Хөснинең әдәби мирасы гаять бай һәм күпкырлы. Ул татар әдәбиятына өч роман, егермеләп повесть, драма әсәрләре һәм берничә дистә хикәя-новелла бүләк итте. Иҗатка күләмнән чыгып бәя бирелми, әлбәттә, әмма Ф. Хөснинең һәр әсәре тел-стиль җәһәтеннән булсынмы, төзелеше яки проблеманың куелышы булсынмы, идея-мәгънә ягыннанмы – сәнгати камил, һәр яктан эшләнгән булуы белән дә аерылып тора. Ул иҗатының башлангыч чорында үзен сүз сәнгатенең төрле өлкәләрендә сынап карый. Ф. Хөсни әдәбиятка шагыйрь буларак килеп керә. Заман таләп иткәнчә революцион рухта язылган романтик шигырьләрендә Такташ интонациясе сизелеп тора. Әдип үзе үк аларда образлылыкның, тормышчанлыкның җитмәвен таный. Соңрак юмор катыштырып: «Шигырьдә син аркандагы ат кебек, рифма казыкларына бәйләнеп куелгансың, фикергә үсәргә, хисләргә ташырга мөмкинлек юк. Ә менә хикәядә яки драмада син инде тәрханда, теләсәң кая чап, койрык чәнчеп чап!» [Хөсни, 1965, б. 110] дип, үзе өчен проза һәм драма жанрларының кулайрак булуын яза.

Яшь, тынгысыз Ф. Хөсни, берничә хикәясе белән матбугатта чыгыш ясаганнан соң, крестьян тормышына зур үзгәреш алып килгән колхозлашу турында тиз арада кыю фикерле «Җир тыңлый» романын иҗат итә һәм ул 1931 ел башында басылып та чыга. Китап яртылаш таралуга, Татар пролетар язучылары ассоциациясе (ТАПП) кискен тәнкыйть яудыра башлый, әсәр сәяси яктан зарарлы дип табыла, кулак идеологиясен яклап язылган

дигән бәя бирелә. Ф. Хөсни романдагы «хаталар»ын танырга, үз әсәреннән баш тартырга мәҗбүр ителә [Атака, б. 41–43].

Роман, вакыт ягыннан бик аз (1930 елның гыйнвары) араны алса да, зур масштабка ия, моның сәбәбе персонажларның күплеге һәм вакыйгаларның тыгызлыгы белән аңлатыла. Яшь Фатих заман таләбе белән кулакны явыз, астыртын, куркыныч итеп күрсәтергә тырышса да, болар әсәрдә абстракт төшенчә булып сүздә генә калган, чынлыкта исә Шакир, Ярхәм бай образлары, тирән психологизм белән сугарылу нәтиҗәсендә, җирнең чын хуҗалары, булдыклы игенчеләр буларак укучы күз алдына бастырыла.

Касыйм Сәлимов – кышкы каникул вакытында авылга кайтып, колхозга керергә агитацияләп йөрүче үзәк герой. Әмма Ф. Хөсни фикер каршылыкларын әлеге студент егет аша түгел, ә Сәрвәр Шамкина аша әйттерә. Сәрвәр, әсәрдә бердәнбер объектив карашлы, шәһәрдән укырга килгән «партиясез интеллигентка» буларак бирелә. Шул чорда ук ул илкүләм ясалган хаталарга үз бәясен бирә: дингә, мәчеткә кагылуны халыкның йөрәгенә кагылу дисә, кулакларга каршы көрәшне «хәерче арттыру» дип бәяли, крестьянга сак караш булырга тиешлекне аңлый, еш кына үз-үзенә һәм көрәштәшләренә «Дөрес эшлибез микән?» дигән сораулар бирә. Боларда яшь Фатихның совет хакимияте сәясәтенә карата икеләнүле карашлары чагыла.

Язучының тәүге романында сәнгати эшләнеш ягыннан кимчелекләр булса да, автор утызынчы елларның катлаулы каршылыгын тоя алган һәм геройларының психологик кичерешләре аша илдә барган тарихи-иҗтимагый әһәмияткә ия киеренке вазгыятьне чагылдыруга ирешкән. Әсәрдә еш кына Сталинның крестьян хәлен аңламавы да әйтелә. «Җир тыңлый» романының совет идеологиясенә туры килмәве, рәсми тәнкыйтьнең әсәрне ни өчен кискен кире кагуы шуның белән аңлатыла.

Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» повесте (1942) Бөек Ватан сугышы чорында сәнгать әһелләренә милли символларны, традицияләрне патриотик максатларда куллану рөхсәт ителгән дәвердә язылa. Әлеге әсәр әдип иҗатында гына түгел, гомумән татар әдәбияты тарихында күренекле урын алый. Сайланган сюжет, аның белән тел-стиль, сурәтләү чараларының ярашуы, композицион бөтенлек һәм халыкчанлык – әлеге әсәрне сүз сәнгатенең гүзәл җәүһәрләре рәтенә куя. Кимчелексез уңай герой турында сүз барганда, әдәбиятны шаулатып, Айдар кебек дуамал, бунтарь, кыю һәм каршылыклы геройның пәйда булуы үзе бер вакыйга саналырлык. Айдар образын әдипнең татар әдәбияты тарихында моңарчы күрелмәгән табышы диярге мөмкин. Әсәр нигезенә мәхәббәт тарихы салынган: сүз Айдар белән Вәсиләнең бербереенә эчкерсез саф мәхәббәте турында бара.

Повесть алма сатучы килү вакыйгасы белән башланып китә. Бөтен авылга алма исе тарала. Кечкенә Айдарның күңелен,

алмасыннан бигрәк, алма сатучының кызы билэп ала. Кызчыкның малайга алма ыргытуы да тикмәгә түгел: алма – матурлык, сафлык, сөю символы. Әсәр башындагы лирик күтәренкелек психологик киеренкелек белән алмашына һәм ахыргача шул халәт дәвам итә.

Айдар – катлаулы образ. Авторның «Үрнәк булырлык язмышмы соң бу, диярләр миңа акыллы башлы тәнкыйтьчеләр. Алдан ук әйтәм, түгел. Киресенчә, аның күп кенә яклары минем үземә дә ошамый. Ләкин тормыш – шуның өчен дә тормыш ул, аның законнары минем яки синең кәеф белән генә исәпләшеп тора алмый. Әйе, тормышта Айдарлар да бар. Үрнәкме алар, түгелме? Ләкин андыйлар бар һәм, димәк, тормышның бүтән яклары белән бергә, аларның да җырга кереп калырга хаклары бар» [Хөсни, 1988, б. 13], дигән сүзләре авторның кешегә партия карарларын үтәүче иҗтимагый продукт итеп кенә түгел, иң беренче чиратта бәхеткә лаеклы шәхес итеп каравын күрсәтә.

Бер караганда, Айдарның холкы, уйламыйча кылган эшгамәлләре, сөйгәнен, якыннарын борчуга салуы нәфрәт кенә тудырырга тиеш кебек, әмма киресе – аның эчкерсезлеге, гаделсезлеккә аяусыз протесты, кыюлыгы, ил алдында батырлыгы укучыда соклану тудыра. Бу, аеруча, аның капма-каршысы булган Госман образы белән чагыштыруда күренә. Әсәр Айдарның көндәлек дәфтәре рәвешендә язылган, шунлыктан без башкалар турында аның сөйләве аша гына беләбез. Госманның хисләре, эчке дөньясы бирелмәсә дә, эш-гамәлләре, сүзләре аша аның нинди адәм булуын аңларга мөмкин. Кечкенәдән Айдарга карата аның күңелендә яшәп килгән көнчелек, хөсетлелек хисе үсә барып, ул ике яшь йөрәкне аерып кына калмый, үзен дә аянычлы, хурлыклы үлемгә дучар итә.

Повесть халыкчанлыгы, гадилеге, теленең байлыгы, геройларының эчкерсезлеге белән, күпләр билгеләп үткәнчә, татар әдәбияты тарихында йөзек кашыдай әһәмияткә ия әсәр булды. Әлеге әсәре белән Ф. Хөсни прозаик буларак җитлегүен, тагы да югарырак иҗат мөмкинлекләренә ия икәнлеген күрсәтте.

60 нчы елларда барлыкка килгән демократик үзгәрешләрдән файдаланып, Ф. Хөсни колхозлашу темасына кабаттан әйләнеп кайта: эчтәлеге, проблеманың башкача куелуы белән «Җир тыңлый»дан аерылып торган, әмма кайбер геройларын кабатлап, «Утызынчы ел» (1958–1962) романын иҗат итә. Әсәр, совет әдәбиятына хас сыйнфый позициядән чыгып язылуына карамастан, үз чорының башкалар игътибарга алырга батырчылык итмәгән якларын яктыртуы белән әһәмиятле. Ф. Хөсни илдә барган үзгәрешләрне катлаулы вакыйгалар яссылыгында түгел, ә, иң беренче чиратта, кеше җанында барлыкка килгән каршылыклы уй-фикерләр, психологик детальләр ярдәмендә җиткерә.

Романда төп образларның берсе булган ячейка секретаре Котдус Вафинның сәяси эшчәнлеге белән мәхәббәт тарихы

үрелеп бара, әсәр ахырына таба мәхәббәт сызыгы гына калдырыла. Ф. Хөсни аның мисалында революцион аскетизмга кискен каршы чыга һәм кешенең шәхси бәхетен барыннан да өстен куя. «Җир тыңлый»да Вафин тагы да аянычлырак язмышка дучар ителгән була: үз белдеге белән мәчет манарасына әләм кадаган егетне авыл кешеләре кыйнап, манарадан ыргыталар.

Эпилог күтәренке рухта тәмамлануга карамастан, күңелдә моңлы сагыш утырып кала. Чөнки әсәргә башта ук дуамал холкы белән килеп кергән, кәҗәсеннән башка югалтыр әйбере булмаганга колхозга керүдән откан Гайниядән башкалар бәхеткә ирешә алмый: Нажия белән Котдус та кавышмый, Касыймның да тормышы барып чыкмый. Әсәрнең объектив эчтәлеге әлеге елларда илнең асты-өскә килеп, халык өстеннән сәяси-икътисади тәҗрибә-экспериментлар үткәрүнең фаҗигагә илтүен күрсәтә. Ул, колхозлашу күренешенең гыйбрәтле нәтиҗәләрен әйтеп, чор идеологиясенең хаксызлыгына ишарә ясый, соцреализм кысаларында да объектив чынбарлыкны сурәтләүгә ирешә. Әсәр колхозлашуның халык өчен рухи тетрәнүләр китерүен, социаль бәрелешләрнең бер милләт вәкилләрен бер-берсенә каршы куюын сурәтләве белән тарихи әһәмияткә ия.

Ф. Хөсни – татар әдәбиятында хикәя жанрын яңа баскычка күтәргән әдип. Ул төзелеше белән камил, идея-сәнгати яктан да үрнәк саналырлык дистәләрчә хикәя иҗат итте. Аларның күбесе новелла төренә карый. Новелла хикәядән сюжетның үткенлеге, композицион төгәллеге һәм күләм ягыннан җыйнак булуы белән аерылыбрак тора. «Хикәя дөньясында ул суга җибәргән балык. Татар әдәбиятына ул бары тик Ф. Хөснигә генә хас бик үзенчәлекле хикәя жанры алып килде. Үзенә махсус теле белән, үзенә махсус дөньясы белән бу хикәяләр укучының мәхәббәтен бик тиз казандылар» [Гази, б. 6] дип яза Ибраһим Гази алар турында.

Ф. Хөсни үзе исән чакта төзегән сайланма әсәрләрендә хикәяләрен хронологик яктан аера: сугышка кадәрге, сугыш чоры, сугыштан соңгыларга. Болай бүлеп карау язучының иҗади үсеш үзенчәлекләрен билгеләргә генә түгел, хикәяләрне гомум иҗтимагый-сәяси яссылыкта карау өчен дә уңайлы. Язучы утызынчы елларда аеруча актив эшли, бер-бер артлы «Хикәяләр» (1934), «Ана хикәясе» һәм башка новеллалар» (1936), «Минем күгәрченнәрем» (1938) җыентыкларын бастырып чыгара. Ә. Еники Ф. Хөснинең стиль үзенчәлеген билгеләп, «Сез аның кайсы гына әсәрен алып укымагыз, нечкә лиризм белән шат юморның, игезәк балалар шикелле, һәр җөмләсендә диярлек янәшә торуын күрерсез», ди [Еники, б. 50]. Халыкның милли юморына һәм хис-кичерешләр дулкынына корылган Ф. Хөсни стиле сугышка кадәр үк формалаша. Хәтта вульгар социологизм хакимлек иткән дәвердә язылган хикәяләреннән дә аның милли рух бөркелә. Милләт хакында турыдан-туры язарга

мөмкин булмаганлыктан, язучы миллилекне форма аша бирә. «Парикмахерскийда» (1935), «Чакыру билеты» (1937), «Сабирҗан абзый» (1939) «Кабак» (1940) хикәяләрендә милли сурәт чаралары кулланyы, мәзәкчән автор хикәяләве, геройлар сөйләме, психологизмның эчке монолог аша бирүе белән ул нәкъ менә татар холкын чагылдыруга ирешә. Шул рәвешчә, автор партия таләп иткән кысаларга гына сыешмыйча, утызынчы еллар әдәбиятын милли геройлар белән баета.

Бөек Ватан сугышы елларында татар хикәясе сюжет-композиция ягыннан да, стиль ягыннан да алга китә. Монда аның оператив һәм җыйнак жанр булуы зур роль уйный һәм, шулай ук, патриотик максатларда милли символларны, традицион образларны кулланырга рөхсәт ителүдә файдага була. Н. Гыйззәтуллин билгеләгәнчә, «Бу еллардагы татар прозасында ачык билгеләнгән ике стиль юнәлеше күренде: беренчесе – героик характерны катлаулы вакыйгаларда күрсәтү һәм шушы максатларда сюжетны төп чара итеп куллану булса (мәсәлән, Г. Әпсәләмов хикәяләрендә), икенчесе – совет кешесенең сугыш елларындагы эчке кичерешләрен бөтен нюанслары белән бирергә, «кеше рухының диалектикасын» ачарга омтылудан гыйбарәт иде (Ә. Еники, Ф. Хөсни һ.б.)» [Гыйззәтуллин, Социалистик Татарстан]. Әлеге икенче юнәлеш психологик алымнар аша гуманлылык идеяләрен алгы планга чыгара. Ф. Хөсни дә әдәбиятның үзәгендә Кеше, аның язмышы, хис-кичерешләре торырга тиеш дигән иманына тугры калып, сугыш чоры хикәяләрендә сугышны кешелекне җимерүче афәт, ә кеше гомерен исә берни белән алыштыргысыз кыйммәт итеп күрсәтә. Шуңа без, татар әдәбиятында 60 нчы елларда барлыкка килгән яңарышның яралгылары сугыш чоры әсәрләрендә, аерым алганда, Ә. Еники һәм Ф. Хөсни иҗатында күренә башлый, дип әйтә алабыз [Сверигин, Казан утлары, б. 131], [Заһидуллина, б. 157]. Тормышның кырыс шартларында да кешеләр арасындагы иң матур сыйфатлар – дуслык, туганлык, мәхәббәт, бер-береңә хөрмәт хисләрен саклап калу әлеге язучылар иҗатында төп мотивлар булып тора.

Р. Сверигин Ф. Хөсни иҗатында ике юнәлешне билгели: «Аларның берсе – кешенең рухи дөньясын тирәнрәк сурәтләүгә омтылыш, икенчесе – тасвирлау техникасының югарылыгына нигезләнгән, тормышның бигүк җитди мәсьәләләрен күтәрмичә генә, җиңел, көлке хәлләр, яисә характерлар комизмы рәвешендәге юмор» [Сверигин, 1989, б. 135]. Язучының сугыштан соңгы хикәяләрендә әлеге ике юнәлеш аерымлыгы тагы да ачыграк күренә. Сугыш китергән бәла-казаларның кеше язмышына тәэсире тормыш-яшәеш турында төптәнрәк уйларга, әсәрнең фәлсәфи киңлегенә, психологизмның тирәнәюенә китерә. «Хат» (1959), «Моң» (1960), «Бәдретдин» (1968), «Ананың үз сүзе» (1976) хикәяләрендә язучы физик һәм рухи имгәтелгән җаннарның күңел әрнүен лирик һәм

психологик детальләр аша уңышлы тасвирлый. «Хат» хикәясе, мәсәлән, сугыш фаҗигасен тормышчан ачы хакыйкате, тетрәндергеч хис-кичерешләре белән күз алдына китереп бастыра. Ике фронт госпитальләренең берсендә ата, икенчесендә аның улы ята. Берсе – контузия алган, икенчесенең – аягын кискәннәр. Улы әтисенә дөньядан туюы, үз-үзенә кул саласы килүе турында хат язган. Ф. Хөсни геройның психологик халәтен хәрәкәтләре аша бирү осталыгына ия. Бу әсәрендә дә ата кешенең бәргәләнүләре, күңел газабы, шул ук вакытта аның рухи ныклыгы хәрәкәтләре аша сурәтләнә. Майор Ташбулатов күңеленнән улына хат яза. Бу хатта ата кешенең газизен өзелеп яратуы да, тормыш сынавына бирешүенә шелтәсе дә бар. Улына мәрхүмә әнисен, балачагын, ошатып йөргән кызын искә төшерүе дә яшәүгә өмет уяту максатында. Гади сөйләм телендәге кечкенә генә хатта тормыш фәлсәфәсе күтәрелә. Шул рәвешчә автор сугыш китергән газапларның иң зурысы, фаҗигасе – кеше язмышын җимерүдә дип белдерә.

Ф. Хөсни үз тәҗрибәсен башкалар белән бүлешүне, яшьләргә, башлап язучыларга киңәшләрен бирүне мөһим бурычы дип саный. Матбугат битләрендәге күпсанлы мәкаләләре, «Уйланулар» (1961), «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» (1974), «Карурманга керәм» (1985) китаплары аның әдәби-теоретик карашларының киңлеген, рус һәм дөнья әдәбиятын яхшы белүен, тугандаш һәм күрше халыклар әдәбияты белән даими кызыксынып торуын дәлилли. Тәнкыйди һәм публицистик язмалары аша язучының төрле мәсьәләләргә юнәлтелгән карашларын һәм, гомумән, дөньяны кабул итүен, иҗат позициясен ачыкларга мөмкин. Бу исә әдипне тагы да ныграк аңларга ярдәм итә.

Ф. Хөсни халкыбызның җанлы сөйләм телен үстерүгә дә зур өлеш керткән әдип. «Телнең аһәңлеге, музыкаль яңгырашы әсәрне йогынтылы итүдә кечкенә роль уйнамый. Ул, беренче җәһәттә, фикернең төгәл уйланылган булуыннан килсә, икенче яктан, шундый ук дәрәҗәдә, телебезнең, аның синтаксик төзелешенең гармонияле агышыннан килеп туа», ди язучы [Хөсни, 1985, б. 188]. Һәр җөмләгә, сүзгә олы мәгънә биреп, тел закончалыкларын яхшы аңлап эш итүе, сингармонизмны саклавы һәм эчке ритмны нечкә тоемлавы аның әсәрләренең музыкальлеген хасил итә.

«Ф. Хөсни иҗатын бәяләүчеләр хаклы рәвештә, аның олылыгын, иң беренче нәүбәттә, милләт җанлы булуында, милли характерда, милли рухта язылган әсәрләрендә күрделәр», – дип яза Р. Сверигин [Сверигин, 2008, б. 131]. Чыннан да, Ф. Хөсни әдәбиятны бары милли йөзле итеп күзаллый. Әдәбиятны гына да түгел, гомумән, сәнгать «кайсы халыкныкы гына булмасын, ул шул халыкның җанын, психологиясен ачарга тиеш, бу – аңардан беренче чиратта сорала торган миссия!» дигән караштa тора ул [Хөсни, 1985 б. 64]. Әдипнең кыю фикерләре космополитизм тарафдарларына каршы

чыгышларында да күренә. XX гасырның алтмышынчы елларында аеруча киң яңгыраш алган әлеге караш миллилекне кире кага, кешене гомумдөнья – планета гражданы итеп саный. Ф. Хөсни Николай Задорновның РСФСР язучылары съезды алдыннан «Литературная газета»да басылган «Күптән вакыт» мәкаләсендәге «Әдәбиятта милли колоритны аерым шарт итеп кую билгеле бер дәрәҗәдә ясалмалык кына ул» дигән фикеренә кискен каршы чыга. Ул, әлеге чыгышта ике зур гөнаһлы фикер урын ала, дип белдерә: «Беренчедән, халыкларның милли колоритын байбәтчәләрчә санга сукмаска маташу. Ә колоритны санга сукмау, шул исәптән милли колоритны чүплек башына ыргытып бәрергә омтылу малайларча «суллашып» маташудан бүтән берни дә түгел ул. Икенчедән, милли колоритны инкарь итәргә тырышып ясалган андый акыл сатуларда безнең илебездәге халыкларның әдәбиятларын бер селтәнү белән «унификацияләргә» азаплану, димәк ки, совет әдәбиятын күп бизәклелек сыйфатыннан мәхрүм итәргә маташу яшеренеп ята» [Хөсни, 1985, б. 92]. Әлбәттә, Ф. Хөсни космополитизм төшенчәсе астында да милләтләрне руслаштыру сәясәте ятканлыгын яхшы аңлый.

XX йөз башында сулышы ачылып киткән татар милләтенә совет хөкүмәте яңа богаулар сала. Милли идея төбе-тамыры белән юкка чыгарылырга тиеш була. Коммунистлар партиясе советчыл аң тәрбияләүдә халыкны рухи азык белән туендыручы әдәбият-сәнгать әһелләрен оста файдалана. Иҗат кешесе катлаулы сынау үтә: бер яктан аны коммунистик идеологияне пропагандаларга мәҗбүр итүче дәүләт китереп кыса, икенче якта аңа гасырлар буе чарланып килгән телен, моңын, рухын сеңдергән газиз милләте тора. Дөрес, бу аянычлы тарихи сынауны бар да тигез генә үтми. Әмма ни генә булса да, бу дәвер әдипләрен без аерым бер хөрмәт һәм аңлау белән өйрәнергә тиешбез. Чөнки нәкъ менә алар XX йөз башында үсеш алган милли рухны, совет чоры аша саклап килеп, 90 нчы еллар яңарышына китереп җиткерде. Халыкның телен, рухын, күңел байлыгын тулыландырып, хәтерен саклап торган бу күпернең имән баганаларын Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Бәширов, С. Баттал кебек олпат язучылар һәм аларның сүз сәнгате өлкәсендәге эшчәнлеге тәшкил итә. Алар ил сәясәтенә каршы килмәстән, шул ук вакытта милли асылыбызны саклауга күп көч куйган фидакарь затлар. Тик әлегә аларның хезмәтләренә тиешле игътибарны биреп җиткермибез кебек. Ф. Хөснинең, мәсәлән, 1966–1968 елларда басылган өчтомлыгыннан кала, бүтән күптомлыклары чыкмаган. Аерым сайланма әсәрләре дә сиксәненче еллардан соң берничә тапкыр гына дөнья күргән. Ә бит Ф. Хөсни кебек инсафлы, әхлаклы юмор иясе, тел нечкәлекләрен һәр күзәнәге белән тоеп, прозага да шигъри аһәң бирә белгән язучылар хәзер юк дәрәҗәсендә. Аның иҗаты хәзерге әдипләребезгә әсәрләренең телен һәм стилен сәнгати

югарылыкка күтәрүдә үрнәк-өлге вазифасын үти ала.

Якын киләчәктә Ф. Хөснинең күптомлыгы нәшер ителүенә өмет бар. Аларга язучының латин шрифтында калган әсәрләрен, вакытлы матбугатта басылып чыккан китапларына кермәгән мәкаләләрен, хикәяләрен дә туплыйсы иде. Шулай ук томлыкка әдипнең Сәгыйть Хафизов «реалистик, демократик асыллы әдәбиятның геноцид режимлы сталинизм тарафыннан аяусыз тыелып, таркатылуына ачык мисал ул» [Хафизов] дип бәяләгән «Җир тыңлый» романы да кертелер дип ышанам. Сүзне йомгаклап шуны әйтәсе килә: Ф. Хөсни иҗаты гаять бай, үзенчәлекле, мавыктыргыч һәм нәфис. Вакытлар үткәнгә карап, аның чын сәнгать җәүһәрләре булган әсәрләре халкыбызның рухи хәзинәсен тәшкил итүдән туктамый. Үткәннәрне өйрәнеп, олпат әдипләребез иҗаты белән күңелләребезне баетып кына без алга бара алачакбыз.

**Әдәбият**

*Гази И.* Фатих Хөсни // Хөсни Ф. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 1 т.: Хикәяләр. 474 б.

*Гыйззәтуллин Н.* Хикәяләр остасы // Социалистик Татарстан. 1967. 30 апр.

*Еники Ә.* Безнең Фатих // Казан утлары. 1968. № 2. Б. 49–50.

«Җир тыңлый» романы турында: ТАПП секретариатының карары // Атака. 1931. № 7. Б. 41–43.

*Заһидуллина Д.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 157 б.

*Сверигин Р.* Фатих Хөсни. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

*Сверигин Р.* Фатих Хөсни феномены // Казан утлары. 2008. № 2. Б. 128–134.

*Хафизов С.* Гаугалы роман // Социалистик Татарстан. 1991. 2 август.

*Хөсни Ф.* Йөзек кашы // Бер яшьлектә, бер картлыкта: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр, 1988. 496 б.

*Хөсни Ф.* Карурманга керәм: иҗат психологиясе һәм иҗатның кайбер башка мәсьәләләренә кагылышлы этюдлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 198 б.

*Хөсни Ф.* Минем тәрәзәләрем. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 272 б.

***Ганиева Айгөл Фирдинант кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Л.Р. Надыршина*

# ӘХСӘН БАЯНОВ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТӨП ТЕМАЛАР ҺӘМ МОТИВЛАР

В статье рассматриваются ключевые темы и мотивы в лирике Ахсана Баянова. В ходе анализа выявляются основные тенденции развития творчества поэта. В начале творческой деятельности в лирике Ахсана Баянова преобладают темы любви, родины, семьи и др., характерные для интимной лирики, и мотивы, традиционные для татарской литературы. Со второй половины 1960-х годов в стихах автора углубляется философское начало, усиливается их метафорический, ассоциативный характер. В середине 1980-х годов автор все больше обращается к социально-политическим мотивам, основными темами в произведениях этого периода становятся темы национальной истории, государственности и др.

**Ключевые слова:** Ахсан Баянов, татарская поэзия, тема, мотив, образы, литература.

Әхсән Баянов әдәбиятка җәмгыятьтә яңарышка омтылыш көчәйгән вакытта килә. Аның иҗаты эчтәлек һәм форма өлкәсендәге эзләнүләре, әсәрләренең лирик-фәлсәфи тирәнлеге, сурәтләү алымнарының төрлелеге, шартлы-символик образларга еш мөрәҗәгать итүе белән аерылып тора. «Әхсән Баянга туктаусыз эзләнү хас», дип билгели С. Хәким [Хәким, б. 10]. Дөрестән дә, әдип каләмен әдәбиятның төрле жанрларында сынап карый, лирика, проза һәм драматургиядә үзенә генә хас иҗат стиле тоемланган үрнәкләр тудыра.

Ә. Баянов иҗаты лирик геройның мәхәббәт, дуслык, табигатьне зурлау, аңа соклану, туган якны сагыну хисенә бәйле шәхси кичерешләр дөньясын чагылдырган күңел лирикасына бай. Әсәрләрендә милли шигърияттә традицион булган Идел, ай, көймә, сандугач, ак каен, җил, җыр, биек һәм горур тау, икмәк һ.б. образлар киң кулланыла, табигый гүзәллек, лирик кичерешләр, хисләр сафлыгы тасвирлана. Әйтик, романтик рух белән сугарылган интим лирика үрнәкләрендә герой күңел серләрен Иделгә сөйли («Ул тыңлар», 1954), сөйгән ярын иркә күгәрчен белән чагыштыра («Яшермә син, иркәм, серләреңне...», 1954), аңа булган мәхәббәтен туган якны яратудан да өстенрәк куя («Ник ашкынып китәм туган җирдән?», 1954), сөюен бар дөньяга хәбәр итәргә тели («Бер генә сүз беләминем йөрәк...», 1951). Гомумән, шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында романтик рух өстенлек ала, аның лирик герое кайнар хисләр белән яна, мәхәббәт кешене яшәтә, рухын үстерә торган бер көч дип саный («Шаулаcàкичен агачлар...», 1951–1973; «Чиксез иде сиңа әйтер сүзем», 1951; «Ишетелсә кичен синең...», 1951 һ.б.). Яшьлек ашкынуы ачык тоемланган романтик аһәңнәр,

соңрак, психологик кичерешләр лирик геройның катлаулы күңел дөньясын, хисләрнең иң нечкә төсмерләрен ачып бирү омтылышы белән алышына. «Мин кич белән килдем сиңа...» (1964), «Күк самолет алып китте сине...» (1965), «Горурлыгым, ирлегемне онытып...» (1971), «Тәрәзәң ачыла үткәнгә, бүгенгә...» (1971), «Кичер» (1974), «Аерылышу» (1976) кебек шигырьләрендә шагыйрьнең лирик герое мәхәббәтнең катлаулы табигатен фәлсәфи уйланулар яссылыгында ача.

Ә. Баяновның күңел лирикасында зур урын алып торган һәм иҗатын иңләп узган тагын бер тема – ул туган як темасы. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «туган җиргә җылы һәм ихлас мөнәсәбәт һәр шагыйрьнең иҗатында күзәтелеп, туган як темасы 1960–1980 еллар татар поэзиясенең әйдәп баручы темаларына әверелә» [Заһидуллина, б. 12]. Ә. Баянов шигъриятендә әлеге тема эчендә туган авыл, әни, нигез, Идел һ.б. образлар идеаллаштырыла, туган якның матурлыгын раслау, күңелгә якынлыгын аңлау, аны сагыну шагыйрьнең үзе кебек кабул ителгән лирик геройның үкенүле уйлары аша сурәтләнә. Шигырьләрендә барлык уйларның, юлларның туган якка юнәлгәнлеге белән бәйле мәңгелеккә кайту мотивы, туган җирне яратуның кеше күңелен җылытуы кебек хисси фикерләр күтәрелә («Туган җирләр ерак миннән...», 1960; «Уйладым да кабат кайтасымны...», 1967), туган авыл образы лирик геройның иң якты, иң ихлас балачак хатирәләре белән бәйләп сурәтләнә, сагышлы сагыну хисе белән өртелә («Бу җирләрдә минем исем белән...», 1974), кайбер әсәрләрендә туган җир лирик герой белән әңгәмә кора һәм балаларын һәрвакыт кичергән, аларның кайтуын сорап ялварган ана образы белән тәңгәлләшә («Туган җирем, без икәү бит...», 1967; «Инде бер дә китмә», 1976). Әдип иҗатында туган җир образы, нигездә, хәтер мотивы аша үткәннәрне тергезә, лирик герой күңелен фәлсәфи уйланулар били, туган як – Җир янәшәлеге әдип әсәрләренең гомумиләштерү көчен арттыра, яшәеш, укучыны заман турындагы уйлануларга этәрә. Мәсәлән, «Чаң» (1965) шигырендә күпме еллар лирик геройга тынгы бирмәгән чаң тавышы – имәнгә эленгән сабан калагы – Җир авазына тәңгәлләшә. Беренче карашка туган җир темасына кагылышлы хатирәләр рәвешендә иҗат ителгән шигырьдә чорга хас иҗтимагый-сәяси вазгыятькә, заманга, халык яшәешенә ишарә иткән бердәмлек, көрәшкә чыгу турындагы фәлсәфи фикер тоемлана.

Гомумән, 1960 елларның икенче яртысыннан башлап, Ә. Баянов шигърияте сыйфат үзгәреше кичерә, бу, иң беренче чиратта, аның әсәрләрендә фәлсәфи фикер көчәюе белән билгеләнә. Аларда кеше һәм галәм, шәхеснең үз-үзен һәм яшәешне танып белү омтылышы алга чыга. Аның лирик герое уйланучан, яшәештәге күренешләрнең асылын аңларга омтылучы, көтелмәгән янәшәлекләр табарга сәләтле, тирән гамьле шәхес буларак күзаллана. Бер төркем

шигырьләрендә фәлсәфилек аерым детальләрдә табыла. Әйтик, «Көзнең тын сурәте» (1966) дип исемләнгән шигырьдә кыр казларының чит илләргә юл алуына бәйле уйланулар гомернең тиз узып китүе хакында искәртә, «Күкләр нигә зәңгәр» (1969) шигырендә хәзерге буынның якты гүзәл яшәеше хакына ата-бабаларның фидакарь хезмәте, каһарманлыгы, гомерләрен корбан итүләре сәнгати формага төреп аңлатыла. «Балачак җәе» (1985), «Әни сагышы» (1985), «Әни төсе» (1985), «Йокысыз төндә» (1985) кебек шигырьләрдә лирик геройның хис-кичерешләре әниле балачакның иң бәхетле чор булуын уйлап юксынуга, вакытның котылгысыз агышында әниләрнең мәңгелеккә китеп баруларын аңлаудан туган үкенүле сагышка, авыр чакларда, әниләрне төштә булса да күреп, җан сызлавының рәхәт җылылык белән алмашынуына әверелә, экзистенциаль укылыш алгы планга чыга.

Ә. Баянов иҗатында кеше фәлсәфәсен, шәхеснең яшәеш белән катлаулы, каршылыклы мөнәсәбәтләрен ачыклаган шигырьләр бер бәйләм хасил итә. Аларда лирик геройның үз язмышы хакындагы уйланулары, кешенең үз асылын, тамырларын, яшәү мәгънәсен табуга омтылышы чагыла. Мәсәлән, «Абынуым – гадәт бала чактан...» (1967) шигырендә кешене хыял яшәтүе, алга барырга көч бирүе турындагы уйланулар, адәм баласының үзе теләп алдануы, хыял дөньясында күңеленә юаныч табарга омтылуы хакындагы фикер укыла. «Җирдә Прометей бар» (1977) шигырендә исә Гермес һәм Прометей каршылыгы дөньяга, яшәешкә капма-каршы карашларны гәүдәләндерә, бу ике образ ярдәмендә ялчылыкта узган шат гомердән җирдәге яктылык, матурлык хакына яшәлгән бер көннең артыграк булуын раслаган югары рухтагы идея үткәрелә. «Демон» (1979) шигырендә, кеше күңелендә барган мәңгелек көрәш турындагы фикерләү кысаларында, лирик геройны көне-төне саклап торган күләгә архетибы – икенче «мин» аның хисләрен тезгенләп торучы образ буларак сурәтләнә, һәм кеше күңелендәге бу бәхәс-көрәш мәңгелек, котылгысыз, димәк, адәм баласы яшәеш кануннарын үзгәртергә сәләтсез, дигән фикер яңгырый. «Җирдә яшәү мөмкин төрлечә...» (1988) әсәрендә кеше фәлсәфәсе Алла һәм Иблис төшенчәләре белән уйнау нәтиҗәсендә ачыла. Бу яшәештә Аллага да, Иблискә дә түгел, кешегә генә ышануын белдергән лирик герой, бер яктан, шәхеснең бөеклеген раслый, кеше фәлсәфәсен көчле шәхес концепциясе кысаларында кабул итә кебек тоела. Әмма шигырьнең соңгы юллары башка эчтәлектәге укылышка юл ача: биредә Алла / Иблис дуалистик каршылыгы кешенең эчке асыл йөзен ачып бирә. Кеше үзе – Алла, үзе – Иблис дигән идея ассызыклана.

Ә. Баянов шигъриятендә һәрвакытта да каршылыкларны, авырлыкларны җиңәргә үзендә көч тапкан образлар зурлана, лирик герой башкаларны да шундый булырга өнди. Әлеге фикер

кульминациясе рәвешендә иҗат ителгән «Җиңәргә тиеш» (1968) шигырендә рәнҗетү, кыерсытуларга каршы сүз әйтә алган, гаделлекне киләсе буыннарга җиткергән шәхес зурлана. Гамәле белән көчле шәхесләр генә тарихта якты эз калдыруы хакындагы фикер, милли эчтәлек алып, шагыйрьнең үз халкына мөрәҗәгате дә булып аңлашыла.

Лирик геройның күңел газапларын тергезгән бер бәйләм шигырьләрдә кеше гомеренең тиз үтүчәнлеге, аның чынга ашмаган хыяллар, буш өметләр, алданулар белән тулы булуы хакындагы экзистенциаль мотивлар сәнгатьчә гәүдәләнеш ала («Яшь көннәр узган, чыр-чулар тынган...», 1979; «Җил сурәте», 1983; «Сәмруг кош», 1997; «Мин – җил түгел», 1998 һ.б.). Мисал өчен, «Яшь көннәр узган, чыр-чулар тынган...» (1979) шигыренең беренче юлында ук яшьлеге узганлыгын аңлаудан сызланулы уйларга бирелгән лирик герой образы тудырыла. Ухылдаган елга, шыңшып яткан көз, буш кабырчыкларның тавышсыз сагыш белән ассоциацияләшүе, тавышлы сагыш булып ишетелгән дәвер белән хушлашу кайтавазы, импрессионистик рухтагы образлар ярдәмендә, экзистенциаль аһәң тудыра һәм ул, көчәйтелеп, лирик герой үз тормышының тарихтан төшеп калуын аңлаган халәттә кала. Күңел халәтен бүлеп килеп кергән төш мотивы (елганың еракта калган «чайкалган чая, уйсыз көннәре» турындагы төше) яшьлекнең күз ачып йомганчы шаулап үтеп китүенә ишарә итә. Сызлану фәлсәфәсенә хас төшенкелек, гомернең чикләнгәнлеге, вакыт агышының котылгысызлыгын аңлау «Җил сурәте» (1983) шигырендә дә, төп лейтмотив булып, һәр строфаны кисеп уза. Әсәрнең исеменә чыгарылган җил образы үзе үк һәр нәрсәнең вакытлы булуына ишарә итә, соңгы строфада җил һәм моң янәшәлеге үткәрелү экзистенциаль сызлануны көчәйтә, гомернең үтүен, бер нәрсәнең дә мәңгелек булмавын, яшьлек ашкынуталпынышларының кайчан да булса бер сүнүен шәрехли:

Гомер буе ясаганбыз ләкин
Тик бер генә сурәт – җил сурәте.
Яфрак, агач, учакларны җыйнап,
Калды моң сурәте –
Җил сурәте... [Баянов, б. 224].

Ә. Баянов иҗаты, фәлсәфи яктан тирәнәя барып, гомумиләшеп, яшәеш, кешелек турындагы уйлануларга күтәрелә. Лирик герой инде үзен бөтен Җир каршында җаваплы тоя, гасырлардан гасырларга, киләчәк буыннарга калачак мирас турында уйлана, шигырьләрдә кеше һәм галәм фәлсәфәсе сәнгати үстерелә. «Җиргә карап торам» (1964), «Безнең күгебез» (1965), «Гомер – биек тау бугай ул...» (1968), «Рәнҗемә, Ай» (1974), «Ялангач ай» (1979), «Җир – җиһанда берәү генә...» (1982) кебек шигырьләрдә бөтен Галәм, Җир яшәеше өчен үзен җаваплы тойган лирик геройның гаме җирдәге караңгылык, ямьсезлек, гаделсезлекнең сәбәбен эзләүгә юнәлә. Мәсәлән, «Җиргә карап торам» (1964) шигырендә төп композицион алым буларак кулланылган антитеза лирик герой

хозурына җиһанның дуалистик картинасын ача: җирдә яхшылык һәм явызлык, матурлык һәм ямьсезлекнең мәңге янәшә яшәве сәнгати образлар белән үтемле итеп җиткерелә. Сибелгән чәчәк һәм буран, вулкан һәм салкын чишмә, котырган океан һәм тын кыр һ.б. кебек табигый каршылыклар санап кителгәннән соң, көтелмәгән янәшәлекләр сискәндереп җибәрә: иген чәчкән трактор һәм сигнал көтеп торган ракеталар, бомба сузган һәм кызга сирень биргән куллар җирдәге яшәеш турында уйландыра. Шигырьнең соңгы юллары фәлсәфи нәтиҗә, гомумиләштерү буларак укыла:

Сак бул, әнкәм-җирем!
Синдә бер үк өйдә
Мәхәббәт һәм үлем [Баянов, б. 55].

Ә. Баяновның лирик герое, еш кына, яшәеш белән дисгармония халәтендә гомер кичерә. Бу – әдип иҗатында үткәннәрне идеаллаштыру тенденциясенең төп сәнгати принципларның берсе булуына китерә. Лирик герой һәрвакытта да хәзерге яшәешкә ят табигыйлекне, әхлак кануннарын, кешелеклелекне әүвәлге дәверләрдән эзли, бу исә, үз чиратында, шигырьләрдә цивилизация һәм табигать, үткән һәм бүгенге каршылыкларга нигезләнгән дөнья сурәте тудыра. Әлеге каршылык хәзерге яшәешкә тәнкыйди бәя булып яңгырый. «Таш легенда» (1975), «Көзге кыйпылчыгы» (1975), «Атлар карап кала» (1975), «Юлчы ишетмәде» (1975), «Көч билгесе» (1975), «Их, син, дөнья, гөнаһлы дөнья...» (1994) кебек шигырьләрдә, мәсәлән, заманга хас глобальләштерү, шәһәрләштерү күренеше сагышлы моңсу хис белән өртелеп сурәтләнә. XX йөз ахырына таба татар әдәбиятында активлашкан «дөнья – базар» метафорик янәшәлеге «Кызлар чәче» (1971–1973) шигырендә төп сәнгати принцип буларак урын ала һәм әсәрнең идеясен билгеләүдә ачкыч ролен үти. Матурлык, сафлык, әхлаклылык символы булган чәч толымы образы ярдәмендә заманның файда, табыш алуга гына нигезләнгән җәмгыять тудыруы аңлатыла. «Кызыл ут» (1988) әсәрендә исә яңа заманның аерылгысыз атрибутларын – «машиналарга утырып чабучы Вакыт», «чырай сытып караучы тәрәзәләр», «биткә төтен һәм газ төкерүче машиналар»ны күрәбез. Шигырьдә Казан образы фәлсәфи эчтәлекле символ буларак сурәтләнә, җәмгыять, яшәеш моделе буларак тәкъдим ителә. Кызыл ут метафорасы, кабатланып, Казанның, димәк, кешелекнең, цивилизациянең юкка чыга баруына ишарә итә.

Әдип иҗатында гражданлык позициясен чагылдырган, иҗтимагый һәм сәяси мотивлар киң урын алган лирик әсәрләр бәйләме дә бар. Әсәрләрдәге иҗтимагый-сәяси мотивлар арасында татар әдәбиятында киң яктыртылган шагыйрь һәм шигърият темасы да бар. Аның «Була сүзләр» (1968), «Канатлы ат» (1979), «Үссен игеннәр» (1974–1975), «Муса Җәлилгә» (1983) кебек шигырьләрендә шагыйрь яшәешенең төп максаты халыкка хезмәт итүдә, җиргә матурлык орлыклары чәчүдә дип

билгеләнә, иҗат кешеләренең рухланып эшләргә, үз идеалларына ахырынача тугры калырга тиешлегенә басым ясала.

Әдипнең гражданлык позициясе милли тематика белән тыгыз үрелеп бара, әсәрләрендә халык, милләт язмышы, тарихыбыз, дәүләтчелегебез, телебез һ.б. шундый проблемалар көн кадагында торган мәсьәләләр буларак күтәрелә. Бу юнәлештә иҗат ителгән шигырьләрдән «Манара янында» (1969), «Урам көе» (1971–1973), «Болгарга сәяхәт» (1979), «Без – тарихта эзле...» (1994) кебек әсәрләрне атый алабыз. 1960–1970 еллар әсәрләрендә Ә. Баянов фәлсәфи эчтәлек белән үрелеп килгән милли яшәеш детальләрен сәнгати яктан үстерә, лирик геройның уй-гамьнәрендә бу детальләр символик эчтәлек белән баетыла. Шундыйлардан «Манара янында» (1969) әсәрендә Сөембикә манарасын күздә тотып иҗат ителгән манара образы лирик герой хыялында туган, милли ана архетибы буларак кабул ителгән татар хатынына торгызылган һәйкәлгә тиңләнә. Милли детальләр (ай, урак, кәшмир болыт-шәл) ярдәмендә татар халкы мәдәниятенә генә хас булган гүзәллек, күңел түренә үтеп кердәй бер моң тоемлана. «Тарих язабыз» (1988), «Саклый алсак» (1988) шигырьләрендә Россия тарихының хакыйкатьтән ерак булуына, гел үзгәртелеп торуына борчылу хисләре белән сугарылган фикерләр күтәрелә. «Челтәрләргә карап» (1971) шигырендә шагыйрь иҗтимагый-сәяси мотивларны бөтен кешелек яшәеше масштабына чыгара.

«Шәрә башлар» (1967), «Әүлиялар» (1967), «Кичәге дуска» (1968), «Әйләнмәле сәхнә» (1973), «Тарих ватыклары» (1974), «Җыелыштан соң» (1974), «Синең йөзең» (1982) һ.б. шигырьләрендә Ә. Баянов заманга, яшәешкә, чорга, иҗтимагый-сәяси вазгыятькә кискен тәнкыйди бәясен бирә.

Гомумән, Ә. Баянов лирикасында тема һәм мотивлар төрлелеге аның иҗатының гомуми үсеше белән бәйләнештә карала. Иҗатының башлангыч чорында мәхәббәт, туган як, гаилә кебек темалар һәм шуларны ачкан мотивлар киң урын алса, 1960 елларның икенче яртысында әдип шигърияте фәлсәфи мотивлар белән байый, 1980 елларның икенче яртысыннан Ә. Баянов иҗатында иҗтимагый-сәяси мотивлар көчәя, тарих, дәүләтчелек, туган тел темалары киң яктыртыла.

**Әдәбият**

*Баянов Ә.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 1 т.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.

*Хәким С.* Гел яктыга таба // Баянов Ә. Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002. 1 т. Б. 7–11.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Абдулкадир Чекич*

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИ ГЕГЕМОНИЯ ТЕМАСЫ

В представленной работе анализируются повести Аяза Гилязова «В пятницу вечером» и «Три аршина земли» с позиции навязывания советского режима татарскому народу согласно теории культурной гегемонии Антонио Грамши.

**Ключевые слова:** Аяз Гилязов, культурная гегемония, татарская литература, «Три аршина земли», «В пятницу вечером».

Италия галиме Антонио Грамши «мәдәни гегемония» теориясен тәкъдим итә. Ул үзенең «Тоткын дәфтәрләре» исемле эсселар җыентыгында гегемонияне субалтерннар, ягъни буйсынучылар өстеннән идеологик хакимлек итү дип билгели. Аның мәдәният турында көчләп тагылган яки норма буларак кабул ителгән күзаллаулары колониаль һәм постколониаль җәмгыятьләр белән бәйле, шулай ук антиколониаль хәрәкәт өчен үзәк проблемага әверелә. Аяз Гыйләҗев совет режимы изүе астында яшәүчеләр турында күпсанлы романнар һәм хикәяләр яза. Геройлар һәм вакыйгалар ярдәмендә ул Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы идеологик өстенлек итүче җәмгыятьне тасвирлый. Язучы романнарында төрле образлар аша, аеруча «Җомга көн кич белән» әсәрендә һәм башкаларда татар җәмгыятенең Совет хакимияте идеологик басымына каршы көрәшергә һәм үзенең милли рухын кире кайтарырга тырышуын күрсәтә.

Аяз Гыйләҗев 1928 елның салкын гыйнвар көнендә туа. Аның балачагы Югары Баграж авылында үтә. Бу авылга әтисен эш буенча җибәрәләр һәм алар шунда урнашып кала да. Әсәрләрендә А. Гыйләҗев бу авылны бик яратып искә ала. Ул чиркәү каршындагы йортта торган Әндриян дәдәйләрдә яшәүләре турында яза. Йорт артында зур гына бакча була, бакча башында Метри елгасы ага. Әтисе химия һәм биология укыта, бакчаларында помидор, кыяр, кишер һәм хәтта кавын-кабак та үстерә. Аяз Гыйләҗев «Балачак сукмаклары» истәлекләрендә бу авылның үзе өчен бик мөһим урын булганын искәртеп үтә: «Минем татлы, кадерле балачак истәлекләрем Җир шарының шушы нәни ноктасы белән бәйләнгән. Каршыда – бакча, уңда – мәктәп биналары, мәктәп каршысындагы киң генә мәйдан – миңа – шактый елгыр малайга – яшәү серләрен ачып биргән кадерле урыннар иде». Югары Баграж авылы малайның дөньяны танып-белүендә, үзенең татар, мөселман тамырларын аңлауда зур роль уйный.

А. Гыйләҗев Владимир Ульянов-Ленин, Лев Толстой кебек студентлары белән данлыклы булган Казан университетында

укый. Ләкин ул, татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укуын ташлап, эшли башлый һәм сәяхәт итә. Соңрак, укуга кире кайткач, 1950 елда аны кулга алалар. Язучы бераз Казан төрмәсендә утыра, аннан Казахстанга, ГУЛАГ лагерьларына озатыла, биш ел гомере төрмә һәм лагерьларда үтә.

Язучы университетта укыганда әдәби клубка йөри. Бирердә алар советлар илендә тормыш һәм сәясәт турында сөйләшәләр. Ләкин араларыннан берәүгә А. Гыйләҗевның фикерләре ошамый, ул аларны җитәкчеләргә җиткерә, әдипне, Сталинга каршы эш алып баруда гаепләп, кулга алалар. Сөргендәге тормышын ул «Ягез, бер дога» әсәрендә тасвирлый.

Иреккә чыккач, А. Гыйләҗев университетта укуын дәвам итә, театр белән кызыксына башлый һәм берничә пьеса яза. Әсәрләрендә ул совет идеологиясе яклы булып тоелса да, аның иҗаты башкаларныкыннан аерылып тора. Язучы совет сәясәтенә һәм Ленин-Сталин культына дан җырлаудан баш тарта, төп игътибарын татар халкының милли үзенчәлекләренә һәм татарларның большевиклар революциясеннән соңгы тормышына юнәлтә.

Антонио Грамши XX гасырда хакимлек структурасы һәм эшче сыйныфның урынын билгеләү өчен мәдәни гегемония теориясен тәкъдим итә; аның фикеренчә, хакимлек һәм хакимлек өчен көрәш һәрвакыт системада зур үзгәрешләр ясарга һәм шул ук вакытта аларны булдырмый калырга сәләтле фикер ияләре һәм идеология тирәсендә бара. Мәдәни гегемония термины хакимлек итүче сыйныфның үзенең иҗтимагый, рухи, сәяси һәм мәдәни кыйммәтләрен буйсынучыныкыннан өстен куюын белдерә. Хакимлек итүче катлауның юнәлеше яки идеологиясе халыкның күпчелеге тарафыннан кабул ителә. Шуннан чыгып, мәҗбүри тагылган идеология, җәмгыятьнең гадәти асылы буларак, тормышка ашырыла. Грамши: «Безнең эзләнүләрнең методологик критерие иҗтимагый группаның өстенлек итүе ике төрле юл – "өстенлек итү" һәм "интеллектуаль һәм мораль җитәкчелек итү" юлы белән башкарылуына нигезләнә» – ди [Gramsci, p. 193]. Шуңа күрә «интеллектуаль һәм мораль лидерлык»ның өстенлеге мәдәни гегемониянең үзен гәүдәләндерә. Моның белән генә чикләнмичә, Грамши гегемония урнаштыру өчен мөһим булган сәяси һәм гражданлык җәмгыятьләрен аерып карый. Бер яктан, гегемония аңа ярдәм итүче гражданлык җәмгыяте аша өстен группалар тарафыннан тормышка ашырыла, икенче яктан, өстенлек итүгә сәяси җәмгыять яки, Грамши билгеләмәсе белән атасак, «дәүләт» аша ирешелә. Мәдәни гегемониягә килгәндә, Грамши: «Интеллигенция – иҗтимагый гегемониянең һәм сәяси хакимиятнең буйсыну функциясен тормышка ашыручы өстенлек итүче "депутатлар" группасы» [Gramsci, p. 145]. Нигездә, гражданлык җәмгыяте һәм интеллигенция буйсынучының гегемониягә ризалыгына этәргеч булып торалар. Буйсынучылар тарафыннан

ризалык билгеләре сизелмәсә яки ризалык бөтенләй булмаса, гегемония хакимият тарафыннан мәҗбүри башкарыла.

Бер яктан, Грамшиның мәдәни гегемониядә ризалык бирү идеясен уңай дип санарга да мөмкин, әмма гегемония максатчан рәвештә буйсынучы өчен уңайлы һәм файдалы күренеш буларак тәкъдим ителә. Холл, буйсынучының «рөхсәт итүе» хакимлек итүчеләр өчен кирәк, дип каршы чыга, чөнки моңа ирешсә генә дәүләт ризалык бирә ала, ди. Аның фикеренчә, хакимлек итүче сыйныф буйсынучыдан өстенлеккә идарә аша гына түгел, ә төрле өлкәләрдә җитәкчелек итү аша да ирешә. Мәсәлән: дин, белем һәм гаилә. Әлеге институтлар сыйнфый көрәшне тәшкил итә һәм буйсынучыны буйсынырга мәҗбүр итә [Hall, Jefferson, p. 42].

Грамши гражданлык җәмгыятен өстенлек итүче сыйныф барлыкка китерү өчен иң яхшы форма дип саный. «Грамши буенча, структурадагы аерма гражданлык/сәяси яки шәхси/җәмгыяви өлкәләрдә генә түгел, гегемония/өстенлек итүдә дә чагылыш таба. Аерым җәмгыятьләрдә бу иҗтимагый контроль төре балансста да булырга мөмкин» [Femia, p. 29]. Әмма һәрвакыт үзләренең мәдәниятләре башкалардан аерылып торуын аңлаучы һәм хакимияткә каршы чыгучы төркемнәр һәм сыйныфлар очрый.

Ләкин иң куәтле сыйныфларның мәнфәгатьләрен яклаучы структуралар эчке яктан ничек кенә катлаулы булмасыннар, башкалардан һәрвакыт иҗтимагый һәм мәдәни яктан өстенлек итәчәкләр. Өстенлек итә торган мәдәният үзен *бердәнбер мәдәният* буларак тәкъдим итә. Ул башкаларга чикләр билгеләргә һәм аларны үз кысаларында тотарга тырыша. Аның дөньяга карашы, әгәр кире кагылмаган булса, иң дөрес, универсаль мәдәният булып санала. Башка мәдәни конфигурацияләр өстенлек итүчегә буйсынып кына калмаячак, ә аның белән көрәшергә, үзгәртергә һәм хәтта аны югары позициядән бәреп төшереп, үз *гегемониясен* алга үткәрергә тырышачак [Hall, Jefferson, p. 11].

1917 елда Россия Империясе Советлар Союзы барлыкка килү белән җимерелә. Әмма татарлар русларга күптән, XVI гасырда, Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан бирле буйсындырылган була. Совет режимы төрле мәдәниятләргә, шулар рәтендә татарларга, тәэсирен көчәйтә генә, мәгариф, матбугат өлкәсендә Совет хакимияте үз карашын тага. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы Совет Татарстаны сурәтләнә. Биредә язучы татар халкының Советлар Союзының мәдәни гегемониясе белән көндәлек көрәшен тасвирлый. А. Гыйләҗев халыкның сугыштан соңгы халәтен бик оста сурәтли, ул әсәрләрендәге күпсанлы геройлар аша татарларның үз йөзен саклап калырга омтылышын күрсәтә. Ә иң мөһиме, Советлар Союзының кырыс цензурасына карамастан, А. Гыйләҗев татар мәдәниятен үстерү турында яза. Әдип Совет гегемониясенә каршы чыга, ул идарә итү сәясәтен

һәм буйсынучы сыйныф формалаштыручы сәясәтне тәнкыйтьли. Үзенең фикерләре аркасында ул биш ел гомерен төрмәләрдә һәм лагерьларда уздыра. А. Гыйләҗев иҗаты белән татар җәмәгатьчелегендә тарихка кереп калырлык ачыш ясый.

Язучы «Өч аршин җир» повестендә, хакимият тарафыннан каршылыклар булуга карамастан, үзеңнең мәдәниятеңне, туган илеңне онытмауның мөһимлеген сурәтли. Әсәр геройларының берсе Мирвәли – совет режимының коллективизация корбаны. Мирвәли, җирләре хакимият тарафыннан тартып алынгач, барысын да онытыр өчен, үч итеп туган җиреннән китә. Аның бу гамәле совет деидентификация процессы нәтиҗәсе, Мирвәлинең туган җире турында истәлекләре – аны үзенең тамырлары, мәдәнияте белән бәйли һәм онытырга ирек бирми. Мирвәли җиңел генә үзенең үткәнен сызып ташлый алмый: «Карыйм. Олаулар тора... Иген исе килә!.. Бодай исе!..Күкрәкләр киңәеп китте... Кыр эшен ярата идем бит мин, гомерем иген игеп үтәр дип уйлый идем. Инде тегендә, туган җирдә, мине мәхрүм иткәннәр икән, ичмасам монда ашлык арасында булыйм дип кердем мин тегермәнгә! Гел ашлык арасында!» [Гыйләҗев, б. 60–61].

Мирвәли хәтерен сызып ташларга омтыла, хәтта үзенең кайда туып-үскәнен дә онытырга теләсә, хатыны Шәмсегаян, киресенчә, рухи кыйммәтләрне сакларга тырыша, Хәтер мәдәниятне саклаучы мөһим фактор булып тора һәм рухи кыйммәтләрнең яшәешенә хезмәт итә. Мирвәли хәтер аркылы һәрвакыт үзенең үткәне белән бәйләнештә яши. Тегермәндә алар өчәү эшли, бер-берсе белән таныш түгелләр, бер-берсенә шәхси сораулар да бирмиләр, алар җансыз кебек. Ярма тартып, Мирвәли үзенең үткәненнән качарга теләсә дә, һәрвакыт ярманы кулына алгач, ул үз-үзеннән «Карачура басуларында үскән ашлык түгелме икән» дип сорый.

Үпкә хисләрен онытып, Мирвәли, хатыны Шәмсегаянны күмәр өчен, туган авылына кайтырга тиеш. Ул авылда берни дә үзгәрмәгәндер кебек, ләкин: «Инеш аръягында үзгәреш!.. Таллык белән тау арасында Мирвәли исемнәрен дә белмәгән әллә нихәтле машиналар канатларын, яңакларын ялтыратып тезелешеп торалар. Авылның механизациясе шунда икән. Хәзергә алар ял итә. Арырак бензин баклары, әллә нинди подваллар, сарайлар... Колхоз үскән, димәк» [Гыйләҗев, б. 94]. Кайчандыр Мирвәлинеке булган җир хәзер Советлар Союзы индустриализациясе яңа сәясәтенең бер өлеше булса да, бу җир аның тамырлары, үткәне белән бәйле. Бу җир аңа ата-бабаларыннан калган, ул аның мәдәнияте, рухи кыйммәтләре символы булып тора.

«Җомга көн кич белән» әсәрендә Аяз Гыйләҗев ерак тарихка мөрәҗәгать итә, аерып әйткәндә, XVI–XVII гасырларда татарларны көчләп чукындыру чорына. Бу төркем татарларны «керәшеннәр» дип атыйлар. «Хәнифәнең ире мәктәп директоры Игнат Белов керәшен иде.

Хәнифә, Явыз Иван хатасын төзәтергә теләп, аңа Идрис дип эндәшә иде» [Гыйләҗев, б. 71]. Явыз Иван, Казан ханлыгын яулап алгач, татарлар русларга буйсындырылалар һәм, христиан динен кабул итсеннәр өчен, аларны төрле яклап кысрыклыйлар. Шулай да, керәшен татарлары тулысынча руслашмый, алар татар теленең диалектында сөйләшә һәм татар йолаларын үтәп яши. «Җомга көн кич белән» әсәрендәге Хәнифә дә бу вакыйганы тарихи фаҗига буларак кабул итә, ире Игнатның ата-бабаларының христианлашуын тарих хатасы дип саный һәм үзенчә моны төзәтергә тырыша. Хәнифә иренең элеккеге фамилиясе Билаловны куллана.

«Җомга көн кич белән» әсәрендә чагылыш тапкан зур тарихи вакыйгаларның тагын берсе – 1917 елгы большевиклар революциясе. А. Гыйләҗев татарларның русларга буйсынуын тәнкыйть итә. «Революция өчен башларын салган ата-бабаларыбыз безне кичерерме? Байларны һәм җирбиләүчеләрне бәреп төшергән ата-бабаларыбыз безне кичерерме? Кичермәс!» [Гыйләҗев, б. 30]. Язучы бу сүзләре белән большевиклар революциясенең, «Өч аршин җир»дәге Мирвәли мисалында күренгәнчә, татарларга беркайчан да файда китермәгәнен аңлатырга тели. Революция нәтиҗәсендә татарлар күбрәк мөлкәтләрен югалталар, колхозлаштыру корбаннарына әвереләләр. А. Гыйләҗев совет цензурасыннан качу өчен революцияне сурәтләгәндә аны уңай яктан тасвирласа да, үз фикерен авырлыкларны-газапларны тасвирлау аша җиткерә.

Мәдәни гегемония урнаштыруда мәгариф һәм белем бирү оешмалары зур көчкә ия. Грамши мәдәни гегемониядә интеллегенциянең роле зур булуын күрсәтә һәм ул мәгарифне өстенлек итүче фикер формалаштыручы оешма дип саный. Шулай да, белем танып-белү үсешенә дә тәэсир итә. А. Гыйләҗев әсәрләре буенча белем – буыннан-буынга күчеп килгән традицияләрне сакларга һәм колониаль идеологиядән котылырга ярдәм итүче, кешене рухи үстерүче чара, ул өстенлек итүче идеология тарафыннан билгеләнми. А. Гыйләҗев «Җомга көн кич белән» әсәрендә мәдәни кыйммәтләрне саклау өчен буыннар арасындагы бәйләнешнең ныклыгы мөһимлеген ассызыклый. Бибинур хәзер балаларның моннан дистә еллар элек уйнаган уеннарны уйнамавын искә ала: «Балалар хәзер качышлы уенын уйнамыйлар» [Гыйләҗев, б. 148]. Ул әлеге күренешнең сәбәпләрен эзли. «Мәсәлән, син балалар бакчасында эшләгәндә аларга кайсысын уйната идең» [Гыйләҗев, б. 148]. Ләкин җавап табылмый. Бала кече яшьтән үк үзенең милли кыйммәтләрен белеп үсәргә тиеш. Шуңа күрә А. Гыйләҗев мәҗбүри тагылучы идеология урынына белем бирүдә милләтенең рухи кыйммәтләрен күрергә тели. Әгәр балалар милли уеннар уйнап үссәләр, киләчәктә алар гегемонияне түгел, ә үз мәдәниятләрен таныып-беләчәкләр. Белемле киләчәк буын мәдәни, рухи яктан аңлырак булачак.

А. Гыйләҗев «Берәү» хикәясендә бер-берсенең ышанычын аклар өчен зур авырлыклар аша үткән ана белән аның улы мөнәсәбәтләренә басым ясый. Исхак шәһәргә укырга китә, әнисе Маһибәдәр авылда торып кала. Әнисенең хатларын укый алыр өчен Исхак гарәп имлясен өйрәнә. Ул аны яшертен өйрәнә, чөнки бишенче сыйныфта укыганда укытучысы Мәрдия апа бөтен иптәшләре каршында аның гарәп хәрефләре кулланиуыннан көлгән була. Әнисе улын гарәп хәрефләре белән язарга өйрәтә. Малай коймаларга, мәктәп парталарына «Исхак» дип яза башлый. Мәрдия апа аны, мулла булырга җыенасыңмы әллә, дип, иптәшләре каршында мыскыл итә һәм директорга алып керә, малайны Коръән хәрефләрен белгәнгә ачуланалар [Гыйләҗев, б. 118].

А. Гыйләҗев татарларның, совет гегемониясе кириллица керткәнче, гарәп алфавиты куллануы турында яза. Югарыда китерелгән мисалдан күренгәнчә, совет белем бирү системасы башка мәдәниятләргә, аеруча дин белән бәйле мәдәниятләргә яшәргә ирек бирми. Исхакны кече яшьтә үк татар мәдәниятен белгәне өчен җәзалыйлар, мыскыл итәләр, шуңа күрә, тагын көлкегә калмас өчен, ул, үскәч тә, гарәп алфавитын качып өйрәнә. Бу – мәдәни гегемониядә мәктәпнең, белем бирү оешмаларының башка идеологияләрне юкка чыгарып, социаль элита идеологиясен көчләп тагуының ачык мисалы. Гарәп хәрефләре Исхакның советлар юкка чыгарырга теләгән татар җаны, мәдәни идеологиясе һәм дини тамырлары символы булып тора.

Советлаштыру процессы динне кире кага; А. Гыйләҗев «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» әсәрендә коммунистларның дини кыйммәтләрне җимерүләрен тасвирлый.

Алар мәчетне клубка әйләндерергә телиләр. Моның өчен манараны кисәргә кирәк. Мәчеттә яшьләрнең кызыл почмагын манараны кисмичә дә ясап була бит. Хәбибрахман абзый шулай уйлый. «Әйдәгез, тимик, – ди ул. – Сез кешеләрнең җанын тәрбияләргә телисез, ләкин яңа кешене җимереп тәрбияләп булмый. Манара безгә зыян салмый, аны безнең бабаларыбыз төзегән...» [Гыйләҗев, б. 24].

Хәбибрахман абзыйны беркем дә тыңларга теләми, киресенчә, аның каршылыгын тәнкыйтьләүчеләр дә табыла. «Манараны председатель югында, төнлә кисәләр. Ул чорда яшьләр тынгысыз иде, аеруча шәһәрдән кайтканнары. Бу манара вакыйгасыннан соң председатель эшеннән алынды» [Гыйләҗев, б. 24].

Хәбибрахман ата-бабалардан калган мирасны саклап калырга тырыша. Манара Хәбибрахман һәм авылда яшәүче башка татарларга тамырларын, кайдан чыгышын хәтерләтеп тора.

Гегемония басымына карамастан, А. Гыйләҗев өчен бердәмлек һәм туган җир темалары өмет чыганагы булып хезмәт итә. Язучы «Берәү», «Җомга көн кич белән», «Өч аршин җир» әсәрләре аша Советлар Союзы мәдәни гегемониясенең тәэсирен күрсәтә. А. Гыйләҗев татар

халкы өчен милли рухның һәм хәтернең мәдәни гегемониягә каршы көрәштә көчле булуын ассызыклый.

**Әдәбият**

*Noaman G. Ali.* Reading Gramsci through Fanon: Hegemony before Dominance in Revolutionary Theory. Rethinking Marxism.

*Gıylecev Ayaz.* Bir Avuç Toprak / Trans. Fatih Kutlu. İstanbul: Sütün Yayınları, 2011.

*Гилязов Аяз.* Вернись к истоку // Гилязов А. Девичьи письма / пер. М. Ганиной. М.: Современник, 1973. С. 49–152.

*Ğıylecev Ayaz.* Cuma Günü, Akşam... / Trans. Fatih Kutlu. Ankara: Bengü, 2013.

*Gramsci Antonio*. Selections from Prison Notebooks of Antonio Gramsci. London London; ElecBook, the Electric Book, Web, 1999.

*Femia Joseph.* Gramsci's Political Thought Hegemony, Consciousness, and the Revolutionary Process. Oxford: Kalderon Press, 1981.

*Hall S. and Jefferson T.* Resistance through Rituals: Youth Subcultures in Post-War Britain. Taylor & Francis, 2006.

***Абдулкадир Чекич,***
*фәннәр кандидаты, Газиантәп, Төркия*

УДК 821.512.145:82-3

***Г.Р. Насибуллова***

# XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ МОТИВЛАРНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена рассмотрению основных мотивов в татарских рассказах конца XX и начала XXI веков. В статье, проведя обзор татарских рассказов данного периода, делается попытка выявления дальнейших путей развития татарской прозы в целом.

**Ключевые слова:** рассказ, мотив, поэтика, жанр, сюжет.

XX–XXI гасырлар чиге әдәбият үсешендә мөһим этап булып тора һәм аерым өйрәнүне сорый. Бу, беренчедән, гасыр ахыры әдәбиятында бөтен йөзьеллык дәвамында булган сәнгати һәм эстетик эзләнүләргә нәтиҗә ясалу белән аңлатылса, икенчедән, яңа әдәбият бүгенге тормышның катлаулы һәм каршылыклы якларын аңларга ярдәм итә, өченчедән, үзенең яңа ачышлары, тәҗрибәләре белән алга таба XXI гасырда әдәбиятның үсеш юлын билгели. XX–XXI гасырлар чигендә җәмгыятьтә барган үзгәрешләр әдәбиятка да үтеп керә. Бу, беренче чиратта, әдәбиятта хикәя жанрында чагылыш таба. Яңа дулкында иҗат ителгән хикәяләр, бер яктан, XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булып, һәм гареп, һәм шәрык мәдәниятендә формалашкан алымнарны милли җирлеккә күчереп, алтын чор традицияләрен үстерүгә юл тота. Икенче яктан, милли чынбарлыкка, үткәнгә һәм бүгенгегә игътибар арту күзәтелә, һәм ул әдәбияттагы тема-проблематикага тәэсир ясый.

1960–1980 елларда татар әдәбиятында идеологик-эстетик юнәлешләр әйдәп барды. Аларның беренчесен партия мәнфәгатьләрен өстен куеп һәм аның идеологиясенә хезмәт иткән рәсми юнәлеш дип тә атарга була. Ул совет чынбарлыгын уңай планда күрсәтүгә басым ясады. Бу максатын, башлыча, эшчеләр дөньясын сурәтләү аша тормышка ашырды. Кеше, иң беренче чиратта, хезмәт кешесе буларак сурәтләнде, аның эчке дөньясы, шәхси тормышы, рухи халәте арткы планда калды. 1980 еллардан исә әдәбиятта эчке кичерешләргә зур урын бирелә, үзәктә җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең кеше күңеленә ничек тәэсир итүе сурәтләнә башлый (М. Хуҗин «Чыбыркы», Ә. Гаффар «Кәфенлеккә кесә текмиләр», Р. Зәйдулла «Итек»).

1960–1980 еллар әдәбиятындагы икенче мөһим юнәлеш, иң әүвәл, авыл турындагы хикәяләр белән бәйләнгән иде. Бу чорны «авыл прозасы» дип тә атыйлар. Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, А. Расих, Ә. Баянов кебек талантлы әдипләребез әлеге теманы

үзәккә алып, бик күп әсәрләр иҗат иттеләр. Авыл темасы XX гасыр ахырында да әдәбият мәйданыннан югалмый. Бу күренешне ике төрле сәбәп белән аңлатырга мөмкин. Беренчедән, авыл элек-электән татар әдипләре өчен аеруча якын һәм кадерле булды. Чөнки аларның шәхси тормышы һәм язмышы күпчелек очракта шушы дөнья белән турыдан-туры бәйле иде. Икенчедән, язучылар авыл белән татар милләтенең язмышы аерылгысыз бәйләнгән булуын яхшы белеп эш итәләр. М. Хуҗин, А. Хәлим, Ә. Гаффар, Г. Гыйльманов һ.б. үзләренең хикәяләрендә авыл, аның үткәне һәм бүгенгесен сурәтлиләр.

Гасырлар чиге әдәбиятында хикәя жанрында чагылыш тапкан төп мотивларның берсе – элекке авылны сагыну. Бүгенге көндә – авыллар юкка чыгып баргагда – бу аеруча актуаль яңгырый. Бер төр хикәяләрдә элекке авыл әдәп-әхлак югарылыгы буларак сурәтләнә. Үткәнгә сәяхәт аша бүгенге көндә әлеге сыйфатларның җуела баруына борчылу белдерелә. Хикәяләрдә автор игътибары күбрәк авыл дөньясының рухи-әхлакый мәсьәләләренә юнәлтелә. Татар халкының менталитетын чагылдырган әхлаклылык, иман, миһербанлылык, тыйнаклык кебек сыйфатларның юкка чыга баруын алгы планда сурәтләгән әсәрләр барлыкка килә. Мәсәлән, М. Хуҗин бу теманы элекке авылны сагынуын, яратуын сурәтләү аша ача. Язучының «Ак төенчек» хикәясендә бу бик ачык күренә. М. Хуҗин авылның һәр урамын, һәр тыкрыгын салмак кына сурәтли. Күз алдына бер-бер артлы тезелеп киткән йортлар, тар сукмаклар, яшел чирәмле капка төпләре килеп баса. Бизәкле тәрәзәләр, аратирә ярдәмчел, шат күңелле, гади авыл кешеләре күренеп китә. Боларның барысында да авторның элеккеге авылны сагынуы, аны матур буяуларга төреп сурәтләве чагыла. Язучы трактор-машина тәгәрмәченнән ермачланган урамнарны, гадилеген, эчкерсезлеген җуя барып, ямьсез гадәтләрне үз иткән авыл агайларын күрергә теләми. Бу мотивлар аның «Ак колын», «Юлмәти бәйрәме», «Җир әйләнә сәяхәт» хикәяләрендә дә үзәк урынны били.

Авыл, аны юксынуга багышланган хәзерге хикәяләрнең күбесе бер структура буенча төзелгән, уртак сюжет мотивы чагылыш таба: кайчандыр читкә бәхет эзләп киткән, озак еллардан соң авылына яки бүгенге көндә шәһәрдә яшәүче кешенең туган нигезенә кайту моментлары сурәтләнә. Кайту юлында ул үткәнен, өйдә ялгызы балаларын көткән әнисен (яки инде мәрхүм булган әти-әнисен), балачакта уйнап үскән болын-кырларын исенә төшерә, яшәеш, яшәү мәгънәсе хакында уйлана. Әсәрләр яшәеш хакында фәлсәфи фикер йөртү мотивы да урын ала. Ә. Гаффарның «Тимер аяк» (1986) һәм «Коелы өй» (2008), М. Хуҗинның «Йолу» (1999), А. Әхмәтгалиеваның «Өзелгән гөл» (2008) һ.б. хикәяләрдә туган авылга кайту, андагы үзгәрешләр образлы-сурәтләү аша бик тәэсирле бирелә. Туган авыл, юл, юлчы мотивлары Ә. Гаффарның «Энә күзе» (2003) әсәрендә дә чагылыш таба. Биредә

язучы кыска хикәя җирлегендә берничә мөһим мәсьәлә күтәрә. Туган нигездән аерылу, авылларның юкка чыга баруын күрсәтү белән берләттән, язучы гомергомергә әхлак-әдәп үрнәге булган татар авылларына җинаятьчелекнең дә үтеп керүен сурәтли.

Туган авыл, туган нигез, ана – бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр. Авылда ялгызы яшәүче ана образы Ф. Яхинның «Күке фалы» (2009) хикәясендә дә тасвирлана. Әлеге моңсу хикәядә язучы мифопоэтик образлар ярдәмендә ана, туган нигез, алардан аерылу сагышын сурәтли. Хикәядә, вакыйгалар сурәтләнешенә караганда, хискичерешләргә урын күбрәк бирелә. Әсәрнең буеннан-буена авыл табигатенә соклану, аны сагыну мотивы үткәрелә. Шәһәрдән авылга кайткан кешенең эчке дөньясы импрессионистик алымнар ярдәмендә ачыла. Табигать күренешләре белән геройның эчке халәте арасында параллель үткәрелә. Геройның күңеле тыныч – ул туган ягында, янында гаиләсе, газиз әнисе. Табигать матур буяулар белән сурәтләнә, лирик герой табигатькә соклана, тирә-юньнең гүзәллеге аның күңеленә тынычлык иңдерә. Бу идиллияне әнисенең күкедән гомер озынлыгын юратуы боза. Газиз кешеләр белән мәңгегә аерылышуның якынлашуын сизү (гәрчә күкенең кеше гомерен юравы хорафат, ышану гына булса да) шом, сызлану мотивларын тудыра. Әлеге халәтне Ф. Яхин табигать сурәте ярдәмендә бик оста тасвирлый.

Шулай ук хәзерге хикәяләрнең күбесендә буш нигез мотивы да киң кулланыла. Нигезнең буш булуы иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә бәйләп аңлатыла. Мәсәлән, А. Әхмәтгалиева «Өзелгән гөл» (2008) хикәясендә туган нигезеннән аерылган кешеләрне өзелгән гөлгә тиңли. Әсәрнең исеменә үк чыгарылган әлеге метафора хикәянең үзәген тәшкил иткән сагыш, ялгызлык, әрнү мотивын тагын да көчәйтә. Зөлфиянең туган нигезеннән китү сәбәпләре авылда яшәү шартларының начар булуы, читтә бәхет эзләү белән аңлатыла.

Авыл темасына багышланган хикәяләрнең күбесендә очрый торган образ – ул элеккеге колхоз рәисе. Хикәяләрдә ул гади халыкны җәберләп торучы, халык мәнфәгатен кайгыртмаучы образ буларак сурәтләнә. А. Әхмәтгалиеваның «Өзелгән гөл» хикәясендә – Тимер Хәсән, М. Хуҗинның «Йолу» хикәясендә – Әтәлге Фирдүс, И. Сираҗиның «Гыйсметдин тәүбәсендә» Гыйсметдин образлары, кайчандыр, үз авылларының хуҗасы булганнар. Ничә еллар буе халыкны кан-яшь түктереп торган әлеге җитәкчеләрнең бүгенгесе аяныч итеп тасвирлана. Әсәрләрнең үзәгендә кеше һәм заман каршылыгы сурәтләнә. Әлеге хикәяләрдә вакыт хронотобы бик үзенчәлекле бирелгән. Вакыт икегә бүленә: бүгенге көн һәм үткән. Мәсәлән, Р. Зәйдулла хикәясендәге Гыйсметдиннең бүгенгесе: ул сөйләшә дә, кымшана да алмыйча урын өстендә ята. Озак вакыт хәрәкәтләнмичә ятканга күрә, аның тәне чери башлаган, ләкин ул үткәннәр өчен үкенми. Үткән заман аның аңы аша бирелә. Автор хикәягә килеп кергән һәрбер

яңа героен аның үткәне белән бәйли, һәм алар белән бәйле рәвештә Гыйсметдиннең яңадан-яңа гөнаһлары ачыла бара.

Кеше һәм заман каршылыгын яктыртучы хикәяләрне тема, идея, геройлар якынлыгы гына түгел, ә сюжет төзелешендә дә уртак мотивлар берләштерә. Н. Гыйматдинованың «Манара» хикәясендә дә алгы планда элеккеге колхоз рәисенең авыл халкы тарафыннан читкә тибәрелеп, картлык көнен ялгыз үткәрүе сурәтләнә.

Яңа заман яңа проблемалар алып килә. XX гасыр ахырында илебездә көчәя барган урлау, талау, җинаятьчелек, фахишәлек кебек күренешләр әдәби әсәр мәйданында да чагылыш таба. XX гасыр ахырында әдәбиятка җинаятьчеләр, фахишәләр, тормышның төбенә төшкән йортсыз-җирсез кешеләр дөньясын сурәтләү килеп керә. Бу темаларны ачуга Зиннур Хөснияр үзенең хикәяләрендә киң урын бирә. Язучы без яши торган кешелексез җәмгыятьне һәм шундый шартлар тудырган кешеләрне укучы хөкеменә чыгара. Мәсәлән, «Ак болыт күләгәсе» (2000) хикәясе Тәслимә иренең хыянәте ачылу белән башланып китә. Алга таба вакыйгалар хатынның иреннән үч алу теләге белән кылган гамәлләрен һәм шул юлда очраткан кыенлыкларны сурәтләү аша үстерелә. Кыска гына хикәя мәйданында автор алданган хатынның эчке кичерешләрен, аларның гаилә тарихын һәм алар янәшәсендә буйдак ир Шамилнең тормыш юлын һәм рухи халәтен ачып салуга ирешә. Язучы җинаятьчелек проблемасын күтәрә. Тәслимә төнлә шәһәр буйлап барганда адым саен җинаятьчеләргә тап була. Зиннур Хөснияр хыянәтче иргә дә, төнге шәһәр хуҗалары булган каракларга, наркоманнарга, гаиләле ирләрне аздыручы хатыннарга да хөкем чыгармый. Ул моны эшләүне укучының үзенә калдыра. Әсәрнең исеменә чыгарылган ак болыт метафорасы да фәлсәфи мәгънәгә ия. Тормыш ваклыкларыннан өстен Тәслимә «Ак болыт»ка тиңләштерелә.

Бүгенге көндә татар хикәясенә шәһәр тормышын чагылдыру җитми, гомумән, татар әдәбиятында бу тема аз яктыртыла. Үзе дә бик күп хикәяләр авторы Рифә Рахман бу күренешне тел белән бәйләп аңлата: «Шәһәрдә яшәүче татарга авылның үткәне турында язуыбыз, бер яктан, яхшы да. Милли хисне тәрбияләрлек материал җитәрлек һәм нәкъ менә шул җирлектә күп тә ул. Икенче яктан, без шәһәр тормышыннан шул хисне үтерерлек күренешләрне табып алып, кире кагарга бурычлы, замананың кеше рухына зыян салырлык якларын бүгенге укучыга ничектер ачарга тиешбез. Шул ук вакытта шәһәр чынбарлыгын тасвирламауның башка сәбәбе дә бар. Кешеләрнең тормышы анда яшәгән тораклары кебек үк шактый охшаш. Аның хәтта вәхшилеге белән имәндергән, көн дә кич «Эфир» программасы күрсәткән күренешләре дә бер-берсенә тартым. Күп ишеткән саен күңелката бара, ә менә авылның кичерәк кенә вакыйгасы да уйга сала. Авылда тугангамы, анда кайткач, яшәү һәм үлем, узган һәм киләчәк, ата-баба, милләт турында күбрәк уйланасың, аның суларын эчеп сафланасың,

яшәүгә өмет аласың, әмма тагын авыл тарлыгыннан шәһәргә качасың. Язучының, ул иҗат иткән геройның шушы ике арада бәргәләнүләре хикәя формасында да чагылыш таба башлады. Без кайчандыр авылдан шәһәргә күчкәндә урталыкта торган каһарманнарны бөтен нечкәлекләре белән бирсәк, аның социаль статусын үзгәртүен уңай дип карасак, хәзер бу мәсьәләне бөтенләй башкача чишәбез» [Рахман, 2009, б. 92].

Хикәяләрдә кешенең авыл белән шәһәр арасында бәргәләнүе, күңел халәте дә чагылыш таба. Мәсәлән, М. Хуҗинның «Бәхет җире», Р. Зәйдулланың «Кызыл сыер» әсәрләрендә әлеге мотивлар бик ачык сурәтләнә. Р. Зәйдулла «Кызыл сыер» хикәясендә символлар ярдәмендә туган нигезеннән аерылып, башка мохиттә яшәргә мәҗбүр ителгән Хәлим психологиясен бик тирәнтен ача. Язучы бу ирнең тормышында очраган авырлыкларны заманга яисә җәмгыятькә кайтарып калдырмый, ә хәзерге әдәбиятның төп сыйфатларыннан берсе булган геройның эчке халәте, рухи дөньясы аша ача. Хикәянең төп мотивы булып шәхес фаҗигасе тора. Әсәрнең сюжеты түбәндәгедән гыйбарәт: Хәлим, хатыны сүзе белән, авылдан шәһәргә күчә. Ир яшел хәтфә болыннарны, тугайларны каланың кысан бүлмәсенә алмаштыра. Р. Зәйдулла шәһәргә китү сәбәпләрен сәнгати осталык белән китереп чыгара: килен һәм кайнана арасындагы каршылык аркасында алар туган нигезләреннән читкә китәләр. Төшләрендә авылны күреп саташучы Хәлим авыл һәм шәһәр арасында бәргәләнә. Ләкин авылга талпыну аның күңелендә генә бара. Р. Зәйдулла «ике ут» арасында калу сәбәпләрен аның холкы-фигыле белән аңлата. Язучы әсәрнең төп мәгънәсен символ аша белдерә. Хәлимнең төшендә күргән кызыл сыеры аның үзен гәүдәләндерә. Ләкин бу образ аллегория генә түгел, «күп һәм төрле сыйфатларны (йомшаклык, эш белән омтылышның тәңгәл килмәве, ихтыяр көче булмау һ.б.) туплаган символ вазифасын башкара. Хәлимнең монологы кебек язылу геройның холык-фигылен ничек бар, шулай кабул итәргә әзерли. Көчсез, үз сүзен әйтә алмаучы Хәлим моннан газап та чикми: ул вакыйга-хәлләрне күңелендә дөресли, хакыйкатькә китерә. Язучы да гаепләүче яки тәнкыйтьләүче түгел, «кызыл сыер» фәлсәфәсен, дөньяга карашын укучыга җиткерүче генә» [Заһидуллина, 2006, б. 203].

Хәзерге хикәяләрдә шәхес фаҗигасе кешенең уй-фикер, хис-кичереш дөньясында барган хәрәкәтне күзәтү аша ачыла. Тормышның авырлыгы, кешенең сынауларны үтеп чыгарга теләп тартышуы үзәктә сурәтләнә. Мисалга Ф. Яруллинның «Кызыл күлмәкле кыз» (1991) хикәясен карыйк. Әсәр геройның сугыштан соңгы елларны искә алуы турында. Хикәянең төп герое – бала. Сугыш еллары сурәтләнгән хикәяләрнең күбесендә бала образы, вакыйгаларны бала авызыннан сөйләтү урын ала. Бу – сугыш, сугыштан соңгы елларның бүгенге көн язучыларының балачагына туры килүе һәм аларның хикәя материалы итеп үз биографияләрен куллану белән дә

аңлатыла. Ф. Яруллинның «Кызыл күлмәкле кыз» хикәясе малай исеменнән сөйләнелә. Әсәрдә сугыштан соңгы ярлы тормыш, чарасызлык үзәк мотив булып тора. Хикәя балачакның күңелне тетрәндергән бер вакыйгасын искә алу рәвешендә язылган. Ф. Яруллин хикәясенең сюжет-вакыйгалар катламы түбәндәгедән гыйбарәт: әсәрдә сугыштан соң фронтовик хатыны һәм аның балаларының тормышы сурәтләнә. Әтиләре сугыштан кайтмаган балаларны ятимлек ачысы гына түгел, ярлылык та газаплый. Малай бу газапларның барысын да әтиләре булмауда күрә. «Әти исән булса», «әти кайткан булса» ашарга ризык та булыр иде, иптәшләре дә кыерсытмас иде. Хикәянең тышкы конфликты җәмгыять һәм кеше арасында булса, эчке конфликт баланың күңелендә бара: ул фикерләр конфликты. Малайның әтиле өй турындагы хыялы чынбарлык белән каршылыкка керә, фикере базарда чәчәк сатканда бер кыз белән очрашкач үзгәрә. Язучы безнең илдә сугыштан соң әтиле өйнең дә мул тормышта яшәмәгәнлеген күрсәтә.

Моңа кадәр илдә барган зур төзелешләр, ГЭСлар, завод-фабрикалар ачылуга дан җырланса, XX гасыр ахырында әдәбиятта бу күренешләрнең башка ягы чагылдырыла. Язучылар игътибарларын әлеге зур төзелешләрнең бик күп авылларның юкка чыгуына, нигезеннән күчерелүенә, су астында калуга дучар ителүенә юнәлтәләр. Нигезеннән кубарылган кешеләрнең рухи халәте һәм аның киләчәк буыннарга йогынтысы хакында бик күп хикәяләр иҗат ителде. Зиннур Хөснияр «Кичү» хикәясендә әлеге проблеманы бик ачык тасвирлый. Хикәядә вакыт хронотобы бик кыска араны тәшкил итә: геройларның бер ярдан икенче ярга чыгу аралыгы. Ләкин шушы кырык минут эчендә көймәдәгеләрнең чын йөзе ачыла. Әлеге хикәядә көймәдә утыручылар да, ниндидер, символик мәгънә йөртә: яр буенда су астында калган зираттан чыккан сөякләрне җыеп йөрүче капчыклы карт, мулла бабай, көймәче, тракторчы, аның улы Мөхәммәт (совет заманы өчен ят исем), үзен дөнья хуҗасы итеп санаган җитәкче. Әсәрдә бары тик малайның исеме генә бирелә. Кечкенә Мөхәммәт киләчәкне гәүдәләндерә, күзәтүләр, яшәеш, тирәюньдәге вакыйгалар малай аңы аша тапшырыла. Көймәдәгеләр уй-ниятләре, дөньяга карашлары, кыйблалары белән аерылалар.

Гомумән, хәзерге әдәбиятта төп нигез, аны югалту, аннан аерылу мотивларын күтәреп иҗат ителгән әсәрләр шактый. Бүгенге көндә, күп авыллар юкка чыга барганда бу тема аеруча актуаль яңгырый.

XX гасыр ахырында сәясәттә барган үзгәрешләр, демократия күренеше буларак сүз иреге, матбугат иреге яулап алыну нәтиҗәсендә милләт, халык, аның үткәне, киләчәге хакында фикер әйтергә мөмкинлек тудырыла. «Татар халкының милләт буларак сакланып калу мәсьәләсе алгы планга чыгып, рухи-мәдәни өлкәдәге үзгәрешләрнең төп юнәлешен билгеле. Ә инде халыкның туган телен әкренләп югалту куркынычы

аеруча кискен итеп куела. Ул исә үткән тарихыбызның фаҗигале һәм данлы сәхифәләрен объектив чагылдыру, олы шәхесләребезнең эшчәнлегенә тарихи дөрес бәя бирү, рус тарихчылары тарафыннан күрмәмешкә салынган факт-күренешләрнең халкыбыз һәм Россия тарихындагы урынын билгеләү һ.б. җитди сорауларны алга куюга, эзләнү-тикшеренүләр башлауга китерә» [Закирҗанов, 2008, б. 12]. Милли азатлык, татар халкының аянычлы язмышы мотивы әдәби әсәрләрдә чагылыш таба. Алай гына түгел, 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башында Ф. Бәйрәмова, А. Хәлим, Р. Әхмәтҗанов, Т. Миңнуллин, З. Зәйнуллин, Ә. Мәхмүдов кебек татар әдипләре «әлеге процесслар эчендә яши, аерым мәсьәләләрдә әйдәп баручы ролен үти» [Закирҗанов, 2008, б. 12].

Татар халкының милләт буларак сакланып калу мәсьәләләрен алгы планга чыгарып, халыкара мөнәсәбәтләрне әсәрләренең үзәк юнәлеше итеп күтәргән Айдар Хәлим хикәяләренә киңрәк тукталыйк. «Кылганнар чәчәк атканда», «Трофей ашъяулык», «Җырлар вакыт», «Берлинга хат», яңгырашы белән үк сискәндереп җибәрә торган «Казыктагы тальян», «Кара кышта», публицистик аһәң белән өртелгән «Эңгер», «Авылдаш», сатирик пафос белән сугарылган «Сандугач белән Карлыгач» һәм утызынчы-кырыгынчы елларның фаҗигале вакыйгаларын, җәмгыятьтә кыргыйлык һәм вәхшилекнең чәчәк атуын чагылдырган «Кыйбла» – әдип соңгы елларда иҗат иткән хикәяләрнең тулы булмаган исемлеге менә шулардан гыйбарәт. Болар һәм исемнәре саналмаган башка күп кенә хикәяләрнең тематик диапозоннары никадәр генә киң, персонажларының яшәү даирәсе һәм мохите ничаклы гына төрле булмасын, күпчелек очракта аларны уртак эчтәлек – милли фаҗиганең төрле ракурсларда, төрле төсмерләрдә сурәтләнеше берләштерә. Язучы милләтнең төп фаҗигасен руслашуда гына түгел, ә чын татарга хас яшәү рәвешен югалтып, кавем буларак, котылгысыз рәвештә үзгәрүгә таба баруда, табигый сыйфатларны тулысынча югалту, эчке һәм тышкы бөтенлектән баш тартуда күрә. Милләт фаҗигасе мотивы А. Хәлимнең һәр хикәясендә үзенчәлекле, алар бер-берсен кабатламыйлар, язучы әлеге теманы төрле яклап ача. Аның хикәяләре бергә тупланып, тулы бер картинаны тәшкил итә.

Милли тема Ркаил Зәйдулла иҗаты өчен дә ят түгел. Язучы милләтнең фаҗигасен хикәянең тар мәйданында бөтен тулылыгы белән ачып бирә. Мәсәлән, «Сөембикә» хикәясендә югары даирәгә каршы чыга алмыйча кызын әрмәнгә кияүгә биреп җибәргән атаның йөрәк әрнүе дә, үз балаларын яклый алмаган «үксез ил»гә рәнҗеш тә бик тәэсирле бирелгән. Авылга эшкә килгән әрмәннәрнең берсе чибәр горур кыз Сөембикәгә гашыйк була. Авыл егетләрен дә үзенә якын китермәгән кызны атасы, бер йорт хакына, әрмәнгә «сата». Автор-хикәяләүче әрмән якларына барып чыккач, авылдаш кызы белән күрешә. Әсәрне укыгач, күңел әрни, рәнҗү хисләре

туа. Күпме юллар үтеп тә, ялгыш кына табан астына эләгеп һәлак булган тычкан бу хисне тагын да көчәйтә. Хикәядә мин исеменнән сөйләүченең авыл егетләренә дә баш бирмәгән горур кызның әрмәнгә ияреп китүенә каршы төшә алмавын сурәтләү аша язучы безнең бөтен илнең чарасызлыгын күрсәтә. Безнең халкыбыз да шушы хәлдә түгелме соң?! Төп герой исеменең татар ханбикәсенеке белән тәңгәл килүе тарихның хурлыклы сәхифәләрен искә төшерә. Һәм ул гади бер авылда булган хәлне әнә шулай, кечкенә деталь аша гына моннан әллә ничә гасыр элек булган вакыйгалар белән бәйли. Р. Зәйдулланың әлеге хикәясе үз балаларын яклый алмаган милләткә рәнҗеш булып яңгырый.

Милләт, аның бүгенгесе, киләчәге хакында фикер йөртеп, язучылар тарихка да мөрәҗәгать итә. Үткән аша бүгенгегә бәя бирү, хәзерге тормышта барган вакыйгаларның сәбәбен ерак тарих аша күрсәтү күзәтелә. 1980 елларда романтик рухлы тарихи хикәяләрнең югары үрнәкләрен Ркаил Зәйдулла иҗат итте. «Бу жанр төрендә ул, тарихи вакыйгаларны хыялда тергезү белән генә чикләнмичә, замандашлары өчен үткен булган мәсьәләләрне вакытка бәйсез гомумкешелек проблемалары төсендә яктыртуга иреште» [Заһидуллина, 2006, б. 200]. «Тәңре кылычы» хикәясенең сюжет сызыгын һуннар белән румнар арасындагы каршылык сурәтләнеше тәшкил итә. Хикәядә безнең эрага кадәр IV гасырда булган вакыйгалар тасвирлана. Язучы җир, дәүләт, хакимият өчен көрәшнең мәңгелек булуын күрсәтә.

Гасырлар чиге татар әдәбиятының хикәя жанрында төп игътибар кешегә, аның эчке дөньясына, рухи халәтенә юнәлтелә. Әлеге кеше тормышның катлаулы борылышларында юлын, киләчәккә өметен югалткан. Өметсезлек, чарасызлык мотивы Н. Гыйматдинованың «Шәһәр хатыны» хикәясендә дә калку бирелгән. Үзәктә – гаилә арбасын үз җилкәсендә тартып барган хатын-кыз образы. Ул балалар анасы да, гаиләне туендыручы да, җәмгыятькә хезмәт итүче булырак та тасвирлана.

Сугыш тәмамлануга шактый еллар узса да, ул вакыйгалар, тыл тормышы сурәтләнеше актуальлеген югалтмый. Бу темага язылган хикәяләрнең бер юнәлешендә җиңү алып килгән ветераннарның бүгенге хәле, аларның сугышта кичергәннәрен оныта алмавы, тән һәм җан яраларының яңаруы тасвирлана. XX гасыр ахырында моңа кадәр тыелган күренешләрне сурәтләү мөмкинлеге туа. Совет чоры әсәрләрендә тылдагы авыр хезмәт, җиңүгә ышаныч, фронтка ярдәм итү максаты белән янып яшәү сурәтләнсә, XX гасыр ахырында хикәяләрдә бу вакыйгалар бөтенләй башка яктан ачыла. Үзгәрешләр 1960–1980 елларда ук башланып китә. Хәрби-патриотик теманы үзәккә алган әсәрләрдә батырлыкка соклану икенче планга күчә, алгы планга батырлыкның чыганакларын эзләү, сугышның ачы фаҗигасен реалистик сурәтләрдә бирү чыга. М. Хуҗин «Бәрәңге чәчәге» (1994), «Укалы карлар»

(1992) кебек хикәяләрендә сугышның аяныч чынбарылыгын бәян итә. Сугыш чорында хатын-кызларның аянычлы язмышы «Бәрәңге чәчәге» (1994) хикәясендә башка яктан сурәтләнә. Заманында язучыны гаепләүгә сәбәпче булган бу хикәядә безнең тормышның аянычлы хакыйкате ята. Әсәрдә тол хатыннарның фаҗигасе реалистик сурәтләр белән тасвирлана. Соңрак, бу тема хикәя мәйданында сынау үткәч, повесть-романнарга да күчә (мәсәлән, М. Әмирхановның «Гөлнәзирә» повесте). Хикәядә татар әдәбиятына ят булган натуралистик күренешләр тасвирланса да, язучының сурәтләү осталыгы, аерым детальләрдән урынлы файдалана белүе аркасында әсәрнең сәнгати матурлыгы югалмый.

Хәзерге әдәбиятта җиңү яулаган ветераннарның бүгенге тормышы сурәтләнгән әсәрләр дә еш очрый. Аларда сугышның дәһшәтле елларын искә төшерүләр, фаҗигале еллар истәлеге булган яраларның яңаруы сурәтләнә. Хикәяләрнең үзәгендә илебез азатлыгы өчен яшьлекләрен биргән, кан койган ветераннар өчен әрнү мотивы үзәккә чыга. Мисалга Ф. Яруллинның «Өзелгән өмет», Р. Габделхакованың «Соңгы һөҗүм» хикәяләрен карыйк. Беренчесендә үзәктә туган ил азатлыгы өчен кайчандыр авыр сугыш юллары үткән, кан койган ветеран сурәтләнә. Хикәя әрнү, чарасызлык мотивы белән сугарылган. Төп мотив әсәрнең исемендә үк чагыла – өзелгән өмет, ягъни өметсезлек мотивы. Әсәрдә кеше һәм җәмгыять каршылыгы калку күрсәтелә. 9 май хөрмәтенә ветераннарга телевизор бирәләр дигән хәбәргә өметләнеп яши башлыйлар. Бу көнне бигрәк тә ветеранның онытгы көтә. Ләкин өметләр акланмый, район үзәгеннән «сиңа тиеш түгел» дип кайтаралар. Ветеран картның, оныгына безнең җәмгыятьнең гадел булмаган кануннар буенча яшәвен күрсәтмәс өчен, үлемтек акчасына телевизор алып кайтуы әрнү хисен тагын да көчәйтә.

Рәмзия Габделхакованың «Соңгы һөҗүм» хикәясендә дә үзәктә заман тарафыннан кыерсытылган ветеран сурәтләнә. Картларның кешегә тиз ышануыннан файдаланып, яхшы күңелле булып кыланып, Марсель исемле егет картның пенсиясен, җыйган соңгы акчаларын алып китә. Икенче бер картның да шундый бәлагә тарыганлыгын очраклы рәвештә ишетеп, бабай теге «изге затның» инде икенче кешене үз кармагына эләктергәнен аңлый. Карт хәйлә юлы белән аферист егетне һәм аның эшнәләрен үз өендә бикләп яндырып үтерә. Ахырда картның үзенең дә үлеп китүе мондый аферистларга карата нәфрәт хисен тагын да көчәйтә, заман, җәмгыять өчен борчылу уята.

Әдәбиятта мәңгелек темаларның берсе булган – мәхәббәт темасын да хикәя жанры ХХ гасыр ахыры – ХХI гасыр башында читтә калдырмый. Ярату, сөю, ир белән хатын, ана һәм бала арасындагы мөнәсәбәтләрне яктыртуга аеруча хатын-кыз язучыларыбыз киң урын бирә. ХХ гасыр ахырында әдәбиятка бер дулкын булып килеп кергән хатын-кыз авторларыбыз хикәя жанрында актив эш алып бара. Нәбирә

Гыйматдинова, Рифә Рахман, Рәмзия Габделхакова, Роза Мулланурова, Асия Юнысова, Халисә Ширмән, Дания Гайнетдинова, Гөлзадә Бәйрәмова, Фирүзә Җамалетдинова кебек «әдибәләр үз күңелдәгеләрен укучыга гына түгел, геройларының, бигрәк тә героиняларының төп-төгәл рәвешләрендә үзләренә дә аңлашылып җитмәгән чуар психологик халәт айкалышларын, фәкать хатын-кыз логикасы аша гына хәл ителерлек сюжет маҗаралары кызыклы хикәяләргә әвереллерәләр» [Сверигин, 2009, б. 88]. Хикәяләр көчле лиризм белән сугарылган. Аларга тормышта һәркөн кабатлана торган гади ситуация, тик шулар арасына хатын-кыз язучыларыбызның гына күзенә күренгән бик нечкә төсмерләр килеп керә, алар укучы күңеленең нечкә кылларына тәэсир итә. Хикәяләрнең төп тематикасы – мәхәббәт, гаилә, ана һәм бала мөнәсәбәтләре. Ләкин һәр әдибә бу тематикага үзенчә килә, аны индивидуаль яктырта.

Мәхәббәтнең төрле төсмерләрен ачуга юнәлтелгән лирик, лиро-эпик, романтик хикәяләр белән берррәттән, хатын-кыз прозаикларыбыз яшәеш, аның асылы, яшәү һәм үлем фәлсәфәсе, кешенең үз урынын эзләү кебек мәсьәләләрне яктыртуга да киң урын бирә. Мәсәлән, Ф. Җамалетдинованың «Таш чыгаручы», «Эш тәме» әсәрләрен фәлсәфи хикәя төренә кертеп карарга була. Аларның икесендә дә сүз эштән тәм табып, кешеләргә шатлык китереп яшәүче картлар турында бара. Берсе өлгергәннәрен генә сайлап, су төбеннән таш чыгара. Шул ташларны ватып, мунча ташы эзләүчегә бик аз гына хакка сатып бирә. Аңа алмашка яшьлеген Себер ягында, шахтада эшләп үткәргән ир кайта. Картның да, ирнең дә хикәядә исемнәре юк. Һәм моның әллә ни әһәмияте дә юк: автор аларны нииндидер фәлсәфи биеклеккә күтәрә, карт белән ир – игелекле эшнең дәвамчыл булырга тиешлеген күрсәтүче символлар буларак кабул ителә.

Яшәешнең асылына, тормыштагы мөнәсәбәтләр һәм бәйләнешләрнең үзенчәлегенә төшенергә тырышу татар әдәбиятында XX йөз башында ук киң колач ала. Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Ә. Тангатаров, Ф. Әмирхан, М. Гафури һ.б. үзләренең әсәрләрендә бу сорауларга җавап эзлиләр. Язучылар яшәешнең мәгънәсезлеге, максатсызлыгы, кешенең ялгызлыгы һәм көчсезлеге хакында бәян итәләр. XX йөз башында кешене чарасыз, көчсез ясый торган Үлем, Өмет өзелү, Гөнаһ һәм Җәза, Хакыйкать кебек төшенчәләр тирәсендәге бәхәс хикәячеләр иҗатына азык була. Мәсәлән, Ә. Тангатаровның «Анама» (1910) хикәясе герое – ялгыз. Символлар кулланып, автор тормышны – диңгез, кешене – шул диңгездәге ялгыз көймә белән чагыштыра. Хикәядә яшәү өметтән үлемгә кадәр ара итеп күрсәтелә. Герой яшәүнең мәгънәсен тапмый, ул бер ярдан икенчесенә ташлана һәм хикәя үлем теләү белән тәгалләнә. Ф. Җамалетдинова үзенең хикәяләрендә гасыр башындагы фикерләргә каршы чыга. Язучы «Таш чыгаручы» һәм «Эш тәме» хикәяләре геройлары үрнәгендә

яшәүнең мәгънәсе барлыгын исбатлый. Беренче әсәрдәге карт та, XX йөз башы әдәбияты геройлары сыман, ялгыз. Язучы символик мәгънә салынган табигать күренешләре ярдәмендә картның ялгызлыгына кат-кат басым ясый: «ялгыз кош моңы», «ялгыз-ялгыз сикерешкән дулкыннар». Ләкин карт ул кадәр үк ялгыз түгел икән, аны башкалар белән бәйләүче җеп бар. Хикәядә ул – таш. Карт үзен кешеләргә кирәкле итеп тоя. Аның бу дөньяга фәлсәфәсе әсәрдә болай бирелә: «Дөньяда ялгызлык дигән татлы газап бар. Яшәү бары тик шушы газаптан тора. Бу галәмдә барча җан ияләре япа-ялгызлар, әмма еш кына кумәк, бергә булып күренергә тырышалар. Минем яшәү тамырым менә шушы ташлар инде. Арадашчыларым алар. Кешеләр күңеленә алтын күперем – шулар». Тик бер мизгелгә, ир кайткач һәм аның эшен дәвам итәргә теләк белдергәч, карт үзенең дә бу дөньяда мәңгелек булмавын аңлый. Ләкин шулай да аның өмете сүнми: «Әйе, кешеләр барыбер онытмаслар. Ташчы карт китергән иде. Искерде шул, пары сүрән, диярләр. Миңа да кирәк, дип каршы чыгар тирә-күршеләре. Онытмаслар, юк, онытмаслар», – ди ул.

Әсәрләрдән күренгәнчә, гасырлар чиге хикәяләренең төп тематикасы – кеше һәм җәмгыять. Язучылар кешенең күңелен, хискичерешләрен, заман үзгәрүнең аңа тәэсирен сурәтләүне үзәккә алалар. 1960–1980 елларда популяр булган авыл темасы хәзерге татар әдәбиятында югалмый, ул үткәндәге авылны сагыну, аның юкка чыга баруына, шуның белән бергә милләтнең рухи-әхлакый сыйфатлары югалуга әрнү төсмерен ала. Шулай ук мәңгелек мотивлардан мәхәббәт мотивы да хәзерге хикәяләргә ят түгел. Сөю хисләре дә, күп очракта, авыл белән бәйләнештә ачыла. Геройлар, еш кына, яшьлекләрендәге сөйгәннәрен сагыналар, озак еллар узгач, очрата һәм авылда узган яшьлеген, аннан китү сәбәпләрен исләренә төшерәләр. Сөю, ярату, җавапсыз мәхәббәт, үкенечле аерылу хатын-кыз әдибәләр хикәяләрендә аеруча еш очрый. Хәзерге хикәяләрнең үзәгендә җиде юл чатында калган, кыйбласын, барыр юлын югалткан герой сурәтләнә. Аның чарасызлыктан бәргәләнүе, юл эзләве хикәяләрнең сюжет сызыгына әверелә.

**Әдәбият**

*Закирҗанов Ә.* Яңарыш юлыннан (хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 303 б.

*Заһидуллина Д.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

*Рахман Р.* Хәзерге хикәя / Дискуссия: Хәзерге хикәя // Казан утлары, 2009. № 5. Б. 163.

Сверигин Р. Хәзерге хикәя / Дискуссия: Хәзерге хикәя // Казан утлары, 2009. № 5. Б. 163.

***Насибуллова Гүзәл Ришат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең тел һәм мәдәниятара багланышлар кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145:82-1

***Н.М. Юсупова***

# 2017 ЕЛДА ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ: СТИЛЬ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЖАНРЛАР ҮСЕШЕ

В статье представлена эстетическая природа развития татарской поэзии в 2017 году. На материале лирических и лиро-эпических произведений выявляются стилевые тенденции, проявляющиеся на уровне принципов и приемов художественного изображения, жанровой парадигмы и образной структуры текстов. В ходе исследования определяются новые тенденции в концепции лирического героя.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, лирический герой, стилевые тенденции, образ, жанр, литературное направление.

2017 елгы татар шигъриятендә кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган әдәби модель дәвам иттерелә, үстерелә. Лирик геройның хыялый-идеалистик омтылышларын, хискичерешләрен сурәтләү объекты итеп алган романтизм һәм җәмгыятькә бәя бирүгә юнәлтелгән реализм юнәлешләре төрле стиль тенденцияләре белән байый, модернистик, постмодернистик алымнар йогынтысында үсә-үзгәрә [Загидуллина]. Шул ук вакытта шигъриятнең жанрлар төрлелеге ягыннан да бай һәм үзенчәлекле булуы, бу өлкәдә эзләнүләрнең, сәнгати экспериментларның урын алуы күзгә ташлана.

Соңгы елда татар укучысына шактый күләмдә поэтик әсәрләр тәкъдим ителгән, башка еллар белән чагыштырганда, сан ягыннан зур аерма күзгә ташлана. Иҗат психологиясен өйрәнгән галимнәр җәмгыятьтәге борылышлар вакытында, бер этаптан икенчесенә күчеш чорында сүз сәнгатенең поэзия төре алга чыгуын билгели. Татар шигърияте тарихына күз салсак та, без бу фикернең хаклы булуын, борылыш, җәмгыятьтәге ниндидер үзгәрешләр чорында, иң беренче чиратта, шигъри сүзнең аваз салуын күрербез. Соңгы вакытта барган күренешләргә фикер белдерү омтылышы, үз тавышыңны ишеттерү теләге бүгенге татар шагыйрьләренә дә хас. Шагыйрьләрнең вакытлы матбугат битләрендә укучыга тәкъдим ителгән күпсанлы лирик һәм лиро-эпик әсәрләре шул хакта сөйли.

Жанрлар ешлыгына килсәк, 2000 еллардан соң күңел лирикасы һәм фәлсәфи лириканың алга чыгуы күзәтелсә, соңгы елда гражданлык лирикасының активлыгы күзгә ташлана. Бу яктан Р. Вәливның «Казан утлары» журналының беренче санында ук дөнья күргән «Яңа елның яңа таңы ата» дигән шигыре программ әсәр булып кабул ителә:

«*Яңа елда могҗизалар көтеп, / Оран салам сезгә, карабайлар! – / Яңа елда, бәлки, берәрегез / Милләт зарын илдә бер абайлар... / Яңа елның яңа таңы ата, – / Йоклаганнар кайчан уяныйрлар?..*» [Вәлиев, б. 3].

Гражданлык һәм сәяси лирика жанрлары, традицияләрне дәвам итеп, иҗтимагый тормышка, җәмгыятьтәге вазгыятькә, милләт тормышына аерым игътибар бирә, заманга, милли сәясәткә хас проблемаларны калкытып куя, лирик геройның гражданлык позициясен ассызыклый. Шунысы үзенчәлекле: соңгы елда дөнья күргән шигырьләрдә ике жанр арасындагы чикләрнең югала баруы күзгә ташлана. Бердән, моңа соңгы еллар шигърыятендә барган жанрлар синтезы, жанрлык сыйфатларының керешеп китү үзенчәлеге йогынты ясаса, икенчедән, ул гражданлык лирикасында иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрнең тирәнәюе белән аңлатыла.

Гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле әсәрләрдә иң төп мотив булып милләт язмышы калкулаша бара, кагыйдә буларак, татар милләтенең, татар теленең киләчәге, аның ил тормышындагы урыны, роле, милли битарафлык, ваемсызлык мәсьәләләре күтәрелә [Юсупова, 2014, с. 128]. Билгеле, татар шигърияте XX гасырның дәвамында милли яшәешне алга җибәрү процессын әйдәп бара, милли идея, милли яшәеш фәлсәфәсе теләсә кайсы чорда да үзкыйммәтен югалтмый. Милли үзаңны үстерү, милли рухны тирәнәйтү омтылышы быелгы шигырь-поэмалар өчен дә актуаль. Мәсәлән: М. Мирзаның «Сабырлык сорыйм ялварып...», Р. Низаминың «Казансуда ятим җилләр йөри...», Л. Шәехнең «Татар көйләре» дигән шигырь бәйләмнәре, А. Хәлимнең «Туган тел», Р. Шәриповның «Бу – безнең җир!», Р. Аймәтнең «Тормыш поезды», Р. Корбанның «Татар күзләре», Р. Газизовның «Татар моңы булып агыла», Ф. Җамалетдинованың «Шәһри Болгар, саумы», Г. Батталованың «Син көчле бит, диләр...», Л. Янсуарның «О-ныт-мас-ка» һ.б. бик күп сандагы шигырьләр шул хакта сөйли. Шул ук вакытта гражданлык лирикасында публицистик башлангычның көчле булуы күзгә ташлана, җәмгыятьтә булып узган вакыйгаларга, үзгәрешләргә мөнәсәбәтне, фикерне турыдан-туры җиткерү омтылышы алга чыга.

Гражданлык лирикасының бер өлешендә совет чоры шигърыятенең «рәсми булмаган» канатында иң еш мөрәҗәгать ителгән эзоп теле төп алым булып кала: җәмгыятькә, андагы кануннарга бәя-мөнәсәбәт метафора-символларга төреп тәкъдим ителә. Мәсәлән, Зиннур Мансуровның «Бөркет күләгәсе» шигырендә милләт язмышы проблемасы буш, иллюзияле идеалларны, хыялларны символлаштырган бөркет күләгәсе, шул хыялларның җимерелүен аңлаткан аргамактан егылып төшү, идеал дип саналган күренешләрнең буш булуы символик образлар, сурәтләр аша күтәрелә.

Эчке эчтәлек Р. Рахманның «Татарстан урамыннан барам» шигырендә дә көчле: тел

аңлаучы бердәнбер образ итеп һәйкәл һәм чәчәк образларын алу тел мәсьәләсенең кискенлегенә, гомумкулланылыштан югала баруына ишарәли. Л. Шәехнең «Инглиз имәннәре» шигырендә боек һәм бөек имән образлары аша ачылган эчке, яшерен эчтәлек ике төрле яшәешкә дучар ителгән ил-халыкны капма-каршы куеп сурәтләргә мөмкинлек бирә, шулар аша автор милләтнең алга таба үсеше өчен мөһим булган шартны символлаштыра: *Алар туа үз бәхете белән / Үсү, яшәү – алар иркендә, / Бер агач та комачаулык итми, / Киртә булып тормый беркемгә* [Шәех, б. 54].

Күп кенә шигырьләрдә милләт язмышына бәйле иҗат мотивы урын ала, әсәрләрдә милли теманы танылган шәхесләр образларына мөнәсәбәтле ачу алымы актив кулланыла. Р. Корбанның «Шагыйрьләр – тел сакчылары имеш», «Җәлил», Л. Шәехнең «Ни диярбез?», «Тауга карап», «Шагыйрь юлы», Г. Бәйрәмованың «Шигырь сатам...», Б. Ибраһимовның «Бу көннәрдә мин дә яза алмыйм» шигырьләрендә иҗат кешесенең, шигъри сүзнең кадерсез булуы хакында сүз алып барыла, җәмгыятьтәге әхлаксызлык күренешләренә бәя бирелә. Мисал өчен, Б. Ибраһимовның «Бу көннәрдә мин дә яза алмыйм» шигырендә иллюзиялелек күренеше лирик геройның яңа статуска күтәрелүе аша яктыртыла. Ул үзенең бүгенге халәте, яза алмау сәбәпләре хакында сөйли һәм аларны идеаль тормыш омтылышлары белән янәшә куеп сурәтли. Әмма реаль тормыш-яшәешнең хыялдагы омтылышларны чынга ашырырга мөмкинлек бирмәве әрнү хисен көчәйтә. Г. Бәйрәмова «Шигырь сатам...» шигырендә интертекстуальлек алымына мөрәҗәгать итә, «шигырь сатам, шигырь, кем ала?» юлларында билгеле гыйбарәне уйнатып, аны текст эчендә кабатлап, сүз кадере беткән бу заманда шигърияттнең үксез-ятим бала хәлендә калуы, кадерсез булуы хакында сөйли.

Гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле күп шигырьләрдә тел язмышы үзәк мәсьәлә итеп күтәрелә. А. Хәлимнең «Семен Денисович Игнатьевка», «Туган тел», Р. Корбанның «Терәү», Айрат Суфияновның «Тыелганны татып», «Шул ук», Г. Рәхимнең «Кызыл әтәч», Р. Аймәтнең «Тормыш поезды», Р. Мөхәммәтшинның «Әлли-бәлли-бәү», Ф. Мөслимованың «Патша белми», «Дию абындымы?», «Ялгыз скрипкачы», Р. Шәриповның «Бу – безнең җир!» кебек шигырьләре, Р. Низаминың «Казансуда ятим җилләр йөри...», «Хәтер үзәнендә тора сакта», Л. Леронның «Мин туялмам җырлап үз халкымны, мин туялмам җырлап Тукайны», Э. Шәрифуллинаның «Очыш» шигырьләр бәйләме гражданлык лирикасында иҗтимагый барышка бәя мотивының калкулануы турында хәбәр итә.

Мондый шигырьләрдә иң төп алымнарның берсе булып демифологизация – мифны җимерү алымы аерылып чыга. Соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрдә совет әдәбияты мифлаштыру әдәбияты дип бәяләнә. Бу

очракта әдәбиятның идеология фикерләрен җиткерү мәйданына әверелүе, 1917 елдан соң сүз сәнгатенең яңа идеологияне популярлаштыру максатында файдаланыла башлавы күздә тотыла. Әлеге күренеш татар поэзиясенең рәсми канатында шундый ук идеалистик эчтәлеккә йөз тоткан һәм кулланылышы ягыннан мифологик структурага ия ил, байрак (әләм), көрәшче, дошман кебек образларны мәйданга чыгара. Соңгы елда дөнья күргән шигырьләрдә шуның киресе – мифны җимерү алымы көчле, ләкин шунысы кызыклы: татар шигърияте шул ук ил, әләм, көрәшче образларына мөрәҗәгать итә һәм аны капма-каршы – демифологик функциядә куллана. Бу – шигъриятнең матур табышы. Әйтик, Зиннур Мансуровның «Чүпчар тавы» шигырендә чүп-чар тавы образы артына кешелек кереп баткан тормыш-яшәешне гәүдәләндерә. Каткан күмәч, ертык дога бите, шәрә курчак, зәһәр шешә бөкесе образлары ярдәмендә дин, иман, әхлак җимерелүе хакында сүз алып барыла, шулар янәшәсенә ертык әләм образы килеп керә дә шигырьне бөтенләй яңа мәгънәләр белән баета. Татар шигърияте тарихыннан мәгълүматлы укучы өчен әләм, ил образларының кулланылышы әсәрне сәяси яссылыкка күчерә. Шагыйрь әхлакый кыйммәтләр янәшәсендә сәяси кыйммәтләрнең дә югалуы, ялган идеалларның җимерелүе хакында сүз башлый.

Ф. Мөслимованың «Патша белми», Фирүзә Җамалетдинованың «Сүз калган», Л. Леронның «Өзеклек» кебек шигырьләре дә мифны җимерү алымына йөз тота. Шигырь кысасында ил, көрәшче, коммунизм, юлбашчы образлары тулысынча сәяси эчтәлекле мифологик вазифасын югалта: *Патшалары киткән... Сүз калган / Алар телендәге ул сүзләрдә / ачыла гына бара һәр ялган / коммунизм төзеп булмаса да, / юлларны гел төзеп торалар* [Лерон, б. 34]. «Өзеклек» шигырендә Л. Лерон Ленинның «укырга, укырга, укырга» лозунгы тибында «түзәргә, түзәргә, түзәргә», «сабырлык, сабырлык, сабырлык» шигарьләрен язып, бер яктан, тормыштагы һәр өлкәдә өзеклек баруын, икенче яктан, тормыш-яшәештәге барлык кыйммәтләрнең иллюзия булуын җиткерә.

Р. Аймәт, Р. Мөхәммәтшин шигырьләрендә шигъри кулланылышка кертелгән Дию мифологик образы да шундый ук вазифа башкара һәм дөнья сурәте артына яшеренгән субъектив эчтәлек татар халкының халәт-яшәешен ачуга юнәлтелә. Р. Вәлиев, С. Әхмәтҗанов, Р. Мөхәммәтшин шигырьләрендә шушы максаттан йокы мотивы отышлы кулланыла. Әлеге мотивка бәйләп аларның «Яңа елның яңа таңы ата», «Давыл», «Йоклар әле бу ил чак кына...», «Әлли-бәллибәү» шигырьләрендә нәзари яктан интертекстуальлек алымы кулланылуы турында әйтә алабыз.

Аерым лирик үрнәкләрдә башка иҗади тәҗрибәләр дә күзгә ташлана. Мисал өчен, Л. Янсуарның «Югыйсә» шигырендә типик мозаик сурәтлелек урнаштырыла: тынлыкның түреннән

Иделне кубарып җил исә, Актырнак өрүе ишетелә, көтү куыла, шулар янәшәсендә ил сурәте калка, тузганак таҗларын, шашынган карларны күрәү турында сүз башлана. Әлеге фрагментар детальләр автор фикерен ачыклауга юнәлтелә: «*Үзгәреш көтәбез... кемнәндер! Офыкта бер күкрәү уяна! Ул.., бәлки, соңарган сөрәндер...*» [Янсуар, б. 96]. Бу юллар һәм бер карашка бер-берсенә бәйләнешсез сурәтләр милләтнең зурдан кубып, вак эшләр белән шөгыльләнүе, шулардан зур мәгънә эзләве, системалылык булмау турында сөйли. Милләт хәтере генә безне туры юлга ирештерә алачак! дип дәшә шагыйрә.

Гражданлык лирикасындагы лирик герой концепциясендә барган үзгәрешне дә билгеләп үтәргә кирәк. Иҗтимагый кануннарны аңларга-бәяләргә омтылучы гражданин лирик герой булып күзаллана. Әсәрләрдә ул 1960–1980 еллар татар поэзиясе традицияләрен дәвам итеп, тормыштагы хаксызлыкны күреп-аңлап та, турыдан-туры каршы чыгарга үзендә көч тапмаган, үз-үзе белән каршылыкта, эчке борчылу халәтендә яшәүче лирик герой булып формалаша.

Р. Аймәт «Тормыш поезды» шигырендә бу тип лирик геройны *чылбырланган вагоннарда барган зынҗырлы җаннар* [Аймәт, б. 76] сурәте аша чагылдыра. Р. Вәлиев, Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин, Р. Низами, Р. Аймәт, И. Гыйләҗев, Г. Рәхим, Б. Ибраһимов шигырьләрендә дә шушы тип лирик герой алга чыга һәм шагыйрьләр тарафыннан чор кешесенең эчке халәте сурәтендә тәкъдим ителә. Р. Низами аның каршылыгын шигъри телдә болай бәяли: *Әй, син, диңгез, беләсеңме икән, / Аңлыйсыңмы икән, аппагым, – / Кош кадәрле нәни йөрәгемдә / Тугыз баллы дулкын ятканын*. Бүгенге шигъриятә мондый каршылык әдипләрнең җәмгыятьтәге вазгыятькә бәйле сызлануын җиткерүгә буйсындырыла. Р. Вәлиев, Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин соңгы елда дөнья күргән шигырьләрендә лирик геройның үз-үзе белән каршылыкта яшәве эчке ирония алымы аша тирәнәйтелә.

Гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле икенче төркем шигырьләрдә лирик герой хөр фикерле актив, вакыты белән гыйсьянчы булып мәйданга аваз сала, тормыш-яшәешкә, үзе яшәгән җәмгыятькә һәм анда барган үзгәрешләргә, милли проблемаларга үз бәясен, фикерен, мөнәсәбәтен ишеттерергә омтыла. «*Сөенмәсеннәр, таптадык, диеп, / Баш күтәрербез көлдән яралып!*» дип аваз салган гыйсьянчы герой, нигездә, Р. Зәйдулла, Н. Сафина иҗатларында алга чыга. Соңгы елларда символик, шартлы сурәтлелеккә борылган Р. Зәйдулланың шигырьләрендә кабат гыйсьянчы лирик герой традициясе яңартыла. Аның тышкы тирәлек белән каршылыкка керүе, «*Тартышып яшибез һаман да, / хак бар яшәргә безнең дә*!» – дип, күнегелгән тәртипләргә, сәясәткә, мәдәни хәл-халәткә каршы чыгуы белән дәлилләнә. Н. Сафинаның да лирик герое шул ук сыйфатларга ия, шагыйрәнең «*Карганмыйм*

*да, тиргәнмим дә, оран салам, тыңлагыз*» [Сафина, б. 157] дип кычкырган лирик героена усаллык та, барлык тәртипләрне җимерергә омтылу да хас. Шушы ук сыйфат Р. Мөхәммәтшинның «Бер генә», «Васыять», «Вакыт җәнаплары» кебек шигырьләрендә дә күзәтелә, алардагы һәр образ, деталь, өзек-өзек сурәтләр шигырь структурасында лирик геройның дөньяга ачу-үпкәсен, ләгънәтен ачуга, тәэсирлелекне көчәйтүгә буйсындырыла.

Икенче актив жанр – күңел лирикасы. Әлеге жанрда авыр кичерешләрдән юануны балачактан, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, мәхәббәттән, туган як җылысыннан эзләгән хисчән лирик герой беренче планга чыга һәм поэзиягә лирик-эмоциональ, вакыты белән сентименталь рух өсти. Бу жанрга мөнәсәбәтле шигъри әсәрләр, нигездә, мәхәббәт темасын үз итә яки туган як темасын алга куя. Бу юнәлештә Р. Гаташ, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Ф. Зыятдинов, Л. Лерон, Р. Сүлти, Р. Мөхәммәтшин шигырьләре уңышлы. Хатын-кыз шагыйрәләр иҗатында К. Булатова, Р. Рахман, А. Юнысова, Ш. Җиһангирова, Ф. Җамалетдинова, И. Иксанова, Э. Сафина, Э. Шәрифуллина, Л. Янсуар, Л. Гыйбадуллина, Г. Корбанова, Л. Вәлиева, Д. Нәгыймуллина әсәрләре җылы кабул ителә.

Мәхәббәт темасына язылган шигырьләрдән Р. Рахман шигырьләре уңышлы кабул ителә, шагыйрәнең матур гына поэтик табышлары бар. Мәсәлән, «Идел» журналында дөнья күргән «Иреннәрем сусылланып китәр, керфек очларына иелсәң» шигырьләр бәйләменә тупланган шигъри үрнәкләрдә шагыйрә гомер көзендә мәхәббәт кадере хакында сүз башлый, шушы юлда шыгыр-шыгыр килгән ак яфраклар өеме, гөл, җепшек кар кебек үзгә эчтәлектәге шартлы-романтик образ-детальләргә мөрәҗәгать итә. Шушы ук сыйфат белән без Р. Зәйдулланың «Фәрештә», «Күрән» шигырьләрендә дә очрашабыз. Бу жанрда Гөлүсә Батталова шигырьләре дә матур тәэсир калдыра, аның шигырьләренә төзек композиция, бай романтик образлылык, камил аһәң, эчке яңгыраш хас.

Л. Гыйбадуллинаның «Бер карышка – бер җан, бер карышка – мөлдерәмә тулы мизгел бары» шигырьләр бәйләме турында да аерып әйтәсе килә. Әлеге башлам астына тупланган шигырьләргә кабатлау алымы хас, бер үк элементларны, образларны кабатлау яңа мәгънә киңлегенә алып чыга, иллюзияле сурәтлелек, эзлекле, төзек композициядән китү сыйфаты чагыла. Авторның шигъри теле образлы, ул үз геройларын яңа сыйфатлар белән баета, бер-берсенә тәңгәлләшмәгән образларны янәшә куеп, аларның мәгънәви чикләрен киңәйтә: «*Мин сине тапмаган дөньяда / Язларың, язларың сызлана... / Илереп җил елый, тәрәзгә / Тымызык көн нуры сылана... / Мин әзер, карадан киенеп, / Күз булып сурәткә төшәргә*» [Гыйбадуллина, б. 31].

Г. Мөхәммәтшинның «Авылыма мәдхия», «Туган як», «Юлчыга», Г. Рәхимнең «Бәрәңге кәлҗемәсе», Р. Газизовның «Көтә

гармун», Р. Бәшәрнең «Тургай» кебек шигырьләрендә, Ф. Тарханованың «Капка» циклында туган як, туган авыл, балачак, әти-әни сурәте тергезелә. Әлеге үрнәкләр XX гасырның икенче яртысы татар поэзиясендә үсеш алган салмак лирика агымының дәвамы кебек кабул ителә. Мондый шигырьләр, кагыйдә буларак, күп катламга ия түгел, аларда субъектив эчтәлек яшерелми, гади-гадәти поэтик сөйләм алга чыга. Шагыйрьләр асыл ышанычны, рухи кыйбланы туган ягында, авыл кешесенең яшәү рәвешендә таба, авыл мохитен, яшәешен югары күтәрә, шигырьдәге образлардан башлап, вак детальләргә кадәр шушы максатка буйсындырыла. Бу урында Ф. Тарханованың «Капка» [Тарханова, б. 96] әсәре турында аерып әйтәсе килә. Романтик образ-детальләргә таянып язылган әсәрдә әти-әни янәшәсендә үткән балачакның бәхетле көннәрен искә төшерү якты моң һәм сагыш уята. Капка образы әсәр структурасында, гади капка келәсе образыннан үстерелеп, күңел капкасы, хәтер капкасы, бәхет капкасы, әхлакый идеаллар дөньясына алып чыгучы капка мәгънәләренә күтәрелә.

1917 елда дөнья күргән фәлсәфи лирикага мөнәсәбәтле шигъри әсәрләр, нигездә, яшәеш кыйммәтләрен аңлау-анализлауга йөз тота, аларда фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау омтылышы күренә. Мисал өчен, Р. Вәлиевнең «Һәйкәлләр», Ф. Сафинның «Мәңгелек бер көн», Р. Рахманиның «Куа заман», Ф. Җәмалетдинованың «Ком сәгате», Г. Бәйрәмованың «Нәрсә ул бәхет?» шигырьләре, Д. Нәгыймуллинаның «Уйлар», Рим Идиятуллинның «Хастаханәдә туган уйлар» шигырьләр циклы һ.б.ларда буыннар алмашы, кеше рухының бөеклеге, гомернең вакыт чикләрендә көчсезлеге хакындагы фәлсәфи фикерләр тәкъдим ителә.

Соңгы елларда фәлсәфи лирика үрнәгендәге дини мотивлар алга чыга башлады һәм алар дини текстларга стильләштереп иҗат ителә [Йосыпова, 2011, б. 56; Юсупова, 2015, с. 284]. Мисал өчен, И. Вәлиулланың «Ә беркөнне», «Өмет», «Тәкъвалык», И. Биектаулының «Бәйрәмнәр – олуг көннәр», Ф. Мөслимованың «Хәлифәбез юкса» кебек шигырьләрендә кеше гомере Аллаһ тарафыннан бирелгән бүләк итеп бәяләнә, язмышның алдан язылуы хакында сөйли, шуңа бәйле әт-тәүхид (бераллалык) идеяләре, ислам кануннарындагыча, язмышның Аллаһтан булуы мотивы алга чыга, замана чиренә әверелгән динсезлек-денсезлек өчен борчылу үзәккә куела. Ләкин бу юнәлештәге әсәрләрдә дидактик башлангычның, үгет-нәсыйхәтнең көчле булуын да билгеләп үтмичә мөмкин түгел, охшаш калыпка нигезләнгән образлылык өстенлек итә, фикерләр фәлсәфи югарылыкка күтәрелеп җитә алмый.

Татар поэзиясендә, 90 нчы еллардан соң Р. Гаташ үстергән традицияләрне дәвам итеп, көнчыгыш шигъри текстларына охшатып стильләштерү, трансформацияләү яки шәркый жанрларны тергезү дәвам итә.

Шуларның берсе – дүртьюллык – робагый жанры. Ул Фәнәвис Дәүләтбаев иҗатында урын ала. Аның робагыйлары төзелеше белән көнчыгыш әдәби традицияләренә нигезләнә: *Бу дөньяның агы, карасы бар, / Безгә монда гыйбрәт аласылар, / Намус-кыйбласыннан тайпылмаган, / Кеше булып җирдә каласы бар* [Дәүләтбаев, б. 145]. Авторның һәр робагыенда, шәркый традицияләргә хас булганча, әхлакый мәсьәләләр үзәккә куела; иҗтимагый-социаль кануннар да фәлсәфи-этик яссылыкта хуплана яки кире кагыла, рухи, әхлакый яңарышка өндәү мотивы көчле яңгыраш ала.

М. Мирза иҗатында, «Адәм баласы» шигырьләр циклының дәвамы булып, бишьюллык жанр формасы кабат мәйданга чыга. Көнчыгыш шигъриятендә киң кулланылган, милли шигърияттә «Туфан строфасы» буларак калыплашкан һәм лирик герой кичерешен, автор фикерен, текстларның яңгырашын, көен, хисси тәэсирен җиткерүгә йөз тоткан бишьюллыкны М. Мирза бөтенләй үзгә форма итеп төзүгә ирешә. Мәкаль-әйтемнәрне куллану, шигырь юлларын хикмәтле сүз әйтү традициясендәгечә төзергә омтылу, үзенә генә хас бик нечкә ирониягә, төртмәле кинаягә мөрәҗәгать итү – барысы да аның үзгәлеген, оригинальлеген тәэмин итә: *Комнан аркан ишеп, / Чүл корабын тарткан, / Адәм баласының / Табигать бер ишен / Хыялый яраткан* [Мирза, б. 41]. Алар, шәркый бишьюллыкларны стильләштерүдән бигрәк, татар шигърияте өчен үзгә жанр формасы буларак кабул ителә. Бу – аның матур табышы буларак бәяләнүгә лаек.

Татар шигърияте гаять авыр шигъри формалардан саналган сонет жанрында да каләмен сынап карый. Әлфия Ситдыйкованың «Вакыт – җитез болан» бәйләме форма ягыннан классик калыпта иҗат ителгән: ул 15 сонетны берләштерә, төзелеше, рифмалашу үзенчәлеге ягыннан да сонет жанры таләпләренә туры китереп эшләнгән (һәр сонет 4 строфалы, беренче икесендә тезмәләр саны – 4, соңгы икесендә – 3) [Ситдыйкова, б. 149]. Сонет романтик стильдә: лирик герой мәхәббәтне илаһилаштыра, әсәр тукымасы лирик герой халәтенә аваздаш табигать сурәтләре белән баетыла.

Флера Тарханованың «Халкым минем» триптихы да татар поэзиясенең жанр чикләрен киңәйтә. Триптих уртак идея, фикер тирәсенә берләшкән өч шигырьне туплаган жанр формасы буларак билгеле. Флера Тархановаң әсәре дә «Рух вә иман», «Моң», «Тел» кебек өч бүлеккә бүленә [Тарханова, б. 28–30]. Әмма бу бүленешнең эчке логикасы субъектив катламда ачыла һәм әлеге өч төшенчә милләт сагында торучы, татарны татар итүче төп сыйфатлар буларак кабул ителә.

2017 елда поэма жанрының сан һәм сыйфат ягыннан күтәрелеш кичерүе күзәтелә. Шулар арасыннан Р. Миңнуллинның «Сөю», Ф. Гыйләҗевның «Иске Казан – Кирмән нигезе», Р. Вәлиеваның «Яралы

язмыш» поэмалары татар поэзиясендә XX йөз башыннан формалашкан, Ф. Кәрим, С. Хәким һ.б. тарафыннан үстерелә килгән традицион стильне дәвам итеп мәйданга чыга. Лирик герой хикәяләүче, хис-кичерешне җиткерүче функциясен ала, теге яки бу тормыш вакыйгасының, мәхәббәт хисләренең сәбәбенә әверелә.

Р. Харисның «Яза башла!» трактат-поэмасы исә фәлсәфи эчтәлек белән өртелә, шагыйрь, шигырь, язу гыйбарәләре әсәрнең буеннан-буена уйнатыла, шулар аша шигырь намус, әхлак, иман, рухи ныклык, халкыңны ярату кебек иң югары идеаллар хакында булырга, шуларга хезмәт итәргә тиеш, дигән фәлсәфи фикер җиткерелә.

Р. Харисның «Уба» поэмасы структур яктан төрле катламнарның синтезын тәшкил итә. Әдәби, имтимагый-сәяси, фәлсәфи катламнар әдәби текстның үз эчендәге башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек ярдәмендә кушыла. Шагыйрь әсәр тукымасына Сталин турындагы җыр текстларын, сәяси лозунг дәрәҗәсендә кулланылган гыйбарәләрне урнаштыра, лирик геройның эчке каршылыгы, мифны җимерү алымнарыннан файдалана [Харис, б. 3–9]. Шуңа бәйле төстә Уба образы да катлаулы символик бөтенлек статусын ала: ул аерым кеше тормышындагы убалардан башлап, ил, тарих чоңгыллары, хәтер төпкелләре, шомлы фаҗигаләр тирәнлеге булып кабул ителә.

Соңгы елдагы шигъриятне күзәтеп чыкканнан соң, баллада жанрының «торгынлык» кичерүе күзгә ташлана. Дөрес, А. Хәлимнең «Казан утлары» журналында «Амур дулкыннары» дигән балладасы басылып чыкты. Әмма шагыйрь үзе куйган жанр формасы белән килешеп булмый, нәзари яктан ул гражданлык лирикасы таләпләренә җавап бирә. Әсәр кысаларында балладага хас романтик, символик-аллегорик яссылыкта геройларның кискен каршылыгына корылган сюжет, үткен каршылык, гипербола алымы күзәтелми.

Йомгаклап әйткәндә, 2017 елда дөнья күргән шигъри әсәрләр хәзерге шигърияттә гражданлык лирикасының алгы сафка чыгуын, шагыйрьләрнең иҗат принципларын, сәяси һәм милли кыйммәтләрне яңадан тагын бер кат күздән кичерүне дәлилли. Бүгенге татар поэзиясе шагыйрьләрнең милли нигезләргә йөз тотуы, элгәреге башлангычларны дәвам итүе, үстерүе, камилләштерүе, баетуы хакында сөйли. Нәкъ шушы сыйфатлар шигъриятнең гасырлардан гасырларга күчә килгән шигъри көченең сакланып калуын тәэмин итә. Традицион образларны яңа мәгънә калыплары белән баету, XX йөз башы татар поэзиясендә кулланылган, әмма соңгы чорда даими кулланылыштан читтәрәк калган алымнарны, образларны яңартып җибәрү, яңа формалар эзләнү һәрчак көнүзәк мәсьәлә булып санала.

**Әдәбият**

*Аймәт Р.* Һәрбер мизгеле изге // Казан утлары. 2017. № 12. Б. 76–79.

*Вәлиев Р.* Яңа елның яңа таңы ата... // Казан утлары. 2017. № 1. Б. 3.

*Гыйбадуллина Л.* Бер карышка – бер җан, бер карышка – мөлдерәмә тулы бер мизгел // Идел. 2017. № 11. Б. 30–31.

*Дәүләтбаев Ф.* Сагындырганы – яшьлек еллары // Казан утлары. 2017. № 11. Б. 143–146.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 268 с.

*Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә символлар. Казан: Казан унты нәшр., 2011. 120 б.

*Лерон Л.* Мин туялмам җырлап үз халкымны, мин туялмам җырлап Тукайны // Идел. 2017. № 4. Б. 34–36.

*Мирза М.* Сабырлык сорыйм ялварып... // Казан утлары. 2017. № 12. Б. 38–41.

*Сафина Н.* Кыч-кы-ра-а-а-ам! // Казан утлары. 2017. № 7. Б. 157.

*Ситдыйкова Ә.* Вакыт – җитез болан // Казан утлары. 2017. № 9. Б. 149–152.

*Тарханова Ф.* Моң таралды ачык тәрәзәдән // Казан утлары. 2017. № 5. Б. 96–99.

*Тарханова Ф.* Халкым минем // Идел. 2017. № 5. Б. 28–30.

*Харис Р.* Уба // Казан утлары. 2017. № 12. Б. 3–9.

*Шәех Л.* Инглиз дәфтәреннән // Идел. 2017. № 1. Б. 54–55.

*Юсупова Н.М.* Татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юллары // Казан утлары. 2014. № 3. Б. 127–134.

*Юсупова Н.М.* Возрождение религиозно-суфийской символики в татарской поэзии рубежа XX–XXI веков (на материале поэтических произведений Г. Салима) // Филология и культура. Philology and culture. 2015. №3(41). С. 284–287.

*Янсуар Л.* Тузганак таҗларын күрибез // Казан утлары. 2017. № 12. Б. 94–97.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы доценты*

Татар әдәбияты классигы, танылган җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый (Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков, 1878–1954) – XX гасыр төрки-татар иҗтимагый-сәяси тормышында тирән эз калдырган, аның рухи-мәдәни үсешенә көчле йогынты ясаган күренекле шәхесләребезнең берсе. Татар җәмәгатьчелеге быел бу могтәбәр затның тууына 140 еллык юбилей датасын билгеләп уза.

Совет чорында исеме онытылуга дучар ителгән әдипнең мирасын барлау, иҗатын халыкка кайтару эше узган гасырның 80 нче еллары азагында башланып китә. 1987 елда күренекле язучы Әмирхан ага Еники язучылар алдында Исхакый исемен аклау мәсьәләсен күтәргән көннән алып бүгенгә кадәр бу юнәлештә шактый зур эшләр башкарылды: Татарстан хөкүмәте карары белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Исхакыйның унбиш томлык «Әсәрләр» җыелмасы нәшер ителде, бу хезмәтне басмага әзерләгән галимнәр коллективы фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясенә лаек булды (2016 ел), әдип иҗаты хакында ике дистәдән артык кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклanды, туган төбәгендә мемориаль музее ачылды, Г. Исхакый исемендәге премия булдырылды, юбилей елларында халыкара фәнни-гамәли конференцияләр һәм башка чаралар уздырылды. Болар барысы бергә күп кешеләр көче, тырышлыгы, инициативасы белән өч дистә ел дәвамында зур, масштаблы эшләр алып барганлык турында сөйли.

Шулар беләр бергә, бүгенге көннең катлаулы вазгыяте җирлегендә Гаяз Исхакый исемен пропагандалау, иҗат мирасын халыкка тагын да якынайту, эшчәнлеге турында мәгълүматны киң җәмәгатьчелеккә, башка халыкларга да җиткерү юлында алда торган эшләребез, бурычларыбыз да байтак әле. Бүген иҗтимагый-сәяси һәм милли-тарихи карашларының киңлеге, концептуальлеге Гаяз Исхакыйның көчле фикер иясе, татар һәм төрки халыклар яңарышының лидерларыннан берсе булуына ныграк игътибар итү кирәклеген көн тәртибенә куя. Бу юлда әдипнең әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итү, Исхакый темасына мөнәсәбәтле барлык басма чыганакларны исәпкә алган библиографик күрсәткечен төзү, аның тулы тормыш һәм иҗат хроникасын эшләү зур адым булыр иде. Әлеге гамәлләрне башкарганда заман ихтыяҗларын тоеп эш итү, мирасны барлау һәм танытуның заманча алымнарын һәм ысулларын кулланып эш йөртү дә сорала.

Олуг әдипләрнең юбилей еллары аларның иҗатына игътибар артуга бер этәргеч булып тора. Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңае белән 2018 елның 6–7 сентябрендә «Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы» темасына узачак Халыкара фәнни-гамәли конференция әнә шундый чараларның берсе. Конференция Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырыла. Чарага әзерлек кысаларында Гаяз Исхакыйның бүгенге укучыга мәгълүм булмаган текстларын үз эченә алган «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. V чыгарылыш», әдипнең тормышын фотографияләр аша яктырткан «Гаяз Исхакый фотографияләрдә», аның иҗаты хакында йөздән артык фәнни мәкаләләрне туплаган конференция җыентыгы да дөнья күрер дип көтелә.

Шулай ук «Фәнни Татарстан» журналында да махсус сәхифә булдыруны максатка ярашлы дип санадык. 2018 елның һәр санында Гаяз Исхакыйның тормышын, эшчәнлеген, иҗатын яктырткан фәнни материаллар урын алачак.

УДК 811.512.145:821.512.145

***И.Б. Бәширова***

# ТӨРКИ-ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕ НӘЗАРИЯТЕ: Гаяз Исхакый әсәрләре телен өйрәнү мәсьәләсенә карата

В статье ставится вопрос рассмотрения творчества татарского классика, литературного критика и публициста, известного общественного деятеля Гаяза Исхаки (1878–1954), как одного из звеньев в истории татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, старотатарский язык, языковые споры, стили повествования, творчество Гаяза Исхаки.

Бу мәкаләдә татар халкының бөек талант иясе, классик әдип, драматург, күренекле публицист һәм тәнкыйтьче, танылган сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның (1878–1954) иҗатын татар әдәби теле тарихының бер баскычы буларак карап өйрәнү мәсьәләсе күтәрелә. Ул түбәндәге юнәлешләрне колачлый: 1) Г. Исхакый иҗатына төрки-татар әдәбият гыйлеме нәзарияте үсешенә зур өлеш керткән галим буларак якын килү; 2) әдипнең үз чоры язма әдәби теле тарихына карата булган мөнәсәбәтен объектив-дөрес аңлау һәм аңлату; 3) Г. Исхакыйның хикәя, повесть, роман, драма кебек төрле жанрда иҗат ителгән сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә сүз белән сурәт ясау осталыгын күзаллау; 4) авторның публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләренең тел үзенчәлеген башка стильдәге әсәрләре белән чагыштырып анализлау барышында, аларның охшаш һәм аермалы якларын күрсәтү һ.б.

Төрки дөньяның классик шагыйре һәм әдипләре булып танылачак Г. Тукай (1886–1913), Г Исхакый (1878–1954), Г. Ибраһимов (1887–1938), Ф. Әмирхан (1886–1926) һ.б. мәгълүм шәхесләрнең иҗат эше башланган XIX гасырның ахырына кадәр үк инде төрки-татарның дәверләр, мең еллар буена тупланган язмачылык тарихы – рухи мирасы булуы билгеле. «Языки мира: Тюркские языки» дигән энциклопедик басмада бирелгән мәгълүматтан аңлашылганча, 15 борынгы һәм хәзерге вакытта яши торган 39 төрки телнең 6 сыннан берсе буларак, иске язулы (старописьменные) телгә ия дип санала торган татар халкының язмачылык тарихы дигәндә, угыз-уйгур-кыпчак кабилә телләренә нигезләнеп, V–VII йөзләрдә гомумтөрки руникада башланып, VIII–X гасырларда әлеге нигездә, XI–XIII гасырлардан гарәп графикасында дәвам иткән язма әдәби тел күз алдында тотыла. Әдәби истәлек язылган регионны төгәл күрсәтү нигезендә, аның графикасының нинди булуын, язма тел белән шундагы диалект, сөйләмә тел һәм халык авыз иҗаты әсәрләре үзенчәлекләренең үзара мөнәсәбәтен

билгеләргә, тарихи яссылыктан чыгып, истәлекләрдә чагылыш тапкан әдәби телнең эзлекле традициясен күзалларга мөмкин [Языки мира..., 1997, с. 35–46]. Махсус әдәбиятта аңлатылганча, иске язулы телләр әдәби нормага нигезләнә, норманың традициясе дәвам ителә. Язма норма дигәндә, график билгеләр системасы һәм аларның графо-орфографик тәртибе истә тотыла [Ахманова, 1969, с. 533]. Шуның белән бергә, төрки-татарларның Болгар дәүләтендә (XIII гасыр), Алтын Урдада (XIV гасыр), Казан ханлыгында (XV гасыр), аннан соң Рус (Мәскәү) дәүләтендә яшәп, эзлекле рәвештә иҗат итүләре, ягъни безнең төрле жанр-стильдә язылган, шәрехләнгән, тәрҗемә кылынган бай әдәби мирасыбызның булуы мәгълүм. Алар төрле чорда төрле дәрәҗәдә барланып, тупланып, өйрәнелеп, укытылып килгәннәр.

Татар халкының классик әдипләре иҗат эшенә керешкән XIX гасыр – XX йөз башында классик иске татар теле матур әдәбият, фәнни әдәбият, динидидактика, публицистика, эш кәгазьләре, эпистоляр стильләр белән кулланылышта булып, үзенең алтын чорын кичерә [Татар әдәби теле..., 2015, б. 86–133].

Г. Исхакый матур әдәбият стиленең проза жанрында 600 еллар буена килә торган хикәяләү стиленең үзгәрергә тиешлеген көн тәртибенә күтәрә. Һәм бу аны төрки-татар әдәбият гыйлеме нәзарияте үсешен күрә белүче, аны нигезләүче галим дип санарга мөмкинлек бирә. Автор «Кәләпүшче кыз» хикәясенең (1900, 1902) «Хөрмәтле укучым! Үземнең күңелемнең йимешен сезгә тәкъдим итәм» дип башланган керешендә, «...әдиплек, мөхәррирлек нәдән гыйбарәт идекене» дигән соравына болай җавап бирә: «...һәр язылган сүз үз вакыйгаларын тасвир, үз хәлләрен бәян улмаз! Хосусан, мөхәррирләр, шагыйрьләр ни язсалар, кемне тасвир кылмакчы булсалар, шул кеше булып күп сөйләрләр һәм сөйләтерләр. Бу сүзләрнең бәгъзеләре әшәке улсалар да, мөхәррирнең үзенең фикеренең шулай булуын белгертмәйдер» [Исхакый, 1998, б. 50]. Шул ук фикерен «Бай угылы» (1903) әсәренең керешендә тәфсилләп кабатлап бирә: «Яздыгым романымда бай угылларымызның тәрбияләре нинди идекене, вә бу тәрбияләрнең ни дәрәҗәдә зарарлы идекене укучыларымның күз алдыларына куймак эстәдем. ...Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем» [Исхакый, 1998, б. 113]. Хәзерге әдәбият фәне күзлегеннән караганда, әлеге белдерү табигый, гадәти бер фикер буларак кабул ителә. Әмма татар әдәбияты, әдәби теле тарихы күзлегеннән караганда, Г. Исхакыйның бу фикере белән хәзерге матур әдәбият фәне нәзарият-теориясенә нигез салуы аңлашыла.

Хикмәт шунда ки, XX гасыр башында, Г. Исхакый белдергәнчә, ягъни хәзерге әдәбият белеме таләп иткәнчә, әсәр язучыны чын мөхәррир-әдип дип санар өчен, аның әсәрендә бара

торган вакыйгалар, авторның үз хəллəрен сөйлəгəн кебек турыдан-туры бəян ителеп түгел, бəлки укучы күрə торган, аның күз алдында бара торган рəвештə тасвир ителергə тиеш. Татар прозасының 600 ел дəвамындагы үсеш тарихыннан аңлашылганча, язма истəлекнең эчтəлеген укучыга ирештерү алымының да үзгəреш кичерүе күренə. Төрки-татар матур əдəбият стиле мең еллар дəвамында поэзия һəм проза жанрлары белəн үсештə була. XII–XIII гасырларда, Ə. Ясəвинең «Диване хикмəт»е, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы кебек төрки һəм мөселман дөньясында мəшһүр саналган, киң таралыш алган хезмəтлəрдəн соң, XIV гасырда, «...Алтын Урдада ислам динен дəүлəт идеологиясенə əйлəндерүнең терəге, коралы, символы булсын, ...болгавыр заманнарда халык тормышының əхлак кодексы булсын», дип, «Кыйсасел-əнбия» (1310), «Нəһҗел-фəрадис» (1358) кебек чəчмə əсəрлəр иҗат ителə [Татар əдəбияты..., 2014, б. 266–267, 272). Мəхмүд əл-Болгари, Мөхəммəд пəйгамбəр галəйһи əс-сəламның «...əгəр берəү пəйгамбəрнең 40 хəдисен башкаларга өйрəтсə, ул кеше галимнəр җөмлəсендə санала, үлгəч шəһитлəр хисабында булачак» дигəн хəдисен тормышка ашыру нияте белəн, «Оҗмахларга ачык юл» əсəрен унар фасылга бүленгəн дүрт баб итеп төзи [Нуриева, 1999, с. 30–32]. Һəр фасыл бер хəдис белəн ачыла һəм «бу хəдис мəгънəсе ул булыр кем», дип, төрле кешелəрнең (мəсəлəн, пəйгамбəремез галəйһи əс-сəлам əйтде, ...шəйех Абу Йазидə Бостани əйтде, ... Абдуллаһ бине Мəсгуд разый аллаһу ганһу əйтер, дип) фикерлəре китерелə [Мəхмүд əл-Болгари, 2002, б. 20]. Шулай итеп, чəчмə əсəрнең эчтəлеген аерым кешелəрнең əйткəн сүзлəре белəн хикəялəү алымы гамəлгə куела. Əлеге ысул белəн К. Насыйриның «Кырык вəзир кыйссасы» (1860), «Кырык бакча» (1880), «Фəвакиһел җөлəса фил əдəбият» җыентыгында (1884) кырык рауза дип тупланган хикəятлəре язылa. Əдəби əсəрне XIV гасыр уртасында башланган ысулы белəн язу XIX йөз ахырына кадəр дəвам итə. Əмма максат үзгəрə, хəдислəр тəфсиллəнми, «...тəварих китапларында риваять кылып язалар...» дип, тарих китапларыннан күчə-күчə риваятьлəр булып əверелгəн хəллəр искə төшерелə дə, «хатын əйтте», «вəзир əйтте», яисə «Локман хəким əйтте», «Арсу əйтте» дип тəфсиллəнеп дəвам ителə [Насыйри, 1975, б. 221, 254]. «Əбүгалисина кыйссасы» (1881) кырык өлешкə бүленми, хəдис китерелми, əмма «Равияне əхбар вə накыйляны асар ошбу тарикъ үзрə риваять кыйлыр ки...» шаблоны саклана. Əсəрнең керешендə: «...гарəп фарсы аз белгəн адəмлəрдəн кыйсса вə хикəят укырга ихласы бар кешелəр өчен, халык аңларлык итеп, рус мəмлəкəтендəге мөселман телендə» тəрҗемə ителүе ассызыклана [Насыйри, 1974, б. 208]. Əлеге ысул белəн, билгеле бер үзенчəлеклəр алган хəлдə, Ə. Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Бүз йегет» (1874), «Кыйссаи Таһир илə Зөһрə»

(1879), Г. Фәезхановның «Тутыйнамә китабы» (1887) һ.б. кыйссалар языла. Нәтиҗәдә, укучыга тарихтан мәгълүм булган кыйссаи хакыйкать җиткерелә, татар прозасында I төр хикәяләү ысулы формалаша.

Шуның белән бергә, Муса Акъегетзадәнең (1870–1923) «Хисаметдин менла» дигән, автор үзе билгеләгәнчә, милли романы дөнья күрә (1886). Аның башкача хикәяләү ысулы белән язылуы аңлашыла. Автор, үзе реаль шәхес буларак, сүзен әсәрендә сөйләнәчәк хәлләрнең кайда, кайчан баруын конкрет әйтеп башлый, вакыйганы сөйләүче бердәнбер кеше буларак, сюжет барышын билгели, укучысына эндәшеп, хәрәкәтне тизләтә, аңлатма бирә. Сөйләнә торган вакыйга-хәлләрне җанлы итеп укучыга җиткерү өчен, әсәрдәге персонажлар авторның идеалына туры китерелеп, уңай һәм аларга каршы куелып тасвирлана. Автор әсәренең тулы хокуклы хакиме булып күтәрелә, укучыга җиткерелергә тиеш булган сәнгатьле фикер тарихи гомумилегеннән «котыла», авторның үз сөйләме, үз фикере буларак бирелә. Бу роман белән башланган әлеге яңарыш З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдев, Г. Гафуров-Чыгтай, З. Һади, М. Гафури кебек танылган авторлар иҗатында дәвам ителә. Әлеге нигездә тормышта булган хәлләрне реаль авторның үз сүзе белән сөйләп языла торган II төр хикәяләү ысулы формалаша.

Г. Исхакый менә шушы алымга каршы чыга, ягъни хикәядә турыдан-туры сөйләп бирелә торган хәлләр генә түгел, гомумиләштерелеп күз алдына китерү өчен бирелә торган фикерләр күбрәк әйтелергә тиеш, дип, сәнгатьле чәчмә әсәрне хикәяләүнең яңа теоретик нигезен билгели.

Г. Исхакый иҗаты ватанга кайтканчы, әлеге фикерне башлап Ф. Әмирхан әйткән дип санала иде [Бәширова, 1979, б. 48]. Автор «Танымаганлыктан таныштык» хикәясенең керешендә болай дип белдерә: «Монда очрый торган «мин» кәлимәсен мөхәррирнең үзендән тәгъбир дип уйлау хата булачакдыр. Хикәя язганда бу тәгъбир, гомум тарафыннан кабул ителгән бер тәгъбир булып, мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертер өчен истигъмаль ителәдер» [Әмирхан, 1984, б. 57]. XX гасыр башларында иҗат итә башлаган, алга таба гомум төрки дөньяның классик әдипләре булып танылачак Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камалның беренче хикәяләрендә, билгеле бер хәлне сөйләү дәвам ителгән хәлдә, «мөхәррирнең үз фикерен» киңрәк бирү ысулы да яшәеш ала бара. Ш. Камалның «Уяну» хикәясе, беренче мәртәбә басылганда, эзлекле сөйләп бирелә [Шура, 1909, № 8, 12]. Төзәтелеп басылганда, «Муса ачуланган иде» дип гади генә башлана да, укучы тоя алырдай, көчле эмоциональ тасвир ясала: «...тәне чымырдап китте, чәчләре үрә торды, агач кебек катты... Ишек төбендә ...бер күз! Яшьле күз... туп-туры Мусаның күзенә карый... Гафифәнең күзе...» [Камал, 1914, 1974]. Бу юлларда сөйләү

логикасына туры килә торган җөмлә төзелеше юк, сөйләүче автор юк. Сүзләр белән укучы күрә һәм тетрәнә алырлык образ-сурәт, катлаулы рухи хәл барлыкка китерелә. Аерым, бигрәк тә әсәрнең исем-атамасы итеп куелган сүзләр, әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган өстәмә мәгънә белән катлауландырыла. Ш. Камалның «Буран»ы табигать күренеше һәм персонажның үкенечле кичерешләре, Г. Исхакыйның «Остазбикә»се мулла хатыны һәм буыннар дәвам ителүен кайгыртучы Ана, Ф. Әмирханның «Хәят»е чибәр кызның исеме һәм гүзәллеге бер кемгә дә кирәк булмаган мәгънәсез тормыш буларак аңлашыла. Г. Ибраһимовның да «Яз башы», «Кызыл чәчәкләр»е, «Тирән тамырлар» һ.б. әсәрләре шушы юнәлештә иҗат ителүе мәгълүм. Шул рәвешле татар прозасында чынбарлыкны образлап-гомумиләштереп язуга җайлаштырылган III төр хикәяләү ысулы формалаша. Әмма бу хәлне барлык укучы да бер дәрәҗәдә аңлыймы? Әлеге мәсьәләгә үз вакытында Җ Вәлиди игътибар итеп болай яза: «Гаяз әфәнденең яңа чыккан бер әсәрене укый идек. ...Авыл куштанларыннан булган фатир хуҗамыз боны тыңлап тора икән, мин аның ишене бишне язарга могу, диде. ...Гаяз әфәнденең әсәре ачык татарча язылган, безнең хуҗага да, хуҗа хатынына да тәмамла аңлашыла, фәкать безгә аңлашылган бик күп мәгънә аларга аңлашылмый иде. Бу көндә инсанның фазыйләте (өстенлеге), аның гәүдәсе, кара көче илә үлчәнмәгән кебек, әдәбиятнең да тышкы ягы, ягъни ләфызыга (*сүзгә, мәгънә калыбына, сүзнең авазына*) карап билгеләнмидер» [Вәлиди, 1912, б. 13]. Димәк, әдәби әсәрне рәсем сәнгатен тәфсилләгән кебек махсус аңлату зарурлыгы таләп ителә.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар прозасында сурәтләнә торган хәлләр, укучыга өч төрле ысул-стильдә тәкъдим ителә: а) кыйссаи хакыйкать җиткерү максаты белән тәрҗемә ителеп языла торган К. Насыйри, Г. Фәезханов һ.б.ның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә, чын автор, риваять сөйләүчеләрнең, ягъни «чит кеше» сүзен кабатлап сөйли; ә) реаль тормышта була торган хәл-әхвәлләрне мәгърифәтче әдипләр «үз сүзе» белән сөйләп тасвир итә; б) вакыйга барышында, автор сөйләгәнгә караганда күбрәк фикер бирелеп, эстетик эчтәлек белән сәнгатьчә форманың үзенчәлекле бердәмлегенә нигезләнгән сүз-сурәт – образлап тасвир итү гамәлгә кертелә башлый. Әлеге ысулларның нәзарият-теориясе нәкъ менә Г. Исхакый тарафыннан көн тәртибенә куела, төрки-татар прозасында 600 еллар буена дәвам итеп килә торган сөйләп хикәяләү ысулының яңарырга тиешлеге принцип буларак күтәрелә, ягъни хәзерге әдәбият фәненең нигезе күзаллана. Димәк, әдипнең бу тармакта галим буларак фикер йөртүе күренә һәм үз чоры язма әдәби теле тарихына карата булган мөнәсәбәтен объектив-дөрес аңларга да мөмкинлек ачыла.

XX гасырның беренче биш еллыгында татар телендә газета

бастырырга рөхсәт алынгач, 1905 елның 2 (27) сентябрендә «Нур» газетасының беренче саны басыла. Газетага мәкаләне нинди тел белән язарга кирәк? дигән сорау куела. Әлегә кадәр гамәлдә булган барлык жанр-стильләрдә, аларның таләпләренә туры китереп кулланылган, ягъни киң мөмкинлеккә ия булган язма телне яңа стильнең җәмәгатьчелеккә аңлаешлы формасына җайлашу проблемасы күтәрелә. Моның өчен татар язма теленең әлегә кадәрге кулланылышын өйрәнү ихтыяҗы туа, бу үз чиратында әлеге өлкәдә күп төрле фикерләр кузгалуга сәбәп була. Газетаның нашире һәм мөхәррире, мөселман дөньясына мәгълүм дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Гатаулла Баязитов (1846–1911) «Татарча мөхәррирдән берничә сүз» дигән язмасында: «...Адәм угланнары өчен гәзитә бер мәйдане әфкярдер, бер хуш, мөләем, мәхәббәтле юлдашдыр», – дип басманың фикер мәйданы булырга тиешлеген билгели. Һәм шул мәйданда сөйләнәчәк сүзләренең нур өстенә нур уйнатачак мөхәррирләре – язучылары булуын тели. Һәр язган сүз укучыга барып җитешсен өчен, газетага дигән мәкаләне нинди тел белән, ничек итеп язарга кирәклекне тәгаенләргә кирәк була. Г. Баязитов «Мәкәрҗәдә ике кич» дигән мәкаләсендә «Казан теле»нең бер генә төрле булмавына игътибар итәргә өнди: «...Нә делдә йазармыз?» сөаленә, «Әлбәттә, Казан делендә!» диделәр. Бик яхшы, ләкин ул Казан деле диб сөйләндеке дел бер төрле түгелдер. ... Бәгъзесе госманлы деленә мәйәл идеб, бәгъзесе гарәп вә фарсыны күб катнаштырыб язалар. Димәк ки, бер төсле йиңел, асат аңлаешлы бер куелган дел йукдыр. Инде ни кыйламыз?» [«Нур», 1905, № 4]. Бу сорауга беренче булып, тарихчы-галим, ахун хәзрәтләре, казый, җәмәгать эшлеклесе Хәсәнгата Габәши (1863–1936) болай дип җавап бирә: «Әгәр дә без гавам аңламый, ничек языйк икән диб торсак, ул вакыт асыл язуга ирешү мөшкил булыр түгелме? Әдәби телне аңламасалар, ул вакыт мәдрәсәләрдә гаеп калыр. Гәзитә мәдрәсә түгелгә, тел үгрәтәсене аны мәдрәсәләрдән сорау кирәк булыр. ...Гәзитәдә мәүзүгъ мәсьәләгә, сүзгә карап йазмак кирәк булыр. Бәгъзе гавам өчен булган вакыйгъ әхбәрләрне, хөкүмәт әмерләрене мөмкин кадәр йиңел, асатлатырга кирәк. Әмма гыйльми мәсьәләләр булганда чара юк, әдәби телдә язмак лязем калыр» [«Нур», 1905, № 4]. Язма әдәби телнең вазифасын яхшы аңлап бирелгән бу җавапта беренче мәртәбә әдәби тел дигән төшенчә белдерелә. Әдәби дигәндә, гасырлар буена классик-абруйлы һәм халыкчан-сөйләмә вариантларында кулланыла торган язма телнең гыйльми мәсьәләләр языла торган классик-абруйлы төре истә тотыла, «йиңел-асат» төр исә гавамга каратыла.

Әмма бәхәс барышында, «әдәби тел» һәм «гавам теле» дигән төшенчәләрнең башкачарак мәгънәдә кулланыла алуы да ачыклана. «...Шушы башымны авырттырган мәсьәләдә бән ялгыз калам, берәү дә сүз

чыгармасмы икән, бер дә бунең иң кирәкле, милләтнең алдагы төп хезмәте икәнене белүчеләр дә булмасмы икән дип әвәрә торганда...», мөхәррирне куандырып, «яшь язучылардан мөхтәрәм Гаяз әфәнде Исхаков бу тел хосусында менә ни яза» дип, «Нур» газетасының 8 нче санында әдипнең «Җаваб»ы урнаштырыла. Ул иң әүвәл «...әдәбиятның ничек булуын вә ни кебек язылуын вә халкымызның нәрсәләргә мохтаҗ булуын ап-ачык күрсәтү, язучыларымызга шул иң кирәкле мәсьәлә хакында язу бүгенге көннәрнең беренче дәрәҗә кирәкле эшләреннәндер, – дип, ассызыклаганнан соң, ...тел мәсьәләсе хакында бераз язмакчы булам. Гәзитәнең нинди телдә язылуы, бер әдәби китапның яки рисаләнең нинди шивәдә язылуы, һәрвакыт биреләчәк сөаль булдыгы кебек, халыкның, бигрәк тә укучы халыкның, башын вата торган мәсьәләләр», – дип, түбәндәгечә дәвам итә: «...Мәкаләдә күрелгән кебек “әдәби тел”, “гавам теле” кебек ике ялган аерма ясаучылар, безнең карендәшләремез госманлы төрекләре арасындагы кебек бездә дә күренә башлады». Г. Исхакый мондый бүленешнең үз вакытында төрекләрдә дә, русларда да булуын, аларның әлеге «тарихи хатадан үткән» булуларын искәртә һәм «әдәби тел» дигән төшенчәне үзенчә аңлата: «...“борыч”ны “форыч” дип, “пәрдә”не “фәрдә” дип, “булыр”ны “улыр” дип язу әдәби язу түгел. Әдәби дип мәгънәсен ап-ачык иттереп аңлата торган һәр гыйбарәгә әйтелә. Бер мәкалә әдәби булыр өчен ни хакында язылганлыгы һәр укый белә торган кешегә тәмам аңлашырдай булырга тиеш. Шуның өчен мин “әдәби тел”не үз телемез димен. Үземез сөйли торган телдә язарга тиеш, димен. Һәм язамын. Минем мәсләгемдә язылган китаплар һәрвакыт халык арасында күп таралып, күп укылачак вә халыкка күп файда китерәчәкдер», – дип ассызыклый [«Нур», 1905, № 8]. Шулай итеп, әдипнең язма әдәби тел дигәндә, «үземез сөйли торган гавам теле»н, газетаның да, китап һәм рисаләләрнең дә фәкать шушы тел белән генә язылырга тиешлеген истә тотуы аңлашыла. Мәгълүм булганча, бу вакытта Г. Исхакый «Тәгаллемдә сәгадәт...» (1899), «Кәләпүшче кыз» (1900), «Бай угылы» (1903) дигән хикәяләрен, «Өч хатын белән тормыш» (1900), «Ике гыйшык» (1903) кебек драмаларын язып бастырган була; А.С. Пушкинның «Капитан кызы»н тәрҗемә кыла (1902), тормышының программасы буларак язылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестен бастыра (1904), әдипне мәшһүр итәчәк «Теләнче кызы» романын басмага әзерли (1907). Димәк, язма-китаби татар теле нинди булырга тиешлеге турында «Нур» газетасында бәян ителгән билгеләмәне язма әдәби тел мәсьәләсенә карата да ныклы фикере формалашып җиткән, өметле яшь әдип буларак киң җәмәгатьчелеккә танылып өлгергән шәхеснең тел концепциясе дип кабул итәргә мөмкин булуы аңлашыла. Автор үзе инанган фикеренә тугры кылып, үз төбәгендә кулланыла торган

*келәү, чикле (кадәр), дөбрән, кагау, өргәү, искәү, тиресләнү (киреләнү), койты* кебек сүзләрне, *күз чыгарып, баш ярып булса да* кебек һ.б. халыкчан-сөйләмә тотрыклы тезмәләрне, беренче чәчмә һәм драма әсәрләрендә табигый бер җиңеллек белән файдалана. Язучының беренче ике хикәясендә килеш категориясе кыпчак төрләнешендә генә күрсәтелә. Әмма шул ук әсәрләрдә, авторның үз чоры әдәби теленә хас булган язма китаби традицияләрдән дә баш тарта алмавы аңлашыла. Г. Исхакый әсәрләрендә, төрки-татар әдәби теленә хас булган язма традициянең дәвам итүен 1) гарәп һәм фарсы телләре белән булган мөнәсәбәтенә, 2) гомумтөрки архаик сүз һәм сүзформаларның кулланылышына, 3) аерым төбәк өчен хас булган диалекталь һәм сөйләмә формаларның татар әдәби нормалары белән чиратлашуына бәйләп карарга мөмкин.

Гарәп һәм фарсы телләренә булган мөнәсәбәт телнең барлык тармакларында чагылыш таба. Графо-орфографиядә сузык һәм тартык авазларның язылышы ике әдәби тел нигезендә бара: гарәп-фарсы алынмалары үз чыганак теле кагыйдәсенә буйсындырыла, төрки-татар сүзләре билгеле бер дәрәҗәдә ныгыган иске имляда языла. Морфология өлкәсендә, һәр грамматик категориядә, шул ук ике телгә хас булган үзенчәлекләр иркен кулланыла. Сан категориясендә: *...әшьяләр-әйберләремне хәзерләрмен* һ.б. Лексикада, гарәп теленнән кереп ныгыган сүз һәм сүз тезмәләре актив. Мәсәлән: *...гыйлем фарыз, ...динне мөдәррисләр, голямалар саклыйлар, ...Аллага шөкер, мөселман булганмыз, Алла теләсә, иншаллаһ, вазыйфәле мөгаллим булырмын, ...мәктәптә кавагыйде гарәбидән истифтах укыймын, истикмаль берлә дәрүсе шифаһия укыймын* һ.б. Шуның белән бергә, гарәп вә фарсы теле алынмалары кулланыла: *тавыш – сада, бәхет – сәгадәт – мәсгүд* һ.б., яисә күпчелек очракта татар теле сүзе белән чиратлаштырылып, *кайгылар – хәсрәтләр, гариза – үтенеч, лисан – тел, күңел – калеб, тырышу – иҗтиһадта булу* кебек синонимик рәтләр хасил итә.

Гомумтөрки архаик сүз һәм сүзформаларның кулланылышына нигезләнә торган традиция, асылда, угыз һәм кыпчак төркеме телләре мөнәсәбәтендә барлыкка килә торган вариантларда чагыла. Графо-орфографиядә: *алар – анлар, берлә – берлән – илә – белән, бунда – монда* һ.б. Боларга караганда сирәгрәк булып *бән – мин, улса – булса, ултыра – утыра, урынлаша – урнаша* һ.б. да очрый. Морфология өлкәсендә түбәндәге формалар кулланыла: I зат күплек сандагы тартым кушымчасы: *дөньямызга, ахирәтемезгә файдалы гыйлемнәр*; хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат күплек кушымчасы: *...дөнья, ахирәтләргә ирешермез, ...без дә угылымызны карак булса иде дип сорамасмыз, сиңа бер эшемезне дә салмамыз*; -мак кушымчалы исем фигыльләр: *ахирәт көнендә әбәди мәсгүдиятләр ирешмәктер* һ.б. [Исхакый, 1998, б. 32–33]. Лексикада, югарыда әйтеп үтелгәнчә, үз төбәгендәге сүзләр

эзлекле файдаланыла. Әмма гасырлар буена традиция булып килә торган сүзләрнең хәзерге әдәби нормасына ешрак мөрәҗәгать ителә: *үгрәнү* сүзе *балаңа фарыз булган гыйлемне үгрәтергә келисең* дип бер мәртәбә файдаланыла [Исхакый, 1998, б. 33], *өйрәнү* [Исхакый, 1998, б. 32], *өйрәтергә, өйрәткәннәр* [Исхакый, 1998, б. 41] формасында өч мәртәбә кабатлана;

Язучының әсәрләрендә аерым төбәк өчен хас диалекталь һәм сөйләмә формаларның татар әдәби нормалары белән чиратлашуына караган мисаллар да күзәтелә. Графо-орфографиядә: *йыглый – җыглый – җылый – йылый, җир – йир, җаучы – йаучы, сач – чәч, сачәкләр* [Исхакый, 1998, б. 36) һ.б. Авторның I томына бирелгән «Искәрмәләр»дә әлеге үзенчәлеккә махсус игътибар ителә [Исхакый, 1998, б. 356]. Мишәр диалектына хас булганча, *башка* бәйлеге белән килгән исем юнәлеш килешендә күрсәтелә: *акчага башка, боларга башка* һ.б. Лексикада мишәр сөйләшләренә хас булган *келисең* сүзен автор, асылда, «Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясендә генә эзлекле кулланa. *Келәү* сүзе *эстәү, теләү* сүзләре белән чиратлаштырыла [Исхакый, 1998, б. 36], алга таба *теләү* активлаша һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әдипнең: «...үземез сөйли торган телдә язарга тиеш, димен. Һәм язамын», – дип белдерүе, үз иҗатына карата бик үк туры килмәве, әмма киләчәктә тормышка ашачак фикер булуы аңлашыла. Г. Исхакый, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теленә хас булган барлык мөмкинлектән дә оста файдаланып иҗат ителгән әсәрләре белән, классик әдип, көчле драматург, ялкынлы публицист һәм атаклы җәмәгать эшлеклесе булып таныла [Бәширова, 2000, б. 256–267]. Шул рәвешле төрки-татар прозасында 600 еллар буена дәвам итеп килә торган сөйләп хикәяләү ысулының яңарырга тиешлеге Г. Исхакый тарафыннан принцип буларак күтәрелә, бу, үз чиратында, олуг шәхесне төрки-татар әдәбият гыйлеме нәзарияте үсешенә этәргеч бирүче галим дип санарга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**


*Акъегетзадә М.* Хисамеддин менла. Милли роман йәки хикәя. Казан: Ун-т табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. 1969. 606 с.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда / Ф. Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. I т.: Хикәяләр. 1907–1922. 478 б.

*Баязитов Г.* Татарча мөхәррирдән берничә сүз. Мәкәрҗәдә ике кич // Нур. 1905. № 4.

*Бәширова И.Б.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле. Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 97 б.

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Исхакый иҗаты // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы. Казан, 2000. Б. 256–267.

*Вәлиди Ж.* Татар әдәбияты барышы: беренче җөзьә. Оренбург: Вактъ, 1912. 122 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: унбиш томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 1 т.: Повестьлар һәм хикәяләр. 1899–1908. 399 б.

*Исхакый Г.* Пушкин А.С. Капитан кызы. Казан: литотип. И.Н. Харитонова, 1902. 56 б.

*Камал Ш.* Сайланма әсәрләр: өч томда. Казан: Татар кит. нәшр., 1974. 1 т.: Хикәяләр. Повестьлар. Роман.

*Мәхмүд әл-Болгари.* Нәһҗел-фәрадис / әсәрне басмага әзерләүче (кульязмадагы текстны укып, гарәп грфикасыннан гамәлдәге язуга күчерүче), кереш мәкалә авторы Казан дәүләт университеты доценты Ф. Нуриева. Казан: Татар. кит. нәшр., 384 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 340 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. – 318 б.

*Нуриева Ф.Ш.* «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Булгари. Казань: Фэн, 1999. 208 с.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. 415 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 696 б.

Языки мира: Тюркские языки. Бишкек: Издательский дом «Кыргызстан», 1997. 542 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# «ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ»ГА БҮГЕНГЕ ХӘЛЕБЕЗДӘН КҮЗ ТАШЛАУ

Известный деятель татарского национального движения, писатель и публицист Г. Исхаки в произведении «Ике йөз елдан соң инкыйраз» («Исчезновение через двести лет», 1902) поднимает актуальную и поныне тему исчезновения нации.

**Ключевые слова:** татарская литература, проза начала XX века, повести Г. Исхаки, национальное самосознание, тема исчезновения нации.

Гаяз Исхакыйның атамада әйтелгән мәгълүм повестенда проблемаларның биш юнәлештә куелышы һәм аларга җаваплары хакында күп язалар. Алар, чыннан да, әсәрнең нигезенә салынган, һәм проблемаларны төркем рәвешендә аерып чыгару мәктәп укучысының да көченнән килә, чөнки Гаяз Исхакый милләтнең һәр кешесенә адресланган программ әсәрендә бу ачыклыкның гаять кирәклеген аңлап, әлеге эшне үзе үк башкара.

Соңгы вакытта татарларда ерак тарихы булган тәфсир, ягъни герменивтика яңадан активлашты. Европа илләрендә әдәбиятны схемачыл өйрәнә башлау шартларында укучының игътибарын текстка юнәлтү, аның язучыны, әдәби әсәрне аңлауда мөһимлеген күрсәтү уку-укытуда актуаль бер мәсьәләгә әйләнеп бара. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны да өстән генә уку аңа салынган мәгънә тирәнлеген аңлаудан ерагайта. Дөрес, әсәрне шәрехләгән, фикерләрен туплаган хезмәтләр инде бихисап. Бик сайлары бар, тирәннәре дә юк түгел. Хәзер сезнең игътибарга тәкъдим ителгән бу мәкалә Гаяз Исхакый исеме күпләргә билгеле булганчы ук язылган иде. Ул әле беркайда да басылмады, фикерләре дә искермәгән. Әдипнең юбилей көннәрендә әсәрдәге милләт яшәешендә бүгенге көндә үтә мөһим саналган кайбер проблемаларга тукталу урынлы булыр.

Сүзне Гаяз Исхакыйның голяма сыйныфына мөнәсәбәтеннән башлыйк. Әдип аны милләт яшәешендә төп рольне уйный дип санаганга аерып куя һәм гомумиләштерелгән образын аеруча калкыта, иң мыскыллы, иң көчле көлү рәвешендәге җөмләләрен аңа юнәлтә. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә галимнәр катламы үтә консерватив төркем буларак бәяләнә. Әлеге төркемгә дәрес бирүче мөдәррисләр дә, руханилар да, китап язучылар да керә дип белик. Консервативлык заман мөгаллимнәренә дә хас түгелмени? Алар арасында милләт һәм тел яшәеше өчен көрәшүчеләр күпме генә?!

Ни өчен төрле дәрәҗәдәге, төрле хәлдәге, төрлечә көн итүче бу катлам зур тәнкыйтькә очрый? Араларында аек карашлы

кешеләр барлыгын Г. Исхакый таный бит юкса, тасвирлый да… Таный, тик ул аларның, матди хәлләре начарлыктан, байларга хезмәт итәргә, гаделсезлеккә хезмәт итәргә мәҗбүрлеген дә белә. Җитмәсә, унтугызынчы-егерменче гасыр чигендә искелек яклы татар галәме артык иҗтимагый активлык, аңлылык күрсәткәннәргә каршы бердәм күтәрелә. Алдынгы карашлы шәхесләребез булуга карамастан, гомумән алганда да, голямалар катламыбызның, башка милләтләрнеке белән чагыштырганда, белем дәрәҗәсе бик чикле, һәм үзләре тарафыннан шуны аңлау күзәтелми. Белемне арттырып, яңача эшләү көч таләп итә. Рәхәт, җиңелрәк, уйламыйча, стратегик максатларсыз гына яшәү милләтнең бөтен табигатенә салынган, һәм аның бер социаль төркеме генә башкача була алмый. Бу сыйфатны хәтта тулы бер гасыр да җиңә алмады шикелле.

Гаяз Исхакый әйткән фикерен мисаллар, тормыш күренешләреннән тасвирлар белән дәлилләп бара. Кайвакыт ташып тормаган яисә актык акчаларын тотып, соңыннан ачлыктан үлгән байлар туен күз алдыбызга китерик: өч катлы йортның һәр почмагында кунаклар. Шуның бер бүлмәсенә генә җыелган хәзрәтләр төркеме генә дә ике өстәл тәшкил итә. Кирәге чыгар дип уйланылган һәр кеше «туй»га чакырыла, һәммәсенә бүләкләр таратыла, төп сәдакалар руханиларга бирелә, алар моны тиеш кебек кабул итә, чөнки, беренче чиратта, байлыкка-байларга хезмәт кыла. Мондый юмартлыклар һәрвакытта да киләчәккә яхшы исем калдыру өчен башкарыла, әмма хуҗалар татарда, мөселман халыкларында ашаганда шул ризыкны бирүчене мактау, гомумән, үзенә якты чырай күрсәткәнгә ялагайлануның бер гадәт икәнлеген генә аңлап бетерми.

Галим-голяма тәнкыйтьне, өйрәткәнне бер дә яратмый, үзен башкалардан нык аерып куя. Эгоистик сыйфатлар бигрәк тә руханиларда соң дәрәҗәдә көчле. Мәсәлән, авыл мөдәррисләре, хәлфәләр, һәр фәннәрдән махсус белгечләр кайтып, үзләренең дәрәҗәсе китүеннән курка. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»дан да аңлашылганча, җәдидчә белем бирү мәктәпләргә, мәдрәсәләргә ныклап керсә, иске карашлы мөдәррис-хәлфәләрнең балалары наданрак икәнлек ачылачак. Г. Исхакый персонажлары да, бөтен кеше укый-яза белсә, аннан хат яздырмаслар, сәдака аз килер, дип уйлый. Ә бит тәрәккыят руханилар катламына сеңгән нигезсез һавалыкны да юкка чыгарачак. Алар тарафыннан томана калдырылган кара халык әлегә, алгарышның, беренче чиратта, үзенә файда итәсен аңламаганга, моңа кадәр пот дәрәҗәсенә күтәргән хәзрәтләр артыннан бара.

Г. Исхакый фикеренчә, татарда коллык психологизмын көчәйтүдә диннең роле аз түгел. Ишан дәрәҗәсенә күтәрелеп, тулы бер милләтне колың ясарга мөмкин. Әсәрдә язучы милләтебезнең, тирәннән уйламастан һәм аңышмастан, дин-сәясәт өлкәсендәге төрле идеологияләргә, агымнарга, күренешләргә бирешүчәнлеге турында яза, рухани «пот»ларга, «патша»ларга табынучан мен-

талитеты хакында сөйли. Менә без – ни өчен совет чорында коммунистлар пропагандасына сүзсез буйсынганбыз, менә без ни өчен хәзер дә, нинди генә эшләргә тотынсак та, иң башта куркулы, шигәюле күз белән тирә-ягыбызга карыйбыз. Язучы, кайта-кайта, татарларда сәяси наданлык һәм сукырлык турында сөйли, бүгенге кешенең башына сыймаслык мисаллар китерә. Дөньяви проблемаларны чишкәндә, авыл кешесе тормышын кайгырту максатыннан корылмаган Думага өмет баглау кебек беркатлыгыбыздан көлә. Болар бит барысы да бик заманча яңгыраган фикерләр.

Гаяз Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестенда мөһаҗирлек проблемасын да күтәрә. Еш кына, татарларда мөһаҗирлек әдәбияты юк дәрәҗәсендә, дигәнне ишетергә туры килә. Хезмәттә аның кайбер сәбәпләре күрсәтелә. Анда ике гасыр чигендә Төркиягә барып җитеп яисә барып та җитмичә, тулаем диярлек, үлеп беткән мөһаҗирләр хакында языла. Аларның зур күпчелеге – нәкъ менә урта хәллеләр, укымышлылар, эшмәкәрләр. Бу ахмак кузгалышларның сәбәбе ни? Яңалыкка каршы тору, киләчәкне күрә белмәү, гадәттәгечә, голяма катламның ялган сүзләренә ышану. М. Галәү кебек талантлы язучының «Мөһаҗирләр» романын язуга этәргечне менә кайдан да эзләргә кирәк!

Соңгырак чор әдәбиятыбыздан Миргазыян Юнысның «Безнең өй өянке астында иде»дә без мөһаҗирлек хәрәкәтенең ачы чишелешләре белән очрашабыз түгелме?! Г. Исхакый безгә бүгенге әдәби тикшеренүләребезгә, шул исәптән күчемлелек, әдәби-мәдәни бәйләнешләр һәм башкалар хакындагы хезмәтләргә юллар күрсәтә. Күпме булганбыз без, күпмебез һәм кай туфракта башын салган, исәннәрнең бүгенгесе нинди? Милли әдип татар тарихчыларына да җитди фәнни темаларны җитәрлек биреп калдыра.

Гаяз Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да русча укуны яклаган, димәк, руслаштыру файдасына су койган, диючеләр бар. Әсәрне җентекләп укучы бу сүзне сөйләми. Рус мәктәпләренә баруның аянычлы яклырын Гаяз Исхакый үзе үк яза. Шуларда белем алган, башка халыкларның алдынгы шәхесләре белән очрашкан морза балалары хакында сөйли ул. Аларның кайберләреннән танылган кешеләр дә чыккан, әмма берсенең генә дә татар милләтенә хезмәт иткәне юк, күбесе хәтта татарлыгын танырга да теләми. «Бу гасырда болардан зарардан башка һичбер файда булмады», – ди әдип.

Чит өлкәләрдә дворян катламыннан булмаганнарның да, рус мәктәпләрен тәмамлап, ни милләтенә, ни үзенә бер-бер яхшылык эшли алмаганлыгы хакында сөйли Г. Исхакый. Рус мәктәбендә белем алуның заман модасы гына булуына борчыла. Гаять актуаль яңгырашлы сүзләр. Дөрес, ул татарларга бу мәктәпләрдә уку һөнәр алу өчен кирәк дип саный, чөнки әлегә татарның андый уку йортлары юк. Бу проблема хәзер дә чишелмәгән ләбаса. Шулай булгач, рус мәктәпләрендә уку милләтнең юкка чыгуына китерәчәк. Икенче яктан,

Исхакыйның шул заманда рус мәктәпләрендә уку кирәклеген язуы татарның, башка халыкларга кара эш көче буларак хезмәт итмичә, үз көнен үзе күрә алуын кайгыртуына кайтып кала. Һәм ул бу эшләрне вакытлыча гамәлләр дип аңлый, чөнки милләтнең алга таба мөстәкыйльлек аласына ышана.

Гаяз Исхакый, туктаусыз рәвештә рус мәктәпләрендә уку кирәклеген кабатлавы белән, татар мәдрәсәләренең аларга альтернатива түгеллеген аңлатырга, булган уку йортларыбызны тамырдан үзгәртеп корырга кирәклекне ирештерергә тели. Белем бирү проблемасын бу юл белән чишүне дә әдип вакытлы – үз мәгарифебезгә реформа ясалганчы булырга тиеш күренеш кенә дип карый. Чит милләт белән артык якынаюның милли әхлакка зыян салуы, татарларның башкалардан бары тик начар нәрсәләргә генә өйрәнүләре хакында бу әсәрендә турыдан-туры әйтеп калдыра.

Бүгенге көндә яшүсмерләр, гаилә эченә үтеп кергән фәхешлек проблемасын еш күтәрәбез. Гаяз Исхакый моның Казанда шул заманда ук чәчәк атуын, исереклекнең күзгә күренеп җәелүен яза. Сүз сәнгате, аның эчтәлеге һәм формасы, аңа тәнкыйть, әсәрләрнең милли теле, традицияләргә нигезләнүе яисә әдәби телне реформалаштыру, китап басу, вакытлы матбугат эшенең торышы, аның җитәкчелеге, эчтәлеге, юнәлеше мәсьәләләре «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да аерым төркемчә булып бара.

Әдәбият һәм сәнгатьне янәшә кую белән беррәттән, Г. Исхакый алар хакында аерым да фикер йөртә, бик кызык чагыштырулар китерә. Милләтнең атасы белән анасы – әдәбият һәм музыка, дип әйтә. Аларның миллилеген саклауны милләтне саклау юлы дип саный. Сәнгатьнең әхлак бозу чарасы буларак кулланылу фактларын атый, шуның киң җәелүеннән курка. Аңа табигый яңгырашны кайтару, милли көйне фәхеш йортларыннан чыгару кебек бүгенгебез өчен гаять тә актуаль проблемалар күтәрә.

Рәссамлык, театр сәнгатен ничек үстерү, табиблык һәм башка һөнәрләрне үзләштерү, фәкыйрьлекне бетерү, түбән катламнар файдасына җәмгыяте хәйрияләр төзү һ.б. – болар барысы да ил, халык, милләт, аның бер кешесенә кагылышлы җитди проблемалар. Гаяз Исхакыйның күз угыннан берсе генә дә төшеп калмый. Безнең әдәбиятта бүгенгәчә нинди проблема күтәрелсә, Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ында ул инде бар. Бу әсәрне хәтта бүгенге сәнгать төрләренең чишмә башы санарга кирәк.

Г. Исхакый татарга алдагы ике йөз елда ничек яшәячәген тасвирласа да, үзе күрмәгән вакыйгаларны язса да, әйткәннәре ни өчен ышандыру көченә ия соң, дигән сорау туа. Җавабы шулдыр: ул татарның моңа кадәр һәм шул көндә барган хәлләрен эзлеклелектә тудыра, бер нәтиҗәгә килерлек итә һәм кайвакыт тарихи фактлар белән дәлилли, шул заман кешесенә билгеле тарихи шәхесләрне телгә ала.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестеның структурасы

бик кызыклы. Ул махсус рәвештә аерым-аерым кисәкләргә бүленмәсә дә, авторның гомуми пландагы фикер сөрешен, күтәргән проблемаларын һәм аннан чыгу юлларын күрсәткән керештән, аны шул чорда татар милләтенең яшәешендә күзәтелгән фактлар, тормышкөнкүреш вакыйгалары белән раслаудан, инде киңрәк аңлатулардан торган беренче кисәктән, аерым бер кешене үзәккә куйган әдәби сюжетны эченә алган өлештән оеша дип карарга кирәк. Болардан тыш, бераз читтә торган һәм оптимистик ноталары зуррак булган Соң сүз (хатимә) дә бар.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең кайсы кисәге мөһимрәк – әйтүе кыен. Бу өлешләрнең берсеннән-берсенә табигый ялганып китүенә стиль, шуны чагылдырган сыйфатларның беренчесе булган темпоритм, хис-фикер уртаклыгы ярдәмендә һәм фәлсәфәне эзлекле үстереп, сәбәп-нәтиҗәне үзара тыгыз бәйләп ирешелә.

Гаяз Исхакый, бер караганда, унтугызынчы гасырдан егерме беренче гасырга юлын өзми генә атлый, шул ук вакытта егерменче гасырның соңгы елларына ул ныклап тукталып тормый. Бу аралыкны тасвирлау бары тик егерме беренче гасырга эзлекле күчү өчен генә кирәк.

Әдип егерме беренче гасырны да ни өчен гомуми планда гына сурәтләми? Бердән, гади халыкта фәнни-публицистик китаплар уку традициясе көчле түгел. Икенчедән, җанлы тормыш картиналары аша кеше күңеленә үтү, алда әйткәннәргә ышандыру җиңелрәк. Өченчедән, милләтнең язмышын фәнни һәм тарихи яктан төп-төгәл фактлар белән фараз итү авыр. Бу очракта атаклы күрәзәче Нострадамусның катреннарын искә төшерү дә урынлы булыр. Фикер иясенә гомуми китешне күрсәтү мөһимрәк, ә ул китешнең ахыры фаҗигале. Дүртенчедән, язучы, болай эшләп, моның әле әдәби хыял гына булып калу мөмкинлеген дә күрсәтә, кешегә өмет чаткысы да сала. Ул бу хакта әсәр башында махсус рәвештә язып та куя.

Бүгенге көн Гаяз Исхакыйның егерменче гасыр буена бирелгән фаразларының тулысынча акланганлыгын исбатлады. Милләт соңга калып булса да уяныргa, үз яшәешен үз кулына алырга тиеш кебек. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең татар баласын тәрбияләүдә генә түгел, татарлыгын онытa барган өлкәннәрнең дөньяга күзен ачуда да роле искиткеч зур.

***Харрасова Рифә Фәтхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***З.Г. Мөхәммәтшин***

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ӘЛИФБА АЛМАШТЫРУГА МӨНӘСӘБӘТЕ

Статья посвящена анализу деятельности выдающегося классика татарской литературы, драматурга, крупнейшего национального политического деятеля и известного представителя татарской общественной мысли Г. Исхаки. Автор статьи ставит своей целью более детально проанализировать несколько работ драматурга, посвященных становлению русского алфавита (письменности) среди тюркоязычного населения России. В статье наиболее ярко расскрывается личность Г. Исхаки как социально-политического и общественного деятеля своего времени. Немаловажным фактом является и то, что Исхаки в своей работе приводит отрывки из выступления некоторых участников первого Всесоюзного тюркологического съезда, которые являлись сторонниками сохранения идентичности и самосознания татарского народа.

**Ключевые слова**. Г. Исхаки, Г. Шараф, латинизация, первый Всесоюзный тюркологический съезд.

Гаяз Исхакый XX гасыр башы иҗтимагый хәрәкәтендә әһәмиятле роль уйнаган, татар публицистикасын, милли традицияләргә бай татар әдәбиятын югары баскычка күтәргән шәхесләрнең берсе. 1917 елгы Октябрь түнтәрешеннән соң гомерен мөһаҗирлеккә бәйләгән әдип, публицист һәм милли сәясәтнең нигезен салучыларның берсе буларак, аның каләме, публицистик иҗаты, күпчелек очракта 20–30 нчы елларда СССРда алып барылган милли сәясәтнең асылын ачып салган тәнкыйди мәкаләләре төрек-татар халкының киләчәк язмышын кайгыртуга хезмәт итә.

Мәгълүм ки, Г. Исхакыйның тырышлыгы һәм аның мөхәррирлегендә мөһаҗирлектә беренче татар матбугат органы булган «Милли юл» (соңрак «Яңа милли юл») журналы 1928–1939 елларда Германиядә нәшер ителә. 1935 елның октябрь аеннан 1945 елның августына кадәр Ерак Шәрыкның Мукден шәһәрендә милли идеяләрне тараткан «Милли байрак» газетасы чыга. Бу журнал һәм газета үзенең төп мәсләген чит халыклар арасында татар халкының милләт буларак сакланышын, телен югалтмауны, балаларда милли хис тәрбияләүне максат итеп куя, шул юлыннан тайпылмыйча, дөнья сәясәтендә кискен үзгәрешләр башланганчы дәвам итә.

Мөһаҗирлектәге вакытлы татар матбугатының икенче төп юнәлеше большевиклар фиркасе идарәсендәге СССРның эчке һәм тышкы сәясәтен, дөньяны бүлүгә корылган ике капма-каршы идеологиянең нигезен ачып бирүне дә читтә калдырмый. Әмма алар арасында иң мөһим проблемаларның берсе – төрек-татар халкының киләчәген корытырга юнәлтелгән большевиклар

идарәлегендәге дәүләтнең милләтләргә каршы эшләнгән пычрак сәясәтләрен тәнкыйтьләүгә юнәлтелә. Бу язмада Г. Исхакыйның СССРда большевиклар хөкүмәтенең төрек-татар халкының гасырлар буенча камилләшкән әлифбасын юк итү сәясәтенә үз мөнәсәбәтен белдергән «Советларда төрек халыклары өчен рус әлифбасы» исемле мәкаләсенә аерым тукталу урынлы булыр. Мәкалә «Яңа милли юл» журналының 1938 елгы 10 нчы санында басылган. Әлеге язма бүгенге Россия сәясмәннәренең рус булмаган халыкларын юк итүгә корылган эчке һәм бик тә нечкә сәясәтләренә җавап бирерлек. Шуларны истә тотып, Г. Исхакыйның төрек-татар халкында әлифба алыштыруга бәйле кайбер фикерләрен укучыга җиткерүне кирәкле санадым.

Төрки дөньяда әлифбага бәйле беренче бәхәсләр XIX гасырның икенче яртысында азәрбайҗан милләтенең күренекле мәгърифәтчесе М. Ахундовның аерым фикерләренә бәйле карала. XX гасырның 10 нчы елларында бу мәсьәлә кабат күтәрелә. Татарның күренекле шагыйре Сәгыйть Рәмиев «Идел» газетасында гарәп әлифбасын латинга күчерүне күтәреп чыга. Татар матбугатында әлеге язма үз вакытында шактый бәхәсләр дә тудыра. Казахның танылган мәгърифәтчесе И. Алтынсарин да казахларга рус әлифбасы кертүне күтәреп чыга, хәтта рус әлифбасына нигезләнгән дәреслек тә бастыра. Әлифба мәсьәләсе 1917 елгы Октябрь түнтәрешеннән соң большевикларның яшертен сәясәтләренә әйләнә. Г. Исхакый үзенең язмасында аның асылына, киләчәгенә игътибарны юнәлтә.

Мәкаләдән күренгәнчә, автор «әлифба» сәясәтенең тарихын, аның бөтен нечкәлекләрен укучыга ачып бирүгә ирешкән. Ул, иң беренче чиратта, большевик сәясәтчеләрнең «Яңалиф», ягъни латин әлифбасына күчерүнең мәкерле гамәлләрен, инде 30 нчы еллар ахырында кириллицага күчүнең ничек тормышка ашырылуын кискен тәнкыйтьли. Язмада татар зыялыларының латин әлифбасын кертүгә каршы булулары һәм аларның репрессияләр корбанына әйләнүләре дә шактый ачык яктыртылган.

Мәгълүм булганча, төрек-татарны латинга күчерү проблемасы, югарыда искә алганча, кабат большевиклар идарәлегендәге Азәрбайҗан Республикасында күтәрелә. Гали Рәхим бу хакта: «1925 елда Бакуда җыелган Азәрбайҗанның өлкәне өйрәнү съезды тюркология корылтае җыюның кирәклеге турында карар чыгарып, аны чакыруны башлап җибәрү өчен аерым бер комиссия тәшкил итте. 1925 елның 6 августында шул комиссиянең беренче утырышы булды», – дип яза [Исхакый, т. 12, б. 441]. Бакудагы латин әлифбасы буенча җыелган корылтай исә 1926 елның 26 февраль – 6 март көннәрендә эшли. Беренче Бөтенсоюз Тюркология корылтае латин әлифбасына күчүнең төп илһамчысы Агамгали оглы (Самед ага) (1867–1930) рәислегендә уза. Корылтай җиңел генә бармый. Бигрәк тә татар делегатларының күпчелеге латинга күчүнең уңай

һәм тискәре якларын дәлилләп, төрек-татар халыкларын таркатуда төп максат булуын ышандырырга тели. Алар арасында күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Шәрәфнең чыгышы игътибарга лаек. Беренче Бөтенсоюз Тюркология корылтаеның стенография хисабында Г. Шәрәфнең «Арабская и латинская система шрифтов и вопрос о применении их для тюрко-татарских народностей» исемле чыгышы бүген дә актуальлеген югалтмаган. Ул үзенең чыгышында латин әлифбасына тартылу XIX гасырның икенче яртысында башлануына тукталып, бу хәрәкәтнең артык тамыр җибәрә алмавын искәрткәннән соң, «...вопрос о принятии латинского шрифта является вопросом не выбора шрифта, а вопросом о замене существующих у них шрифтов; это обстоятельство я подчёркиваю, так как вопрос о замене шрифта в культурно-экономическом и общественном отношении имеет громадное значение, в особенности, для народностей, имеющих значительные культурные достижения в прошлом и настоящем, как турки Турции, казанские татары, азербайджанцы, узбеки, казак-киргизы и др. Замена шрифта в этих случаях связана: с переучиванием новой грамоте всех грамотных по прежней письменности, с необходимостью на ряд лет ведения параллельного издательство, обучение грамоте, создание навыков чтения и письма одновременно по двум письменностям...» – дип яза [Исхакый, т. 12, б. 443]. Беренче Бөтенсоюз корылтае «яңалиф»кә карата нинди дә булса карар кабул итә алмый. Г. Исхакый мәкаләсендә «18 декабрь 1928 елда, Азәрбайҗан Совет җөмһүриятенең рәисе Агамгали оглының башлыгы астында төрле-төрле кабиләләрнең латинчы түрәләреннән егерме биш кеше Казанга килде», – дип яза. Милли телнең киләчәген кайгырткан, латин әлифбасына тискәре һәм кискен каршы торган Татарстан башкаласында Өченче Бөтенсоюз Тюркология корылтаеның уздырылуы гаҗәп түгел. Ул большевиклар фиркасенең махсус карары белән башкарыла. Г. Исхакый корылтайда чыгыш ясаган кайбер делегатларның фикерләрен иҗади тәрҗемәдә төгәл бирергә тырышкан. Әлеге язмада аларның оригиналь текстын урнаштыру кулайрак булыр дигән уй белән өзекләрне рус телендә тәкъдим итәм. Өзекләрдә чагылыш тапкан фикерләр большевиклар фиркасенең патша Россиясе алып барган милли сәясәтеннән ерак тормавын да ачык сиземләргә ярдәм итә. Агамгали оглының чыгышы шактый гыйбрәтле, ул СССРның милли сәясәтенең эчке мәгънәсен ачып бирә һәм болай ди: «…недаром назначили открытие 3-го Пленума ВЦК НТА именно в Казани. Как раз в этом самом городе Татарстана новый алфавит встретил наиболее сильное идеологическое и практическое сопротивление. Конечно, это вполне объяснимо. Объяснимо прошлым состоянием Татарстана. Грамотность в этой республике наиболее высока, в сравнении с другими тюрко-татарскими на-

родностями и в довоенное время доходила, кажется, до 40%. Наконец, развивающаяся национальная литература, национальное самосознание именно в Казани более чувствительно были связаны с николаевским режимом. Эти два момента и определили настроение Казани. Татреспублика наиболее сильно пострадала от русского самодержавия» [Исхакый, т. 12, б. 445]. Агамгали оглы татар халкын башка төрки халыкларга караганда өстенрәк саный һәм Казанның СССРда яшәгән төрек-татарлар өчен сикереш мәйданы булуын да искәртә. Шунысы ачык: XX гасырның 20–30 нчы елларында әлифба алыштыру, бер яктан, сәяси уен булса, икенче яктан, Казанны буйсындыру төрек-татарны сәясәт корбанына әйләндерүдә мөмкинлек ачылу дигәнне дә аңлата. Агамгали оглының икенче өзегенә дә игътибар итү әһәмиятле кебек. Ул бу өзектә Казанны яулап алу төрек-татар дөньясы өчен аеруча мөһим роль уйнавын ачык дәлилли. «Яңалиф» рәисе үзенең чыгышында Казанны «яулап» алуның максатын түбәндәгечә аңлата: «Казань нам нужно взять, – это замечательный Порт-Артур не только для северных тюрко-татарских народов, но и для южных. В прежнее время влияние Казани шло дальше – до Азербайджана и докатывались до Персии и Турции. Поэтому мы должны здесь в Казани подхлестнуть наших товарищей. Это не грех а, наоборот, это хорошо, это нам нужно, восстановить новую Казань, использовать все накопленные силы, старую мощь перекинуть к новому делу, заставить служить нашему делу». Агамгали оглы үзенең чыгышында СССР-дагы милли сәясәтнең кырыс якларын күрсәтергә теләмәсә дә, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Михаил Осипович Разумовның чыгышында милли сәясәттә диктаторлык алымнары чагылыш табуы күзгә ташлана: «Мы настаиваем на том, что независимо от того, как настроен был по отношению к Яналифу тот или другой представитель беспартийной интеллигенции, он должен исходить от того, что этот вопрос является уже решённым и теперь в интересах тюрко-татарских народов является скорейшее окончание начатой работы. [...] Яналиф – одна из важнейших наших задач в тюрко-татарских советских республиках; поэтому кто не с нами в этой серьезной культурно-политической работе, тот против нас вообще», – дип белдерә [Исхакый, т. 12, б. 445]. Өзектән күренгәнчә, әлифба сәясәте күп кенә татар зыялыларын репрессияләүгә юл ачуга сәбәп тә була. Моңа мисал итеп тарихка кереп калган «82 хаты» мәгълүм. Нинди генә каршылыклар булуга карамастан, 1929 елдан латин әлифбасы фирка карары нигезендә мәҗбүри кабул ителә. Ләкин, Г. Исхакый мәкаләсендә бирелгән мисаллардан күренгәнчә, әлифбаның кабул ителгән беренче елларында күпчелек газета-журналларда укучылар үзләренең зарларын хат рәвешендә матбугатта

бастырып, ризасызлыкларын белдерә килгәннәр.

Г. Исхакыйның милли теманы яктырткан күпчелек мәкаләләре раслаганча, XX гасырның 30 нчы еллары ахырында милләтләргә тигез хокуклар бирергә вәгъдә иткән СССР инде патша Россиясенең милли сәясәтенә тулысы белән күчеп бетә. Шуның бер мисалы – 1929 елда төрек-татар халкына көчләп тагылган латин әлифбасын 1939 елда кириллицага алыштыру сәясәте. Югарыда искә алынганча, бу күчеш тавышсыз-тынсыз гына башкарыла. Әдип һәм публицист әлеге вакыйганы түбәндәгечә тасвирлый: «Бусында большевик хөкүмәте андый сатлык хәрәкәтне кирәкле күрми, үзенең бозгынчылыгын, мәдәниятебезне җимерү эшен, нечкә булса да, бер пәрдә берлә дә өртүне кирәкле тапмый, ул ачыктан-ачык Мәскәүдән “Әлифба русча булсын” диеп әмер бирә. Мәскәүдә безнең халык арасында элекке христианлык таратучы миссионерлардан “белгечләр һәйәте” төзеп, русча әлифбалар ясарга кушадыр. Декрет тарызында *(рәвешендә)* Кырымда 1938 елның уку елыннан русча әлифба берлә укыта башларга әмер бирәдер. Бу әлифбаны алуның кирәклеге хакында әсбабе мәүҗүбәсен *(барлык сәбәпләрен)* күрсәткәндә дә, большевик хөкүмәте инсани, мәдәни сылтауларны эзләп тормый, ул тугрыдан-тугры: “Латин әлифбасы хезмәт ияләренә русчаны өйрәнергә комачаулык ясый, аның хәрефләренең аерым төстә язылуы эшче, колхозчы балаларына русчаны өйрәнергә уңайсызлык итә”», – дип яза. Соңгы өзекне Г. Исхакый «Кызыл Татарстан»ның 22 июнь саныннан (1938 ел) алынуын искәртә. Шул рәвешле, төрек-татар милләте большевик фиркасенең куркытуга корылган милли сәясәте корбанына әйләнүе дә ачык сизелә. Хәер, моңа сәбәп тә бар: 1937–1938 еллар – СССРда сәяси репрессиянең «чәчәк аткан» еллары, татар зыялыларының төрмә һәм сөргенгә җибәрелгән яисә үлем җәзасына хөкем ителгән еллары.

Г. Исхакый үзенең язмасында төрек-татар халкының милли көрәш тарихын искә төшерергә дә онытмый һәм большевиклар фиркасе идарәсендәге Совет хөкүмәтенең патша Россиясе алып барган милли сәясәтенә караганда күпкә куркынычрак булуына басым ясый. Мәкаләдә шактый өзекләр китерелүгә карамастан, большевикларның гайре рус халыкларын юк итүгә нигезләнгән идеясен түбәндәге өзектән дә чамаларга мөмкин. Г. Исхакый: «...төрек халыкларында Русиядән аерылып, аерым мөстәкыйль милли дәүләт ясау агымы киң халык катлавына кадәр җәелгән көчле бер фикер агымы булып җитүе бик ачык күренеп калды. Совет хөкүмәте, шуның төбен-тамырын кисәр өчен, төрек халкының милли минлеген, үзлеген бетерү тәдбирен *(чарасын)* алырга кереште, архивларын актарды, Ильминский, Победоносцев, Столыпинның руслаштыру юлын “иң катгый юл” диеп уйлап, Победоносцев, Столыпинның гамәлгә ашыра алмаган русча

әлифбасын өстерәп чыгарып, гайре рус мәктәпләргә яңа русча уку программы ясап, татбикъка *(яраклаштырырга)* кереште. Шуны да кушарга кирәк: бүгенге русча әлифба алдыру декретлары – Советларның большевизм принциплары берлә һичбер галякасы *(бәйләнеше)* булмаган, аларның фәкать рус ассимиляторларыннан, руслаштыручыларыннан килеп чыккан рус шовинизмасының гына җимешедер», – дип яза һәм большевикларның милли сәясәттәге төп принципларын күз алдына китереп бастыра. Әдипнең большевик фиркасенең милли һәм, шул исәптән, әлифба сәясәтенә мөнәсәбәте болар белән генә чикләнми әлбәттә. Ул язмасын һәркемгә ачык итеп, түбәндәгечә тәмамлый: «Ләкин шул кадәр гауга, тавыш берлә җәбрән *(көчләп)* кабул иттергән латин әлифбасының сигезенче яшендә үк кирәкмәгән булып ташланып, русчага җәбрән күчерелергә тырышылуы большевикларның бу эшләренә, электрлаштыру кеби, бер уен төсле бирәчәктер вә халкыбыз да үзенең иске әлифбасына багланышын ныгытачактыр. Большевик хөкүмәтенең бу ачыкча үзлегебезне, барлыгыбызны, берлегебезне бетерү хәрәкәтенең илләребездәге гаксел гамәле тагы ни төсләр алачак, киләчәк күрсәтер». Әмма әдип һәм публицистның өмет-хыяллары бүген дә акланмады, ул хәтта, Г. Исхакый искә алганча, Победоносцев, Столыпин, Сталин тарафыннан башкарылган сәяси уеннарга караганда да куркынычрак төс алды, тел мәсьәләсе үлем белән яшәү арасында калды.

Г. Исхакый әлифба сәясәтендәге кайбер детальләрне, сәяси мәнфәгатьләрне белеп бетермәгән күрәсең. Хәзер шулар хакында да искә төшерү комачауламастыр, мөгаен. Совет хөкүмәте XX гасырның 20 нче еллар башында рус әлифбасын да латинга күчерү тәкъдиме белән чыга. Бу мәсьәләне большевиклар Россиясенең беренче мәгариф комиссары А. Луначарский «Красная Татария» газетасының 1930 елгы 9 гыйнвар санында басылган «Латинизация русской письменности» мәкаләсендә күтәрә. Ләкин В. Ленин үз вакытында рус әлифбасын латинга алмаштыруны кичектереп торуны хуплый. Шуңа карамастан, әлеге мәкаләдә яңгыраган фикернең дә үз вакытында бер уен гына булуы сиземләнә һәм тел, әлифба реформаларының нигезендә һәрвакыт сәяси мотив ятуы аңлашыла. Бу фикер Зәки Вәлидинең «Хатирәләр» китабында, казах милли хәрәкәтенең күренекле шәхесләренең берсе Мостафа Чокайга язган хатында ачык чагылыш таба. Сәяси мотивның ролен күрсәтү йөзеннән һәм мәгълүматның кыйммәте югары булуын истә тотып, өзекне мөмкин кадәр тулырак тәкъдим итү урынлы саналды. «1922 елның 27 июлендә язылган хатымны 1923 елның декабрендә Парижга барып, Мостафа Чокай улы белән очрашкач, кулыма кире алдым. Хатымда шул вакыттагы Сәмәрканд вилаятендәге вакыйгалар да, Мәскәүдән килгән хәбәрләр дә язганмын. Бу хатирәләрдә искә алырга кирәкле фикерләр түбәндәгеләр: «Совет

хөкүмәте Польшага каршы сугышта җиңеп чыкса, мөселманнарга карата яңа мәдәни сәясәт башланачак. Моны өч көн әүвәл Мәскәүдән Сәмәркандка килгән бер аркадашым, Сәлах Атнагулов, Манатов, азәрбайҗаннардан Мөхәммәт ага Шахтахтинский, Гали Айдар Сәгыйтьзадә, Җәлилмөхәммәт Кули-задә, төрек коммунистларыннан Әхмәт Җават, Назыйм Хикмәт, татарлардан Солтангалиев, Нәүширван Яушев Мәскәүгә чакырылган. Аларның һәрберсенә үз кавемләренең мәдәниятенә һәм коммунизм төзүгә багышланган зурзур әсәрләр язу яисә тәрҗемә итү бурычы йөкләнгән. Мәскәүдә Шәрык университеты оештырылган, аның башында Сванидзе белән Бройдо тора икән. Бройдо – хәзер Сталинның ярдәмчесе, 1917 елның апрель һәм июль айларында бу адәмне дус күреп, аны Хивага вәли итеп җибәрүегез никадәр ялгыш булуын аңлагансыздыр инде. Шушы Бройдо һәм профессор Поливанов, Азәрбайҗан өлкән яшьтәге рус теле белгече Шахтахтинский, төрек Әхмәт Җават белән берлектә, бөтен төрки халыкларга латин яки рус хәрефләре нигезендә аерымаерым әлифба төзеп, безне берберебездән һәм нигезебездән аеру сәясәте алып баралар. Нәзир Түрәколов белән хатыны Хәнифә, илдә латин хәрефләре кабул ителсә, төрки кавемләр өчен дөйөм *(гомум)* бер әлифба булсын дигәндер. Ләкин Бройдо белән Поливанов һәр кабиләгә фонетик үзенчәлекләренә ярашлы аерым тел булдыру сәясәтен алга сөрә. Латин хәрефе, әлбәттә, рус әлифбасына күчү өчен бер баскыч булып хезмәт итәчәк. Дагыстанда хәзер үк осетин һәм черкес телләрен кириллицага күчерү башланган. Алтай татарлары, фин вә якут өчен дә латин хәрефләре кабул итү хакында сүз бара. Бу фикерне алга сөрүчеләр дә Бройдо белән Поливанов икән».

Югарыда искә алганча, З. Вәлиди әлеге хатында Урта Азиядәге сәяси вакыйгаларны, шунда нәшер ителгән газета һәм журнал битләрендә төрки халыкларны латинга күчерүнең барышын тасвирлый һәм аңарда нинди сәяси мотив ятуын искәртә. Хатның дәвамында: «Поливанов, латин әлифбасы кабул ителсә, һәр сөйләш аерым әлифба нигезендә ныгытылачак (зафиксировать), аннан соң халыкларның берләшү өметләре нигездә киселәчәк, – дип яза, – Чынбарлыкта Советларның киләчәктә сәясәтенең төп нигезе шул. Моны хәзердән үк язып куярга идең». Мәгълүм булганча, хат шактый гыйбрәтле һәм Совет хөкүмәтенең шовинистик сәясәтенең чын йөзен ачкан. Шунда ук латин әлифбасының рус әлифбасына күчү юлында бер плацдарм гына булуына ышанасың.

Кыскасы, патша Россиясенең дә, большевиклар фиркасе идарәсендәге Совет хөкүмәтенең тел һәм әлифба сәясәтен гайре русларга каршы оста файдалануларын күрми мөмкин түгел һәм аның төп сәяси мотивы булуына да игътибар итәргә мәҗбүрбез. Г. Исхакый мәкаләсендә бу тема барлык тулылыгы белән яктыртылган. Аның язмада гәүдәләнгән фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмаган һәм югалтмаячак.

**Әдәбият**

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 12 т.: публицистика / [томны төз., текст., иск. һәм аңлат. әзерл. З. Мөхәммәтшин]. 470 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998–2014.

*Луначарский А.* Латинизация русской письменности // Красная Татария. 1930. 9 январь.

***Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***И.И. Ямалтдинов***

# «ФОЛЬКЛОР» ТЕРМИНЫН ФӘННИ ӘЙЛӘНЕШКӘ КЕРТҮ ТАРИХЫННАН

Статья посвящена истории введения термина «фольклор» в научный оборот татарской фольклористики.

**Ключевые слова:** фольклористика, татарское народное творчество, фольклор, термин.

Европада «фольклор» терминын (*ингл.* «халык акылы», «халык хикмәте») XIX гасыр урталарыннан инглиз галиме Вильям Томас куллана башлый. Татар фольклористикасында «фольклор» термины Г. Рәхим һәм А. Васильев тарафыннан 1926 елда төзелгән кулланмада очрый, ә фәнни әйләнешкә кертүне Г. Толымбай тәкъдим итә. Хәзерге вакытта әлеге термин халыкара термин булып санала.

1927 елны «Безнең юл» журналында Г. Толымбайның «Татар фольклоры турында кайбер фикерләр» мәкаләсе басылып чыга. 1931 елда язучы А. Шамов билгеләгәнчә, беренче булып халык әдәбиятын «фольклор» термины белән Г. Толымбай атый [Шамов, б. 62]. Әлеге вакытка кадәр халык иҗаты «халык әдәбияты» яисә «халык мосаннәфәте» дигән терминнар белән билгеләнә.

1929 елда Г. Толымбай рус телендә басылып чыккан «Нәрсә ул фольклор» мәкаләсендә фольклор төшенчәсен билгеләү мәсьәләсен күтәрә. «Әлеге сүз халык хикмәте мәгънәсенә ия», ди ул [Тулумбайский, 1929].

Бер елдан соң Г. Толымбай бу фикеренә ачыклык кертә: «Бу бер яшь өлкә әле, – дип яза ул. – Монда күп кенә мәсьәләләр бөтенләй чишелмәгән әле. Материалларга фольклор дип әйтү, шул фольклор материалларын тикшерә торган белемне фольклористика дип атау, рус белем дөньясында кискен рәвештә куелды һәм соңгы ике-өч ел эчендә шулай кулланылу күренеп килә. (Беркадәр тулылык бирү өчен, шуны әйтергә кирәк, бездә әлеге мәсьәлә 1927 елда күтәрелә. – *И.Я.*) ... Хәзер бездә дә әлегә кадәр халык әдәбияты исеме астында йөртелеп килгән нәрсәләрнең нинди исем алырга тиеш булулары турында бер кадәр ачыклык бирми ярамый. Чөнки исем, атама мәсьәләләренең гыйльми бер дисциплинаны тикшерү һәм аның тармакларын барлау өчен шактый зур кирәге бар. Шуның өчен дә бу мәсьәләгә туктамыйча үтү мөмкин түгел. Халык әдәбияты дип әйтүдән нәрсә аңларга була соң?» [Тулумбайский, 1930, с. 52].

1926 елда ук Татарстанның Академүзәге тарафыннан

бастырылып таратылган күрсәтмәләр җыентыгында бу мәсьәлә белгечләр Г. Рәхим һәм А. Васильев тарафыннан күтәрелә. «Фольклор һәм халык әдәбияты җыю өчен кулланма» «нәрсә ул фольклор?» дигән сораудан башлана. Анда билгеләнгәнчә, социаль-икътисади шартлар һәм техник казанышлар йогынтысы белән барлыкка килгән дөрес фән, гыйльми фәлсәфә, китаплы дин, хокукый белемнәр һәм язма әдәбият массакүләм таралыш алганчы, үзеннән үзе яралып, халыкның рухи ихтыяҗын үтәп килгән шаманизм дәвере калдыкларын барысын бергә җыеп фольклор дип атыйлар [Васильев, Рахимов, с. 24–25]. «Фольклор» терминын кертү һәм аның эчтәлеген ачыклау бик вакытлы була. Әмма фольклорга бик үк анык булмаган билгеләмә бирелә.

Г. Рәхим һәм А. Васильев «фольклор» терминын куллансалар да, аны һаман да «халык әдәбияты»ннан аерып карыйлар. Чөнки «фольклор» сүзенең мәгънәсе халык әдәбияты төшенчәсен колачламый. Шуңа күрә мәкаләләренең исемен «Фольклор һәм халык әдәбияты җыю өчен кулланма» дип атыйлар һәм, тирән фәнни нигезләмичә, фольклор һәм халык әдәбиятын ике аерым тармак буларак күрсәтәләр.

Г. Рәхим һәм А. Васильев фикеренчә, фольклор халык массасы белән бәйле, анда сыйнфый каршылык юк. Г. Толымбай исә, фольклор ул Г. Рәхим әйткәнчә, халык массасының ихтыяҗын гына каплап килми. Фольклордан бик нык сыйнфый ис килә. Аның сыйнфый йөзе, төрле сыйныфларга хезмәт итүе күренеп тора. Шуңа күрә, бу терминны «халык» дигән исем астына кую урынсыз, дип саный. Шулай ук «халык әдәбияты» төшенчәсе астына ырым, шом һәм фольклорның шундый башка тармакларын кертү мантыйксыз. Элек күбрәк фольклорның бер тармагына гына әйтелеп йөргән «халык әдәбияты» дигән сүз белән «фольклор» дигән сүзне алмаштыру һәм аларны берберсенә капма-каршы кую һич дөрес түгел. Шуңа күрә Европада һәм рус фольклорчылары тарафыннан алынган «фольклор» терминын безгә дә алырга кирәк, ди Г. Толымбай [Тулумбайский, 1930, с. 53].

Безнең фикеребезчә, киң мәгънәлелек ягыннан Г. Толымбайның «фольклор» терминын фәнни әйләнешкә кертергә тәкъдим итүе мантыйклы, эзлекле һәм нигезләнгән була. Ләкин ул «халык әдәбияты» төшенчәсен тарайтып ялгыша. Шулай ук, «халык әдәбияты»н төрле ышанулардан (хорафатлардан), дини катламнардан аерып, аны дөньяви итеп чистартырга омтылу да дөрес түгел. Болай якын килүдә илдәге ортодоксаль совет идеологиясе һәм иҗтимагый-сәяси вазгыятнең тәэсире чагыла. Әлеге идеология нигезендә, гомумхалык кыйммәтләрен булдырган аерым вәкилләрне исәпкә алмаганда, җәмгыятьнең югары катламнары, шулай ук руханилар һәм хәлле крестьяннар халык – хезмәт ияләре массалары составына кертелми.

Чынлыкта фольклор милли байлык һәм барлык социаль

катламнарның һәм төркемнәрнең иҗатын үзенә туплаган гомумхалык кыйммәтенә ия мәдәни феномен булып саналырга хаклы. Шуңа күрә инкыйлабка кадәрге һәм совет фольклоры эчтәлекләренең төрлелеге табигый [Культурология, с. 199].

А. Шамов билгеләп үткәнчә, фольклор атамасы колачлаган җырлар, бәетләр, такмаклар, әкиятләр һәм халык телендә, хәтерендә сакланган башка үрнәкләр революциягә кадәр рус әдәбиятында да һәм безнең әдәбиятта да «халык әдәбияты» исеме белән йөрде. Бик күп төрле сыйнфый катлаулардан төзелгән җәмгыятьнең фольклоры да бер генә сыйныфныкы булуы мөмкин түгел. Шуның өчен дә аны «халык әдәбияты» дигән төпсез һәм билгесез исем астына гына кертеп йөртү гыйльми яктан зур хата иде. Дөрес, фольклор (халыкны тану, белү дигән сүз. – *А.Ш.*) сүзе дә сыйнфый билге бирерлек сүз түгел. Шулай да ул, «халык әдәбияты» дигән атамага караганда, киңрәк һәм уңайрак [Шамов, б. 62]. Монда да «халык» төшенчәсен тар һәм сыйнфый яктан аңлап «халык әдәбияты» һәм «фольклор» терминнарын капма-каршы куюу сизелә.

Рус фольклорчысы Ю. Соколов «Рус фольклорын өйрәнүнең чираттагы бурычлары» («Очередные задачи о изучении русского фольклора») мәкаләсендә [Соколов, с. 5–29] фольклор материалларын – фольклор, фольклор турындагы фәнни дисциплинаны – фольклористика дип атарга тәкъдим итә. Г. Толымбай фикеренчә, без бу тәкъдимне кабул итсәк, шуның белән алга таба мөһим адым ясаячакбыз һәм профессор Ю. Соколовка каршы килмичә, фольклор тармакларын: әдәби фольклор, дини фольклор дип атарга тиеш булабыз [Тулумбайский, 1927, б. 24–28].

1930 елда Г. Толымбай фольклорның кайбер характерлы якларын күрсәтә. Шул ук вакытта иҗтимагый-сәяси вазгыять йогынтысында халык иҗатын артык идеологияләштерә һәм аны турыдан-туры идеология өлкәсенең бер тармагы итеп саный. Аның ясаган төп нәтиҗәсе түбәндәгечә: фольклор – ул идеология өлкәсенең бер тармагы – бер төре булган материаллар төркеме. Алар, Г. Рәхим һәм А. Васильев фикеренчә, үз-үзләреннән генә тумаган шикелле, бер дәвернең катып калган күренеше генә дә түгел, заман үзгәрешләренә карап үзгәрә килгәннәр һәм киләләр. Идеология өлкәсенең һәр тармагындагы кебек, бу материалларда да сыйнфый йөз бар. Аларның башка идеология төрләреннән аермалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1. Үзләренең килеп чыгу тарихлары белән язмасызлык заманына кайтып калганнары кебек, хәзерге көндә дә авыздан авызга күчеп йөриләр. Авыздан авызга күчеп саклану, фольклорның һәр төренә дә уртак сыйфат; 2. Фольклор материаллары мәгълүм дәвер белән бәйләнгән традициягә нигезләнә; 3. Авторлары мәгълүм түгел; 4. Мәдәният алга китү белән аларның урыннары тарая бара, ләкин шул мәдәниятнең туу, үсү тарихын өйрәнүгә кирәкле материал бу-

лып хезмәт итәләр [Тулумбайский, 1930, с. 54].

Г. Толымбай татар фольклорының күләменә тукталып, башта аның ышануга (хорафатка) нигезләнүе турында фикерләрен әйтә, аннан фольклорның икенче өлешен, руслардагы кебек, сәнгати фольклор дип атарга тәкъдим итә: «Бу атама бездә «әдәби фольклор» дип йөртелгәләде. Билгеле, «әдәби фольклор» дигән сүз үз астына кирәкле эчтәлекне ала алмый. Чөнки бит художестволы фольклор астына әдәби дигән атама астына кермәгән нәрсәләр дә керәләр. Мәсәлән, синкритик поэзияне генә алыйк. Боларда бит сүзләр белән бергә көй, бию, мимика кебек нәрсәләр дә бар» [Тулумбайский, 1930, с. 57].

XIX–XX йөз башы чорын өйрәнү, тикшеренүләрне анализлау «фольклор» терминының фәнни әйләнешкә керү тарихын татар фольклористикасының үсеш процессында карау мөмкинлеге бирә.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

**Әдәбият**

*Васильев А., Рахим Г.* Руководство для собирания фольклора и народной литературы. Казань, 1926. С. 24–25.

Культурология. М.: Экзамен, 2005.

*Соколов Ю.М.* Очередные задачи о изучении русского фольклора // Художественный фольклор. 1926. № 1. С. 5–29.

*Толымбайский Г.* Татар фольклоры // Татарстан. 1930. № 6/7. Б. 52–59.

*Толымбайский Г.* Татар фольклоры турында кайбер фикерләр // Безнең юл. 1927. № 11. Б.24-28.

*Тулумбайский Г.* Что такое фольклор // Художественный фольклор. 1929. № 4/5.

*Шамов А.* Фольклор мәсьәләләре // Яңалиф. 1931. № 7. Б. 62.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

УДК 811.2:82’091

***М.М. Шәкүрова,***
***Л.М. Гиниятуллина***

# Г. СӘГЪДИНЕҢ МЕТОДИК МИРАСЫ

Статья посвящена исследованию научных трудов известного литературоведа, лингвиста, методиста начала ХХ столетия Габдрахмана Сагди. В своих работах ученый рассматривал вопросы классификации жанров, попытался дать подробные определения терминам, выявить темы, предмет, виды, цель литературных произведений, затрагивал проблемы литературной критики. В статье также уделяется внимание анализу лингвометодических трудов ученого.

**Ключевые слова:** Габдрахман Сагди, татарская литература, татарский язык, лингвометодика.

Тел һәм әдәбият белеменең беренче буын вәкилләре арасында әдәбиятчы, тәнкыйтьче, педагог, телче, методист, күпсанлы дәреслекләр, мәкаләләр авторы Габдрахман Гайнан улы Сәгъдиев күренекле урын алып тора. Ул татар әдәбияты тарихын аерым дәверләргә бүлү принципларын, әдәби агымнар һәм иҗат методларын, стиль мәсьәләләрен, татар әдипләренең иҗат мирасын һәм биографияләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галим. Ләкин Г. Сәгъди иҗатының төп юнәлеше булып татар әдәбияты тарихы һәм аны укыту методикасын эшләү санала. Аның шундый хезмәтләреннән «Әдәбият ысуллары», «Октябрьдән элек һәм соң татар мәктәпләрендә әдәбият» китапларын әйтеп узарга мөмкин. Әлеге мәкаләдә авторның әдәбиятка һәм телгә, методикага караган хезмәтләрен кыскача анализлау максат итеп куелды.

Г. Сәгъдинең «Әдәбият ысуллары» китабы өч өлештән тора, бу өлешләр, үз чиратында, берничә бүлеккә бүленә. Хезмәтнең беренче өлеше әдәбият теориясе буенча эшләнгән. Анда түбәндәге юнәлешләр тәкъдим ителә: әдәбиятның предметы, төрләре; хикәя, роман, аларның төркемнәре һәм аларны язу; дастан, кыйсса, экият, мәсәл, театр рисаләләре, комедия, драма, трагедия; театрның әһәмияте. Боларның барысына да характеристика бирелә. Автор фикерләре хәзерге әдәбият белеме билгеләмәләре белән тәңгәл килә диярлек. Шул ук вакытта аермалар да юк түгел.

Беренче бүлек «Әдәбиятның мәүзугы» дип атала. «Мәүзугъ» хәзерге әдәбият белемендәге предмет, тема, проблема, сюжет терминнарын үз эченә берләштерә. Г. Сәгъди аңа түбәндәге билгеләмәне бирә: «Без, дөнья тормышында өзексез бер тәэссерат вә тәхессесәт дулкыннары астында йөзеп йөрмәктәмез. Менә әдәбиятыбызда хасыйл булган шул фикерләр, хисләр вә хыяллардан бәхет итә. Аның мәүзугы шул» [Сәгъди, 1912, б. 4].

Әдәбиятның асылыннан чыгып, автор әдәбиятны ике өлешкә

бүлә: каләм әдәбияты һәм халык авыз иҗаты (авыз әдәбияты). Г. Сәгъди, халык әдәбияты халыкның тарихын, яшәешен күрсәтә һәм ул тарих гыйлеменең бер нигезе булып тора, дип яза.

Каләм әдәбиятын исә «мөхәррирләр, әдип вә шагыйрьләр тарафыннан язылып, китап булып басылып чыккан һәр төрле хикәя, роман вә театр мәҗмугалары (*пьесалар*) һәм башка төрле тасвирлар вә шигырьләр» дип билгели [Сәгъди, 1912, б. 5]. Каләм әдәбиятын автор жанрларга бүлә, хикәя һәм романга тукталып үтә. Аларның әхлакый әһәмиятен күрсәтә.

Ләкин Г. Сәгъди әдәбиятны сәнгать төре итеп карамый. Ул әсәрләр бары әхлак өчен генә языла, дип белдерә. Татар әдәбиятында прозаның, нигездә, әхлак турында гына булырга тиешлеген ассызыклап болай яза: «...роман вә хикәяләр фәкать тәрзиб (*пакьләү*) әхлак өчен язылырга тиешлеләр. Романчыларның язачак романнарында тәвәҗҗеһ (*караш*) иткән ноктагалары ялгыз шул улмак лязим. Чөнки мәйданга китерәчәк роман вә хикәяләре, аңарда укучыларын фәсад (*бозык*) әхлакка өндәүче вә анларны зәһәрләүче булсалар, бондый роман вә хикәяләрне бозучылар җәмгыяте бәшәриянең сәгадәте өчен файда итүчеләрдән түгел, бәлки аңа агу тәкъдим кылучылардан хисап ителеп җәмгыятькә гафу улынмаячак дәрәҗәдә олуг бер җинаять иткән улачаклардыр» [Сәгъди, 1912, б. 9].

Әсәрнең бары әхлак өчен генә языла диюе Г. Сәгъдинең әлеге мәсьәләдә үзенә кадәр булган карашка иярүе. Аның бу фикере Г. Ибраһимов хезмәтләреннән нык аерыла [Ибраһимов, б. 67].

Г. Сәгъди роман һәм хикәяләрне бер типтагы әсәрләр дип билгели. XX гасыр башында язылган фәнни хезмәтләрнең барысында да аерым төгәлсезлекләр күзәтелә. Әмма бу аларның тел, әдәбият белеме өчен булган әһәмиятен һич кенә дә киметми.

Г. Сәгъди роман һәм хикәяләрне, ягъни проза әсәрләрен 5 төргә бүлә:

1) Хисси. Монда әсәрнең күп өлешен хиссият алып тора.

2) Хыялый. Әсәрнең күп урынында хыял стиле кулланыла.

3) Хөкеми. Күбрәк хөкеми һәм фәлсәфи эшләр хакында языла.

4) Фәнни. Мондый әсәр ахыры укучыларына ачык фәнни мәгълүмат бирә.

5) Мөкәммәл роман. Бу төр романнарда хиссият, хыял, фән һәм хөкемиятнең һәрберсенең үрнәге була.

Моннан тыш, Г. Сәгъди тагын бер классификация ясый. Ул романнарны тарихи һәм дәвери романнарга бүлә. «Үткән заман тормышындан алынып язылсалар *тарихи*, мөхәррирнең үзенең заманындагы тормыштан алынып язылган булсалар, *дәвери* роман исемен алалар» [Сәгъди, 1912, б. 116].

Автор хикәя һәм роман арасындагы аермаларга да тукталып үтә. Бу аермаларны ул, иң элек, әсәрнең темасына, сюжетына һәм күләменә карап билгели. Повесть белән хикәяне Г. Сәгъди бер итеп карый. Повесть дигән төшенчәне бөтенләй кулланмый.

Хезмәттә тагын бер чәчмә әсәр төре булган дастан телгә алына. Автор дастанны поэмага нигезли. Бу хәзерге караштан аерылып тора. Белгәнебезчә, хәзер поэма белән дастан ике төрле жанр булып исәпләнәләр.

Халык әдәбияты да автор тарафыннан, шулай ук жанрларга бүленә. Кыйссага бирелгән билгеләмәдән чыгып, кыйсса хәзерге хикәят төшенчәсенә туры килә дип әйтергә мөмкин. Хәзерге мәсәлне Г. Сәгъди хиссалык дип атый. Ул үзе дә «хиссалыкның» русчага тәрҗемәсен «басня» дип бирә, ә мәсәлне ул «сказка» дип атый. Әдип тарафыннан тагын бер жанр төре билгеләнә. Ул – «сонгый кыйсса» һәм «сонгый әкият»ләр. Язучы, мөхәррир тарафыннан эшкәртелгән кыйсса яки әкият шулай атала. Моңа мисал итеп ул Г. Рәшиднең «Сак-Сок» кыйсасын китерә. Фантастик әсәрләрне исә Г. Сәгъди «уйдырма» дип атый. Бу төр әсәрләргә мисал итеп ул Г. Тукайның «Чын белән ялган»ын, «Шүрәле»сен һәм «Япон хикәясе»н китерә.

Халык авыз иҗаты өстендә эшләгәннән соң, Г. Сәгъди драма әсәрләрен анализлый. Пьесаларны ул берничә төргә бүлә: комедия, драма, трагедия. Бүленешне автор әсәрнең функциясенә һәм геройларына карап ясый. Боларга бирелгән билгеләмәләр бүгенге әдәбият белемендәге билгеләмәләргә якын торалар.

«Әдәбият ысуллары» хезмәтендә Г. Сәгъди әдәби әсәргә тәнкыйть мәсьәләсен дә кузгата. Автор тәнкыйтьне әдәбиятка кертеп карый. Ул тәнкыйтьченең әсәр язучыдан һәрьяклап өстен булырга тиешлеген бәян итә. Бу Г. Ибраһимовта да шулай. Шушы ук кисемдә «план» һәм аның әһәмияте турында телгә алына. Авторның «план»га биргән билгеләмәсеннән чыгып, бу төшенчәнең композиция төшенчәсенә туры килүен әйтергә мөмкин.

Габдрахман Сәгъди «Әдәбият ысуллары» китабының өченче кисемендә әдәбиятның үзенчәлекләре, закончалыклары турында сүз алып бара. Шул рәвешле, Г. Сәгъдинең «Әдәбият ысуллары» китабы, Г. Ибраһимовның «Әдәбият кануннары», Г. Батталның «Нәзарияте әдәбият» хезмәтләре белән янәшә, әдәбият белеме фәненең беренче үрнәкләреннән саналырга хаклы. Ул әдәбият теориясе мәсьәләләренә караган зур фәнни эшнең бер өлеше – эпик әсәрләр теориясен үзәккә куйган китап. Башка төр әсәрләргә караган эзләнүләре соңрак дөнья күргән «Мохтәсар кавагыйде әдәбият», «Гыйләвә» кебек китапларда чагылыш таба.

«Әдәбият ысуллары» әдәбият теориясенә милли әдәбият үзенчәлекләрен исәпкә алып якын килгән хезмәт. Әдәбият белеме фәне 100 ел эчендә шактый алга китсә дә, XX йөз башында ук әлеге мәсьәләләрне күтәргән хезмәтләрдән бүген дә кирәкле белешмәләрне табарга була. Мәсәлән, терминология, әдәби әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләре, әдәбиятның асылы хакында аларда үзенчәлекле язылган.

Г. Сәгъдинең «Октябрьдән элек һәм соң татар мәктәпләрендә әдәбият» дигән хезмәте әдәбият укыту методикасы тарихына

багышланган. Хезмәтнең беренче бүлегендә Октябрь инкыйлабына кадәр мәктәпләрдә әдәбият укыту турында сүз алып барыла.

Автор татар теле һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләренә игътибар артуның сәбәбен турыдан-туры 1905 ел инкыйлабы белән бәйли, аның тарихын шуннан башлый. Г. Сәгъди уйлавынча, татар телен үстерү һәм шул өлкәдә эшләүчеләргә юл ачыла. «Бөтен халык революциясе дип тәкъбир ителгән бу революция XIX йөзнең соңгы яртысында Каюм Насыйрилар белән башланган, Гаспринскийлар, Рәшид Ибраһимовлар, Ризалар, Ф. Кәримиләр юлбашчылыгы, Гыйни байлар командасы астында кыздырылып, киңәйтелеп килгән зур тарихи бер хәрәкәткә соңгы җиңү юлын ачты. Татарның патшалык золымы астында буылып торган гомуми, иҗтимагый-мәдәни хәрәкәте бердән ерылып, шаулап агып китте. Нәтиҗәсендә, ул вакытта һәрнәрсәдән элек бөтен татар халкы өчен чарасыз кирәк һәм файдалы байтак кына уртак уңышлар казанылды», – дип яза ул [Сәгъди, 1927, б. 1].

К. Насыйри кебек шәхесләрне телгә алса да, Г. Сәгъди алар эшчәнлеген татар теле һәм әдәбияты укыту белән бәйләп карамый, 1905 елга кадәр тупланган тәҗрибәне телгә дә алмый. Бу яктан Г. Сәгъдинең карашлары Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди һәм башка бик күп мәгърифәтчеләрнең карашларыннан нык аерылып тора. Бу, бәлки, хезмәтнең Октябрь инкыйлабыннан соң, 1927 елны язылуы белән аңлатыладыр.

Г. Сәгъди фикеренчә, бу вакытта «Җәдиди мәктәпләрнең» саны арта. Ләкин татар теле һәм әдәбиятын уку йортларына кертү, укытуны үзгәртү бик акрынлык белән баруы хакында ул болай ди: «Беренче революция күп гасырлар буенча татар мәктәпләрендә уку теле булып йөргән гарәп, фарсы телләрен татарның үз теле белән алыштыру хәрәкәтен тизләтә. Бу, иң элек, башлангыч («ибтидаи») мәктәпләрдә генә эшләнелә. «Рөшди» дип аталып йөртелгән мәктәпләр яисә сыйныфларда исә (хәзерге 2 нче баскычның 5, 6, 7 нче елларына туры килә) татар теле зәгыйфь, бәлки әле ул анда кермәгән дип әйтерлек дәрәҗәдә була» [Сәгъди, 1927, б. 2]. Бу сүзләрдә дә төгәлсезлек бар. К. Биккуловның «Кыйраәт китабы» (1910) ибтидаянең 1–2 сыйныфлары өчен, «Кыйраәт вә зыйраәт» (1911) 3–4 нче сыйныфларга, С. Рахманколыйның «Монтазан кыйраәт китабы» (1912) ибтидаянең соңгы һәм рөшдиянең беренче сыйныфларына атап эшләнә, Н. Думавиның «Безнең мәктәп» китабы (1911–1917) әлифбадан алып урта сыйныфларга кадәр төзелгән томнардан тора. 1911–1917 елларда әдәбият теориясе, тарихы буенча басылып чыккан китаплар да шунда ук югары сыйныфларда дәреслек буларак кулланылышка керә (Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов һ.б.ның хезмәтләре). 1917 елга кадәр «рөшдия», хәтта «галия» баскычы өчен дә дәреслек-хрестоматияләр басылып чыга, димәк, алар буенча дәресләр алып барыла дигән сүз.

Әдип фикеренчә, татар мәктәпләрендә татар әдәбияты укыта башлауны таләп итеп яңгыраган беренче тарихи аваз 1908 елда «Әлислах» газетасында басылган «Мәктәпләрдә әдәбият дәресләре» исеме астындагы баш мәкалә була. Бу мәкалә Ф. Әмирханныкы. Ул әдипнең 4 томлыгына да кертелгән [Әмирхан, б. 77–79].

Габдрахман Сәгъди, мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыта башлауның беренче гамәли тәҗрибәләре 1910–1911 елларда гына күренә башлый, дип белдерә. Моның сәбәпләрен дә атап китә. Югарыда әйтеп үтелгән хезмәтенең алдагы бүлеген Г. Сәгъди «Әдәбият һәм методика кулланмалары» дип атый. Монда мәктәпләр өчен әдәбият белеме өлкәсендәге әдәбият теориясе һәм тарихыннан, әдәбият хрестоматияләреннән әһәмиятлерәк булган хезмәтләр атап үтелә. Боларга түбәндәгеләрне кертә: «Кавагыйде әдәбият» һәм аңа «Гыйләвә», «Әдәбият ысуллары», «Әдәбият мөгаллиме» (Г. Сәгъди); «Нәзарияте әдәбият» (Г. Баттал); «Әдәбият кануннары», «Татар шагыйрьләре» (Г. Ибраһимов); «Әдәбият юллары» (Гата Исхакый); «Татар әдәбиятының барышы» (Җ. Вәлиди – әдәбият тарихыннан); «Әлислах» газетасы, «Шура», «Аң» журналларында Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Н. Гасрый, Г. Рәхим һәм башкаларның төрле мәкаләләре; хрестоматияләрдән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (Г. Тукай), «Яңа әдәбият» (Г. Ибраһимов). Күренгәнчә, боларны санавы белән үк Г. Сәгъди үзенең беренче бүлектә язган фикерләренә каршы килә.

Алга таба автор февраль һәм октябрь инкыйлаблары арасында татар теле һәм әдәбиятына карата булган мөнәсәбәтне тасвирлый. Мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укыту мәсьәләсе күтәрелә, курслар оеша, корылтайлар җыела башлый. Боларда программа, мәктәп дәреслекләре карала. Казанда Бөтен Россия укытучыларының икенче корылтае уздырыла. Ләкин анда укыту методларына кагылмыйлар, чөнки укытучылар ул мәсьәләне күтәреп чыгарлык дәрәҗәдә әзерлекле дә булмыйлар [Сәгъди, 1927, б. 5]. Авторның фикеренчә, бу зур сикереш 1917 ел инкыйлабы белән өзелеп кала. Вакытлы хөкүмәт 1917 елның августында бөтен башлангыч мәктәпләрне мәгариф белән җитәкчелек органына тапшыра. Күпсанлы корылтайлар, курслар җыела, ләкин алар нәтиҗә бирмиләр.

Г. Сәгъди китапның беренче өлешендә менә шушылар хакында сүз йөртә, XX нче йөз башына татар әдәбиятының торышын түбәндәгечә бәяли:

– укыту бер эзгә салына;

– түбән сыйныф укучылары өчен әхлакый-эстетик принциптан чыгып төзелгән уку китаплары, хрестоматияләр чыгарыла; иҗади фикерне алга сөргән программалар дөнья күрә;

– югары сыйныфлар өчен әдәбият теориясен, әдәбият тарихын фәнни өйрәтеп язылган китаплар басыла;

– әдәбият укытуның теоретик мәсьәләләренә багышланган фәнни хезмәтләр языла башлый;

– уку-укыту мәсьәләләрен, аерым алганда әдәбият укыту, киң җәмгыятьчелекне дә, татар зыялыларын да борчый торган актуаль мәсьәләләр алга сөрелә;

– «Мәктәп», «Ак юл» (Казанда), «Мөгаллим» (Оренбургта) журналлары чыга.

Г. Сәгъдинең «Октябрьдән элек һәм соң татар мәктәпләрендә әдәбият» китабын, кайбер төгәлсезлекләр булуга карамастан, уңышлы хезмәт дип атарга кирәк. Ул безгә 1905–1917 еллар һәм аннан соңгы 10 ел эчендә татар теле, әдәбияты һәм методика үсешен күзалларга ярдәм итә.

Г. Сәгъди «Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыфы» дигән дәреслеген татар телен укыту методикасына багышлый. Хезмәтен автор дүрт-биш ел сынаганнан соң гына бастырып чагара. Сүз башында Г. Сәгъди «балаларны ничек, ни рәвешле укытканда, телебезнең сарыфын һәм нәхүен үзләштереп була?» дигән сорау куя һәм «кагыйдәләрне балаларның үзләреннән таптырырга яки табуга якынлаштырырга» кирәклекне ассызыклый [Сәгъди, 1913, б. 3]. Бу эвристик ысулны (кагыйдәне ятлатасы түгел, киресенчә, укучының үзеннән эзләтеп таптырасы) Ф.И. Буслаев, К.Д. Ушинскийлар тәкъдим иткән булган.

Г. Сәгъди әлеге дәреслек елән эшләргә өйрәтү өчен, ике дәреснең тулы үрнәген бирә. Галим дәреслекнең 6–8 нче битләрендә зат алмашлыкларын аңлата, дәрес барышын сорау-җавап формасында (ул әңгәмә ысулын да яратып куллана) алып бара:

*Мин. Син. Ул*

*– Ягез, минә шул сүзләрдән нәрсә аңлыйсыз?*

*– Боларның – мин дигәненнән без һәркайсыбыз үзебезне аңлыйбыз. Мин дип әйтсәк, һәрберебез үзебезне әйткән булабыз.*

*– «Син» дигәннән нәрсә ачасыз?*

*– Бусыннан үзебездән башка бер кешенең безгә эндәшеп әйткәнен ачыклыйбыз.*

*– Ул дигәннән ни аңлыйсыз?*

*– Ансыннан чит кешене аңлыйбыз. Менә мин, мәгълүм әфәнде, сезнең белән сөйләшкәндә янымда утырган бер иптәшемне әйтергә теләсәм, «ул» дип әйтәмен.*

*– Шулай. Бик дөрес әйтәсең. Ләкин ул чит кеше түгел, яныңдагы кеше ич!*

*– Нигә чит кеше булмасын? Мин сезнең белән сөйләшәм. Ә ул сезнең белән миннән башка кеше ич! Әлбәттә, сезнең белән миңа, сөйләшкән вакытыбызда, чит кеше булып тора ул.*

*– Ярый,өчесен дә дөрес аңладыгыз. Инде сез шуны уйлап карагыз: «мин» дип әйтмәсәгез, аның урынына сезгә ничек әйтергә кирәк булыр иде?..* [Сәгъди, 1915, б. 6–8].

Г. Сәгъди «Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыфы» дигән дәреслегендә сүз төркемнәре турында мәгълүмат бирә, фигыльләрне аеруча (барлык-юклык фигыльләрен, фигыльләрнең төрләрен, дәрәҗәләрен, бабларын (юнәлешләрен), ярдәмче фигыльләр һ.б.ны) җентекләп эшли. «Исем»гә түбәндәге билгеләмә бирә:

*Улы. Каләм. Язу. Куану. Дәфтәр.*

Кеше һәм әйбер атамаларын яки бер эш һәм бер хәлнең исемен «исем» дип атый.

1-сынау: *түбәндәге бәеттә исемнәр бармы? Шуларны аерып языгыз.*

*Шаулый* ***диңгез***
***Җил*** *өрәдер,*
***Җилкәнен*** *киргән* ***караб.***
*Төн вә көндез*
*Ул йөзәдер:*
***Юл*** *бара ят* ***ил*** *карап*
(Дәрдемәнд).

Г. Ибраһимовның да «исем» сүз төркемен өйрәткәндә, Дәрдемәндкә мөрәҗәгать итүен күргән идек. Дәрдемәнд шигырьләренең шул дәрәҗәдә популяр булуына, укучы тарафыннан җылы кабул ителүенә тагын бер кат ышанасың. Алга таба М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, Х. Бәдигый, М. Фазлуллин һ.б.ның дәреслекләрендә дә Дәрдемәнд шигырьләреннән өзекләр еш очрый. Китап укучыларга аңлаешлы, гади телдә язылган.

Г. Сәгъди «Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү» дигән дәреслегенең кереш сүзендә «Һәр мөгаллим галим була алса да, һәрбер галим мөгаллим вә педагог була алмыйдыр» дип искәртеп, дәреслек төзүнең гаять дәрәҗәдә катлаулы эш икәнлеген, зур тәҗрибә соравын әйтеп уза [Сәгъди, 1915, б. 4]. Әлеге дәреслек IV–V сыйныфларны күздә тотып төзелгән. Ләкин тел гыйлеменең морфология, сүз төзелеше, синтаксис һәм пунктуация өлеше бераз катлаулырак, һәрхәлдә, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килеп бетми. Инде дәреслекнең эчтәлегенә күз салыйк.

Бу дәреслек өч бүлектән, 36 дәрес үрнәгеннән гыйбарәт. Беренче бүлек 8 дәресне үз эченә алган: кереш дәрес, мәгънә, җөмлә һәм аның баш кисәкләре белән таныштыру, исем һәм аның берлек, күплек төрләре, фигыль, фигыльнең юклык төре, аергычлар, кидләр (сүзләрне яки җөмләләрне бер-берсе белән бәйләү; үзләреннән элек, я соң килә торган сүзләрнең мәгънәләрен тутыру-көчәйтү һәм киңәйтү өчен тагылып йөри торган сүзләр) белән таныштыру. 8 нче дәресне, материал күп булу сәбәпле, автор дүрткә бүлеп, 4 дәрес итеп үткәрергә тәкъдим итә [Сәгъди, 1915, б. 3].

Икенче бүлек 9 нчы дәрес белән 13 нче дәрес араларын колачлый: тагылмалар, юлдаш (парлы) сүзләр, эндәшләр, оеш җөмләләр (җөмлә кисәкләренең берәрсе бердән артык булган очрак), хөкем (хәбәр) һәм яшерен ияле җөмләләр, ким җөмләләр, күчерелгән җөмләләр (туры сөйләмгә туры килә) белән таныштыру. Язма күнегүләрдән «сорауларга тулы җавап бирү, җөмләләр төзү» кебек күнегүләр күбрәк кулланылса, сөйләм күнегүләреннән, беренче чиратта, «бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзү яки җөмләләрне дәвам итү» күздә тотыла. Автор укучыларның бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү эшендә беренче баскыч итеп балаларның иреклe сөйләүләрен атый. Ул укучыларда бәйләнешле сөйләм күнекмәләре тудыруда ярдәм итәрлек түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итә: текст белән эшләү, күңелдән ятлау, хикәяләү һ.б.

Дәреслекнең иң зур бүлеген өченче бүлек тәшкил итә (14 нче дәрестән алып 36 нчы дәрескә кадәр): тәмамлыкларның төрләре, боерыклар (боерык фигыль) һәм боерык җөмләләр, фигыльләр һәм аларның төрләре, шарт фигыль һәм шарт җөмләләр, хәл һәм вакыт җөмләләр, сыйфатлар, аергычларның төрләре һ.б. Биредә Г. Сәгъди морфология белән синтаксисның бик тыгыз үрелеп баруын күз уңында тота.

Өч бүлекне аерып чыгаруның махсус күрсәткече юк. Өчесендә дә сүз төркемнәре, кушымчалар, җөмлә кисәкләре һәм җөмләләр, аларның төрләре, тыныш билгеләре, һәркайсына мисаллар китерү, дәлилләү үзәккә куелган.

Гадәттә автор дәресне яңа төшенчә бирү, аны шәрехләү белән башлап җибәрә, кагыйдәләрне формалаштыра, мисалларны үзебезнең җирлектән ала. Г. Сәгъдинең үз мисалларыннан тыш, җыр, мәкаләләр, әдәби әсәрләрдән (Дәрдемәнд, Г. Тукай, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдин, Ф. Әмирхан, М. Гафури, З. Бәшири, Ш. Камал, Н. Думави, Ш. Шәриф, Укмаси һ.б.ның хезмәтләреннән) бик күп үрнәкләр китерелгән. Шунысы сөенечле: ул аерым җөмләләр белән генә чикләнеп калмый, текстлар белән дә эшли, тел күренешләрен татар әдәбиятыннан алынган мисаллар белән ныгыта, тел үзенчәлекләренә игътибарны юнәлтә. Әдәбият белгече Д.Ф. Заһидуллина «Әдәбият кануннары һәм заман» хезмәтендә «беренче сарыф-нәхү китаплары татар әдәби-нәзари фикеренә сәнгатьлелек, образлылык, язучы стиле кебек төшенчәләр алып килә, язу кагыйдәләрен билгеләү омтылышы ясый, әдәби сүз-сөйләм үзенчәлекләренә игътибар итә» дип, Г. Сәгъдинең әлеге дәреслегенә дә ишарә ясый [Заһидуллина, б. 72].

Дәреслектә шулай ук мөһим искәрмәләр (1-игътибар, 2-игътибар һ.б.) дә урын алган. Аларның күбесе, нигездә, тыныш билгеләре белән бәйле. Өй эшләре (вазифалар) дәрес үрнәкләренең иң җаваплы этабы булып тора. Алар уйланылган, укучыны иҗади эшләргә, эзләнергә өйрәтә торган итеп төзелгән. Өй эшләренең күләме түбәндәгечә: теге яки бу кагыйдәгә караган 10 ар, 20 шәр, хәтта 50 шәр мисал туплап алып киләсе. (Хәзерге көндәгечә – 3–4 мисал гына түгел!)

Автор үткән материалга кат-кат әйләнеп кайта. Мәсәлән, 14 нче дәрестәге бирем 2 нче һәм 6 нчы дәресләргә барып тоташа: *2 нче һәм 6 нчы дәресләрдәге мисалларда (шигырьләрдә) нинди исемнәр бар? Шуларның һәр төрен үзен бер рәткә тезеп язып китерегез* [Сәгъди, 1915, б. 30]. Укучылар Н. Думави, Г. Тукай һәм Дәрдемәнд шигырьләре ярдәмендә җөмләнең баш кисәкләрен, фигыль сүз төркемен өйрәнсәләр, җөмләләрнең төрләрен дә алар аша үзләштерәләр, тагын үткән теманы искә төшерәләр. Шул рәвешле автор дәреслек төзүдә темаара бәйләнешне дә саклый, кулланыла торган дәвамчанлык, күчемлелек принципларын да игътибар үзәгендә тота [Шәкүрова, б. 38].

Автор синтаксис һәм морфологияне бер яссылыкта карый.

Мәсәлән, Г. Сәгъди 16 нчы дәрестә төшем тәмамлыгы (туры тәмамлык) турында мәгълүмат биргәндә, башта кушымталарны (кушымчаларны) тикшерә. Мисалларда бирелгән фигыльләр аша сорау куеп (мәсәлән:, *тоям* (*нәрсәне?*), *ишеттем* (*нәрсәне?*) һ.б.), «төшем тәмамлыгының ахырына кушыла торган «-ны» кушымчасы кайсы бердә әйтелми дә калу» очрагын ассызыклап үтә: *Китап укыдым. Сыер саудым. Базардан күлмәклек алдым. Өй бураттым. Ат җиктем. Хат яздым.* Ләкин -ны кушымчасын «кеше исемнәреннән һәм исемлекләрдән (зат алмашлыклары күздә тотылган), шулай ук эти, әни, абзый, апай, җизни, абыстай кеби сүзләрдән төшереп калдырырга ярамый, *Мин сине күрмәдем. Ул мине белми. Әнине, абзыйны, җизнине, абыстайны алып бардым».* Алга таба Г. Сәгъди төшем килешенең кушымчасыз очрагы турында тулы һәм төгәл аңлатма бирә. Моннан тыш, дәреслектә бик кызыклы бер материал бар: тыныш билгеләре. XX гасыр башларында ук, ягъни татар телендә тыныш билгеләрен куюга багышланган хезмәтләр чыга башлаган бер дәвердә, Г. Сәгъди 10 төрле тыныш билгесен тикшерә, аларны кулланып, мисаллар белән нygыта һәм кагыйдә рәвешенә китерә. Ул пунктуацияне синтаксик һәм интонацион принципларга салып аңлата. Мәсәлән, 3 нче дәрестә җөмләнең баш кисәкләре – ия һәм хөкем турында мәгълүмат биргәндә, «...ияләр күп булып килсәләр, ул җөмләдә һәрбер иянең арасы кире өтер дип аталган ошбу (‘) билге белән бирелә», – ди автор. Шул ук вакытта искәрмә рәвешендә *(1-игътибар)* «Бер үк хөкем мәгънәгә куәт бирә, аның тәэсирен арттыру өчен тәкрар әйтелгәндә дә (кабатланганда) аралары кире өтер белән аерылыр: *Сызла, сызла, сызла күңелем, сызла бер туктамыйча; Сызла айлар, сызла еллар, сызла төн йокламыйча* (С. Рәмиев)» [Сәгъди, 1915, б. 12].

10 нчы дәрестә укучыларга эндәшләр турында мәгълүмат биргәндә, «алар янында кире өтер һәм “эндәшү билгесе галәмәте” дип аталган ошбу “!” галәмәт куелыр» дип, мисаллар нигезендә шәрехли.

11 нче дәрестә оеш җөмләләр янында – кире өтерләр, күчерелгән җөмләләрдә – ике нокта, кечкенә куш җәяләр (« »), 19, 20 нче дәресләрдә шарт һәм вакыт җөмләләрдә – кире өтер, 28 нче дәрестә сорау галәмәте (?) һ.б. тыныш билгеләренең куелу очракларына бәйнә-бәйнә туктала. Гомумән алганда, 36 нчы дәрес тыныш билгеләренә генә багышланган. Бу дәрестә галим 10 төрле тыныш билгесен тикшерә: нокта (.), кире өтер (‘), нокталы өтер (;), ике нокта (:), күпнокта (...), сорау билгесе (?) һәм эндәшү билгесе (!), алар янында кулланылган катнаш билгеләр («?!», «?...», «!...»); зур җәяләр [(...)], кечкенә җәяләр яки куш өтерләр („ “), сызык (–). Әлеге дәрес материалыннан чыгып, XX гасыр башларында нәкъ менә Г. Сәгъди тыныш билгеләренең төзек бер системасын булдырырга омтылган дигән фикергә киләсең. Кагыйдәләр

шәрехләнеп, билгеле бер калыпка салынган. Галим, иң элек, тыныш билгеләрен куюның әһәмиятен, бурычларын билгели, аларга түбәндәге таләпләрне куя:

1) аңлатырга уйланган мәгънә укучыларга ачык, җиңел аңлашылсын вә җиңел укырга ярдәм итсен;

2) кайсы урында күп, кайсы урында азрак туктарга тиеш яки кайсы тапкырда тавышка куәт бирергә дә, кайсы урында аны йомшартырга кирәк, менә шул ачык күренеп торсын;

3) укучының тавышы укыган чакта нинди агышлар белән агарга һәм үзгәрә барырга кирәклеге беленсен [Сәгъди, 1915, б. 76].

Мисал итеп нокта куелу очрагын карап китик. «Нокта кайчан куела?» дигән сорауга Г. Сәгъди түбәндәгечә аңлатма бирә:

«1. Нокта (.). Нокта үз алдына тәгәл мәгънәле һәм башкаларына бәйләнмәгән һәр җөмләдән соң куела. Исем яки мисаллар ахырында, яисә алар урынына языла торган ялгыз хәрефләрдән соң һәм язылырга уйланган нәрсәнең башына куела торган сүзләрдән, ягъни ахырдан шул билге куела» (36 нчы дәрес). Чынлап та, без хәзер дә, нигездә, шушы кагыйдәләргә таянып, нокта куябыз. Болар гына да түгел, нокта хикәяләү интонациясе белән әйтелгән җөмлә ахырында һәм кыскартылмалардан тыш, нәрсә булса да саналып киткәндә, алларында сан яки хәреф җәясез кулланыла икән, саннан соң да, кабатлаулар, тиңдәш кисәкләр, аныклагычлар, өстәлмәләр, ымлыклар, аваз ияртемнәре, раслау һәм инкарь итүче сүзләр янында, туры сөйләм һәм эчке сөйләмдә, пьеса текстларында, персонаж исемнәре, ремаркалар янында, астөшермәләрдә һ.б. урыннарда куела.

Г. Сәгъди, сорау һәм эндәшү билгеләренең вазифаларын аңлату белән генә чикләнмичә, аларның бергә килү очракларына да зур әһәмият бирә.

«1. Бик артык ис китеп, тәмам аптырап һәм гайрәт белән соралса яки көлү, чәнчү, үч алу һәм хурлау тарикынча бирелсә, ул чагында сорау илә бергә эндәшү билгесен дә куялар. Яки эндәшү билгесе куймыйча, аның урынына сорау билгесеннән соң күпнокта язалар (“?!”, “?...”).

2. Бик артык дулкынланып, артык якын күреп яисә берәрсеннән өмет итеп вә чарасызлык белән эндәшелсә, эндәш билгесеннән соң да күпнокта куялар (!...)» [Сәгъди, 1915, б. 79].

Күренә ки, җөмлә ахырында сорау һәм өндәү билгеләреннән соң куелган күпнокталар (гадәттә бу тыныш билгеләреннән соң күпноктаның ике ноктасы гына куела) интонациягә, эчке халәтне белдерү үзенчәлегенә бәйле.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Сәгъдинең «Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү» дәреслеге үз вакытында укытучыны телнең бөтен мөмкинлекләрен күзаллап, грамматик конструкцияләрдән файдаланырга, әдәбият белән бәйләп алып барырга өйрәтә. Тыныш билгеләрен билгеле бер тәртипкә китереп, укучыларда пунктуацион грамоталылык тәрбияли. Дәреслектә морфологияне синтаксик яссылыкта карау, кагыйдәләрне системага салу хәзерге тел методикаларында кул-

ланыла торган бүлекара бәйләнеш принцибының башлангычы булып тора.

Г. Сәгъди октябрь инкыйлабыннан соң да укытуын дәвам итә һәм китаплар яза («Фәне тәрбия дәресләре» (Педагогика дәресләре), «Фәне тәрбия вә тәгълим» һ.б.). Ул укытуга юнәлеш бирү, тел һәм имля мәсьәләләрен хәл итү максатыннан оештырылган конференция, корылтайлар эшенә дә катнаша [Гыйләҗева, б. 21].

Гомумән алганда, Габдрахман Гайнан улы Сәгъдинең татар теле дәреслекләре бик уйлап төзелгән: текстлар белән эшләү, сүзлек эше, грамматик материалны үзләштерү, сәнгатьле уку, грамоталы итеп язу күнекмәләрен булдыру, иҗади характердагы күнегүләр. Аның хезмәтләрендә урын алган принциплар, ысуллар һәм кулланылган алымнар, тел материаллары хәзерге тел, әдәбият укыту методикасында бүген дә әһәмиятле роль уйныйлар.

**Әдәбият**


*Әмирхан Ф.* Мәктәпләрдә әдәбият дәресләре // Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. IV т. Б. 77–79.

*Гиниятуллина Л.М.* Аналитические придаточные предложения в грамматике «Татар нәхүе» («Синтаксис татарского языка») Г. Ибрагимова // Молодой ученый. 2012. № 7. С. 144–146.

*Гыйләҗева Ч.М.* Габдрахман Сәгъди. Казан: ТФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2006.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман: Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Ибраһимов Г.* Әдәбият мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Сәгъди. Г.* Әдәбият ысуллары. Оренбург: Вакыт, 1912.

*Сәгъди Г.* Октябрьдән элек һәм соң татар мәктәбләрендә әдәбият. Казан: Тат. МХК басмасы, 1927.

*Сәгъди Г.* Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү: ирләр һәм кызлар мәктәбенең ибтидаи соңгы, рөшди беренче сыйныф шәкертләре өчен дәреслек. Казан: Умидъ, 1915.

*Сәгъди Г.* Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыфы: ибтидаи мәктәпләрнең соңгы, рөшди мәктәпләрнең 1 нче сыйныф шәкертләре өчен дәрес китабы. Казан: Өмет, 1913.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.



***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;*

***Гиниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 39

***Р.В. Шәйдуллин***

# ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ТАРИХЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ ТУРЫНДА УНИВЕРСАЛЬ ФӘННИ-МЕТОДИК КОМПЛЕКС

В статье рассматривается научно-практический и методологический контекст универсального научно-методического комплекса «История и культура народов Татарстана». Особое внимание уделяется цели и задачам научно-методического комплекса в плане углубления знаний учащейся молодежи по различным проблемам этнической истории и культуры народов Татарстана, а также вовлечения ее в образовательно-культурологический процесс сохранения многовекового историко-культурного наследия этнических сообществ республики.

**Ключевые слова**: Республика Татарстан, народы, учащаяся молодежь, учебно-методический комплекс, концептуальная задача издания, научно-практическая методология комплекса, этническая история и культура народов.

Татарстан Республикасының иң зур байлыгы – анда яшәүче халыклар, ул аларның күпләренең Ватаны. Халык иҗатының күптөрлелеге һәм этник үзенчәлеге, традицияләренең һәм йолаларының үзгәлеге Татарстанның мәдәниятен хасил итә. Республиканың этник манзарасы гасырлар дәвамында формалашты. Татарстанда яшәүче халыкның бүгенге милли составы Идел буе төбәге үсешенең тарихи һәм демографик шартлары аның геосәяси хәле белән аңлатыла. Татарстан Республикасы, татар халкының күпчелек өлеше тупланып яшәве белән генә түгел, төп этномәдәни һәм милләтне төзегән ресурсның туплануы белән дә башка төбәкләрдән аерылып тора.

Безнең көннәрдә күпмилләтле Татарстан халкының гомуми мәдәнияте һәм, аерым алганда, шәхеснең формалашу процессы шулкадәр актуаль – ул фәкать төрле дәрәҗәдәге мәгариф, шул исәптән югары уку йортлары системасы аша гына гамәлгә ашырылырга мөмкин. Халыкларның тарихы һәм мәдәнияте турындагы тулы һәм дөрес белемнәр, ксенофобияне һәм аерым этник стереотипларны җиңүгә ярдәм итеп кенә калмыйча, республика гражданнарының рухи дөньясын баета, аларда милләтара татулыкка һәм хезмәттәшлеккә позитив юнәлеш формалаштыра. Ж.Г. Нигъмәтов: «Үзлектән рухи үсешкә табигый мохитнең эстетик оешканлыгы, кешеләрнең үз-үзләрен тотышының социаль формалары, кешеләр мөнәсәбәтләренең матурлыгы, көнкүреш булышлык итә», – дип яза [Нигматов, с. 248]. Моннан тыш, теләсә кайсы халыкның этник үсеше үзенчәлекләрен тулы күләмдә аңлау өчен, аның килеп чыгышы тарихын, меңнәрчә еллар дәвамында формалашкан

этномәдәни асылының үзенчәлекләрен белү зарур. Татарстанның этник бергәлекләре арасында катгый мәдәни, бигрәк тә административ-территориаль чикләр уздыру кыен, чөнки тарихта даими рәвештә үзара мәдәни йогынты, төрле милләт кешеләренең күчеше һәм аларның кушылуы процессы бара.

XXI гасыр башында иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормыштагы үзгәрешләр уку йортларының яңа укыту-мәгариф стандартларына күчүе белән бәйле рәвештә Татарстанда аның халыклары тарихы һәм мәдәнияте буенча системалаштырылган фәнни-методик комплекс булдыру зарурияте туды. Әлеге зарурият гамәлдәге фәнни-методик программаларның һәм әсбапларның шактый өлешенең универсаль һәм комплекслы характерда булмавы, шул ук вакытта аларның күбесенең искерүе һәм заманча уку процессы таләпләренә генә түгел, мәгълүмати җәмгыять таләпләренә дә җавап бирмәүләре белән аңлатыла. Бүген милли-төбәк аспектында Татарстан халыкларының үзенчәлекле тарихы һәм мәдәнияте аерым урын били, үсеп килүче буынны укыту-тәрбияләү барышында аның әһәмияте зур. Моның өчен укучы яшьләрнең барлык категорияләренә өйрәнелә торган тема буенча белемнәрне системалы рәвештә җиткерүгә, аларда шул юнәлештә алга таба эшләү максатыннан аналитик белем базасы булдыруга сәләтле яңа, универсаль комплекслар кирәк.

«Татарстан халыклары тарихы һәм мәдәнияте: универсаль фәнни-методик комплекс» – Татарстан халыкларының этник тарихын һәм үзенчәлекле мәдәниятен социомәдәни анализлауга һәм тасвирлауга багышланган универсаль басма. Аның материаллары фәнни-мәгариф һәм тәрбия җәһәтеннән зур әһәмияткә ия, чөнки аларда башка тарихи һәм фәнни-методик чыганакларда урын алмаган мәгълүматлар тупланган. Әлеге мәгълүматлар ярдәмендә Татарстан халыклары тарихы һәм мәдәниятенең күп кенә билгеле булмаган сәхифәләрен торгызырга мөмкин. Алар үсеп килүче буынны тулы сыйфатлы укыту һәм яшьләрдә Россия Федерациясенең өйрәнелә торган милли субъектындагы татар милләте һәм башка этносларның рухи мәдәнияте үсешендә катнашырга теләү хисләрен тәрбияләү өчен зарур.

Укучы яшьләрдә Татарстанның – Идел буендагы уникаль төбәкнең гасырлар дәвамында бер тормыш пространствосында үзара тату яшәп, бер-берсеннән матди һәм рухи мәдәният-ләр элементларын үзләштергән, шул ук вакытта үзләренең милли үзенчәлекләрен саклаган төрки, фин-угор һәм славян халыкларының этник бәйрәмнәре зур кызыксыну уятырга мөмкин. Билгеле булганча, халык бәйрәмнәре күпмилләтле Татарстанда күптөрле традицион мәдәниятләргә тартуда аерым роль уйный; анда ел саен этник бәйрәмнәр уздырыла, аларда республикада яшәүче халыкларның милли традицияләре чагылыш таба. Болар – татарларның Сабан туе, русларның «Каравон»ы,

удмуртларның «Гырон-быдтон»ы, чувашларның «Уяв», мордваларның «Балтай», мариларның «Семык», керәшен татарларының «Питрау» бәйрәмнәре һ.б. Бәйрәмнәр – Идел буе халыкларының рухи традицияләрен саклау һәм үстерү мөмкинлекләре күрсәткече [Нургаянова, б. 370].

Мондый бәйрәмнәрне укыту-методик комплексында системалы карау-өйрәнү нәтиҗәсендә укучы яшьләрдә туган төбәкнең йолаларын һәм традицияләрен тирәнтен үзләштерү мөмкинлеге туа, бер үк вакытта төрле халыкларның милли мәдәниятләрен саклау, үстерү һәм мәдәни-белем бирү барышына җәлеп итүгә өмет уяна. Моннан тыш, Татарстан Республикасында уздырыла торган этник бәйрәмнәр анда яшәүче күпмилләтле халыкларда төрле халыкларның мәдәнияте белән якыннан танышырга, аларның традицияләрен, йолаларын күбрәк белергә мөмкинлек бирә. Татарстанда яшәүче этнослар өчен исә бу – киләчәк буыннарга үз мәдәни байлыкларын саклау һәм тапшыру мөмкинлеге дә.

Укыту-методик комплексының мөһим концептуаль асылы аның интегратив характерда булуыннан гыйбарәт. Ул Татарстанда яшәүче татар, мари, мордва, рус, удмурт, чуваш һәм башка халыкларның мәдәниятләре үзенчәлеген һәм аларның үзара этномәдәни бәйләнешен күрсәтә. Анда комплекслы фәнни-мәгълүмати, иллюстратив, тарихи чыганакларны өйрәнү, фәнни-методик һәм белем бирүнең гамәли базаларын булдыру буенча эш нәтиҗәләрен яктырта. Комплекс берничә бүлектән тора: кереш өлеш, эчтәлекле контент, тарихи чыганакларны өйрәнү исемлеге, фәнни-методик контент, контроль-тикшерү контенты, кушымта.

Һичшиксез, әлеге фәнни-методик комплекс белем бирүнең төрле өлкәләрендә эшләячәк белгечләрне тарихи-культурологик яктан әзерләүгә булышлык итәчәк. Ул шулай ук төрле мәгариф-агарту оешмалары хезмәткәрләренә укучы яшьләргә белем һәм тәрбия бирүдә әһәмиятле кулланма да булачак. Басмада урын алган материаллардан белем бирү һәм эшкә өйрәтүнең башка өлкәләре белгечләре дә файдалана ала. Анда әйдәп баручы гуманитар фәннәр галимнәре һәм гамәли хезмәткәрләр тарафыннан әзерләнгән тарихи-этнологик материаллар тупланган, алар укучы яшьләрнең Татарстанда яшәүче халыкларның тарихы һәм мәдәнияте турындагы белемнәрен киңәйтүгә һәм тирәнәйтүгә юнәлтелгән, милли үзаң, патриотлык, кешелеклелек, рухи-әхлакый идеал һәм мәдәният, халыкара толерантлык формалаштыруга да ярдәм итәчәк.

*Мәкалә «Татар телендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып барган галимнәр һәм укытучылар өчен Татарстан Республикасы гранты» ярдәмендә язылды (2017 ел).*

**Әдәбият**

*Нигматов З.Г.* Гуманистические основы педагогики: учеб. пособие. М.: Высшая школа, 2004. 400 с.

*Нургаянова Н.Х.* Фольклорные фестивали и народные праздники как форма сохранения этномузыкальных традиций народов Поволжья // Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия: материалы IV Международной научно-практической конференции, посвященной 55-летию музыкально-педагогического образования в г. Казани (Казань, 15 октября 2015 г.). Казань: Отечество, 2015. С. 370–375.

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының*
*энциклопедистика үзәге җитәкчесе*

УДК 373.3

***Л.Г. Гыйләҗева,***
***Г.В. Һадиева***

# ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ: БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ КОМПЛЕКСЛЫ ЭШЛӘР

Комплексные работы на татарском языке для 1 класса позволяют на основе текста определить понимание прочитанного, а также оценить предметные результаты по математике, русскому языку и окружающему миру и выявить уровень сформированности универсальных учебных действий. Статья посвящена вопросам оценивания знаний и умений учащихся 1 класса по Федеральному образовательному стандарту начального общего образования (ФГОС НОО). Использование данных материалов в урочной и внеурочной деятельности позволит выявить сформированность предметных, метапредметных и личностных результатов.

**Ключевые слова:** комплексные работы, предметные результаты, метапредметные результаты (универсальные учебные действия), личностные результаты, стартовый и итоговый контроль, система оценивания.

Соңгы ун ел эчендә җәмгыятьтә белем бирүнең максатларын һәм аны тормышка ашыруның юлларын күзаллау кардиналь рәвештә үзгәрде. Нигездә, белем системасын тәкъдим итү – билгеле бер нәтиҗә алу максаты белән белем бирүдә актив эшчәнлеккә күчү, аерым бер уку предметларын үзләштергәндә катлаулы тормыш ситуацияләрен предметара бәйләнеш, белем һәм күнекмәләргә ия булу барышында укытучы белән укучы арасындагы хезмәттәшлек, укытуның эчтәлеген һәм ысулларын сайлаганда, укучының актив катнашу процессы [Метапредметные результаты, с. 9]. Мәктәп укучыларында гомумуку күнекмәләрен формалаштыру бүгенге көндә тиз һәм сыйфатлы белем бирүдә перспектив юл булып тора.

Саналып кителгән компонентлар универсаль уку гамәлләрен (*алга таба УУГ*) үстерү концепциясендә күрсәтелгән [Как проектировать..., с. 7]. Шуңа күрә укучыларның яңа белем бирү баскычына әзерлек дәрәҗәләрен белем һәм күнекмәләр нигезендә генә түгел, ә УУГнең төп төрләрен формалаштыру базасында бәяләргә кирәк. Белем бирү системасының төрле баскычлары дәвамлылыгының нигезе – «белем ала белү»не формалаштыру.

Бүгенге көндә мәгариф системасында мөһим нәтиҗәләрнең берсе булып, укучыны «белем ала белү»гә өйрәтә торган һәм үзүсеш, үзтәрбия сәләтен үстерүгә юнәлтелгән метапредмет нәтиҗәләре санала [Метапредметные результаты, с. 15]. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (*алга таба ФДБС*) укучыда УУГ формалаштыруны максат итеп куя. Билгеле булганча,

алар дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәсендә предмет материалына нигезләнеп алып барыла.

Универсаль уку гамәлләрен үстерү концепциясе эшчәнлеккә системалы якын килүне күздә тота. Киң мәгънәдә «универсаль уку гамәлләре» термины «белем ала белү» мәгънәсен аңлата, ягъни субъектның аңлы һәм актив рәвештә яңа социаль тәҗрибә алу юлы белән үсешкә һәм камилләшүгә сәләтле булуын белдерә. Тар мәгънәдә исә бу терминны укучыларның мөстәкыйль рәвештә яңа белемнәрне үзләштерү, күнекмәләрне формалаштыруны тәэмин итә торган эшчәнлек ысулларының җыелмасы дип билгеләп була.

ФДБСның төп үзенчәлекләренең берсе – **яңа бәяләү системасы.** Стандарт таләбеннән чыгып, укучыларның предмет буенча белемнәре генә түгел, ә УУГ формалашу һәм аның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре дә исәпкә алына. Нәтиҗәдә эчке контроль системасының ике состав өлеше билгеләнә: педагогның контроль-бәяләү эшчәнлеге һәм укучыларның үз контроль-бәяләү эшчәнлеге [Хәмитова, б. 6]. Шул уңайдан заманча мәктәптә укучыларда метапредмет нәтиҗәләрен бәяләүдә предметара нигезгә корылган **комплекслы эшләр** аеруча әһәмиятле. Комплекслы эшләр – башлангыч мәктәптә метапредмет нәтиҗәләренә ирешүне бәяләүне формалаштыру чарасы, тәкъдим ителгән текст өстендә эшләү аркылы «Әдәби уку», «Татар теле», «Рус теле», «Математика», «Әйләнә-тирә дөнья» һ.б. предметларга караган биремнәр системасы ул. Мондый тип эшләрдәге биремнәр системасы икенче буын стандартлары нигезендә билгеле бер белемнең үзләштерелүен тикшерүгә генә түгел, ә беренче сыйныф укучысының тупланган белем, формалаштырылган күнекмәләр һәм УУГ нигезендә уку һәм гамәли мәсьәләләрне чишә белүен тикшерүгә дә юнәлдерелгән [Сизонова, с. 163].

Бүгенге көнгә кадәр мәгариф системасында татар телендә нәшер ителгән комплекслы эшләр бөтенләй юк. Шушы ихтыяҗны исәпкә алып, «Өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр: 1 нче сыйныф» дип аталган ярдәмлек (кулъязма формасында) төзелде.

Ярдәмлектә нигездә өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр урын алган. Алар татар мәктәпләрендә кулланыла торган дәреслекләрнең укыту-методик системасына нигезләнеп төзелде. Өйрәтү характерындагы әлеге хезмәтне укытучылар төрле предмет кысаларында куллана ала.

Комплекслы эшләрне 3 нче чирек ахырында һәм 4 нче чиректә үткәрергә тәкъдим ителә. Ярдәмлектә урын алган вариантларның барысын да эшләү мәҗбүри түгел, укытучы үзе теләгәнен сайлап алырга яки әтиәниләргә балалар белән аерым эшләү өчен тәкъдим итәргә мөмкин. Индивидуаль эшләгәндә материалны авыр үзләштерүче балага өлкәннәрнең ярдәме мөһим. Кулланманы шулай ук укучылар өчен өстәмә дидактик материал һәм метапредмет күнекмәләрен

формалаштыру һәм йомгаклау эшенә әзерләү өчен дә файдаланырга мөмкин.

Ярдәмлектә өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр 20 вариантта тәкъдим ителде. Биремнәр халык авыз иҗаты, татар һәм рус язучыларының әдәби әсәрләренә нигезләнеп формалаштырылды. Текстлар төрле эчтәлектә һәм укучыларның яшь үзенчәлегеннән чыгып яраклаштырылды.

Комплекслы эшләр, укучыларда «Татар теле», «Әдәби уку», «Рус теле», «Математика», «Әйләнә-тирә дөнья», «Сынлы сәнгать» предметлары буенча нәтиҗәләр формалаштыру белән беррәттән, шәхескә кагылышлы (әдәп-әхлак нормаларын үзләштерү, үзен тормышта лаек шәхес итеп тоту, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү һ.б.) һәм метапредмет нәтиҗәләренә карап (танып белү, коммуникатив һәм регулятив УУГ) 4 төр типик биремнәр рәвешендә тәкъдим ителде.

Ярдәмлек белән эшләү барышында беренче сыйныф укучысында түбәндәге белем һәм күнекмәләрне үстерү максат итеп алынды. Уку өлкәсендә: уку техникасы һәм күнекмәсе, «эчтән уку» күнекмәсен формалаштыру, текстта ориентлаша белү (текстка кагылышлы сорауларга җавап бирә белү, текст эзлеклелеген билгеләү, авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, текстның идея эчтәлеге белән икенче бер текст эчтәлеге арасында параллель үткәрә белү), инструкцияне укып аңлый белү, биремнән чыгып, тексттан кирәкле булган мәгълүматны сайлап ала белү, тексттагы мәгълүматны биремнәр системасындагы мәгълүмат белән бәйли белү, текст һәм мәгълүмат белән эшли белү, текст эчтәлегенә карата үз фикерен формалаштыра һәм әйтә белү, тестлар белән эшли белү.

Тел системасы өлкәсендә: сүзнең мәгънәсен аңлау, ситуациядән чыгып, тиешле сүзне таба белү; сүзтезмә, җөмләләр төзи белү, гади җөмлә төзелешендәге хаталарны таба белү; дөрес язу күнекмәләре (өйрәнелгән күләмдә) формалаштыру, матур язу күнекмәләре булдыру (күчереп язу яисә үз фикерен белдерүне таләп иткән биремнәрдә), сүзлек запасын баету.

Математика өлкәсендә: өйрәнелгән бүлекләр буенча белем һәм күнекмәләрне үстерү (сан, арифметик гамәлләр, геометрик күзаллаулар, төрле типтагы мәсьәләләр чишү), текст, таблица формасында бирелгән мәсьәләләрнең биремнәрен аңлап чишә белү, үз гамәлләрен нигезли белү.

Әйләнә-тирә дөньяны танып белү өлкәсендә: табигать объектлары, аларның характерлы билгеләре турындагы беренчел күзаллауларны булдыру, матдә һәм җисем (масса, күләм, тизлек һәм башка характеристикалар), тере һәм тере булмаган табигать объектлары, хайван һәм үсемлекләрнең төрле классына караган аерым бер вәкилләрен тану һәм аларга характеристика бирү, аерым бер географик объектларны тану; системага салу.

Моннан тыш тәкъдим ителгән эшләр системасы рефлексия, җайга сала белү, үзконтроль, үзкоррекция кебек универсаль

гамәл ысулларын булдырырга да ярдәм итә.

Ярдәмлектә мәгълүмат алу, эзләү, алган белемнәрне ныгыту юллары шактый төрле итеп бирелгән һәм алар түбәндәге мәгълүмати уку күнекмәләре формалаштырырга ярдәм итә:

– текстның темасын һәм төп мәгънәсен билгеләү, җөмләдән яисә тексттан тиешле мәгълүматны эзләп табу;

– берничә сүзләр варианты арасыннан куелган бурычка туры килә торганын эзләп табу;

– табылган сүзне төрле график тамга белән билгеләү;

– өлешләре, элементлары, символик билгеләнелешләре буенча сүзне эзләп табу;

– төрле ысуллар белән (сүз, таблица, схема, диаграмма рәвешендә) бирелгән мәгълүматны үзләштерү, таблица структурасында ориентлашу, таблица белән эшли белү, бирелгән схема нигезендә сүзне табу һәм, киресенчә, сүзгә схема төзү;

– ребуслар чишү, анаграммалар төзү.

Мәгълүматны үзгәртү, куллану түбәндәге мәгълүмати уку күнекмәләрен формалаштыра:

– сүзләрне образларга әйләндерү, бер төр мәгълүматны икенче төргә әйләндерү;

– бирелгән сүзләрдә мәгънә табу;

– бирем шарты буенча җөмләләр яки текст төзү;

– терәк сүзләрне дөрес кулланып, текстны уку һәм төшеп калган сүзләрне язып кую;

– тексттан алынган мәгълүматны кулланып, сорауларга җавап бирү;

– текстта бирелгән сүзгә мәгънәсе буенча якын булган икенче сүз табу;

– үрнәк нигезендә таблица төзү;

– билге-символик билгеләнелештә мәгънә табу.

Басмада урын алган комплекслы эшләр нигез һәм катлаулы дәрәҗәдәге биремнәрдән гыйбарәт. Ярдәмлекнең ахырында һәрбер вариантның җаваплары күрсәтелгән, бу исә укучыга үзен бәяләргә мөмкинлек бирә. Биремнәр ике типка берләштерелеп тәкъдим ителде:

1) билгеле бер дәрәҗәдә УУГ формалаштыру максатыннан махсус бирелгән сорау яки биремнәр: когнитив, эмоциональ, эшчәнлекледән башлап, иҗади характердагы биремнәргә кадәр;

2) бер үк вакытта төрле УУГ формалаштыруга ярдәм итә торган күпфункцияле биремнәр.

Ярдәмлектә, беренче чиратта, шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләренә зур урын бирелде. Нәкъ менә беренче сыйныф укучысында игелеклелек, намуслылык, гаделлек, тырышлык, батырлык сыйфатларын булдыру аеруча мөһим. Әхлакый төшенчәләрне формалаштыру, текстның эчтәлегеннән чыгып, биремне үтәгәндә яки сорауларга җавап биргәндә, укучының шәхси позициясен билгеләү аша бара. Тексттагы вакыйгаларга, геройларга карата укучының үз позициясен билгеләү ирекле җавап, текстка исем уйлап табу һәм татар халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышу аша эшләнде.

Ярдәмлектә җавап формасына бәйле рәвештә төрле

характердагы биремнәр урын алган:

– рәсем формасында җавапны сайлап алу;

– бер яки берничә дөрес җавапны сайлап алу;

– сүз формасындагы кыска җавапны тиешле урынга язу;

– текстта төшеп калган сүзләрне язу;

– тулы һәм ирекле җавапны язу;

– эзлеклелекне билгеләү;

– үзара бәйләнешләрне уклар (сызыклар) ярдәмендә күрсәтү;

– хатаны эзләп табу һәм төзәтү h.б.

Шулай итеп, комплекслы эшләрне үткәрү бер предмет кысаларында алган белем һәм күнекмәләрне башка төр уку ситуацияләренә һәм бурычларына күчерә белү сәләтен формалаштырырга, укучыларның компетентлылык дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә һәм башлангыч белем бирүдә системалы-эшчәнлекле юнәлешне тормышка ашыруда актуаль форма булып тора.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

**Әдәбият**

*Батырева С.Г.* Типовые задачи по формированию универсальных учебных действий. Литературное чтение. 1 класс: пособие для учащихся общеобразоват. учреждений. М.: Просвещение, 2012. 95 с.

Как проектировать универсальные учебные действия в начальной школе: от действия к мысли / А.Асмолов и др. М.; СПб.: Просвещение, 2008. 151 с.

Метапредметные результаты: Стандартизированные материалы для промежуточной аттестации: 5 класс / Г.С. Ковалёва и др. М.; СПб.: Просвещение, 2014. 160 с.

*Мошнина Р.Ш.* Типовые задачи по формированию универсальных учебных действий. Окружающий мир. 2 класс: пособие для учащихся общеобразоват. организаций. М.: Просвещение, 2013. 79 с.

*Сәгъдиева И.Т.* «Аңлап уку стратегияләре һәм текст белән эш итү» программасы // Мәгариф, 2015. № 12. Б. 14–17.

*Сизонова В.В., Ткаченко М.О.* Комплексная работа – средство формирующего оценивания достижения метапредметных результатов в начальной школе [Текст] // Педагогическое мастерство: материалы VII Междунар. науч. конф. (г. Москва, ноябрь 2015 г.). М.: Буки-Веди, 2015. С. 162–166.

*Хәмитова Г.Р.* Федераль дәүләт башлангыч гомуми белем бирү стандартларын гамәлгә кую мәсьәләләре // Мәгариф, 2015. № 1. 3–7 б.

***Гыйләҗева Лилия Гыйльметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты доценты*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының өлкән укытучысы*

УДК 373.1:373.21

*И.И. Хаббанов*

# ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘ ӨСТӘЛ УЕННАРЫНЫҢ РОЛЕ

В статье рассматривается роль игр в педагогической деятельности. Особое внимание уделяется играм настольного типа в познавательном и личностном развитии детей дошкольного и младшего школьного возраста. Подробно рассказывается об обучающей интерактивной настольной игре «Сәяхәт» на татарском языке.

**Ключевые слова:** татарский язык, игра, настольные игры, педагогические технологии, игровые технологии.

Бүгенге тормыш катлаулы, тиз үзгәрүчән. Әлеге шартларда мәгарифнең дә кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара. Инновацион белем бирүнең төп бурычлары булып яңа нәтиҗәләргә ирешү, конкурентлыкка сәләтле, социаль яктан җаваплы, инициативалы шәхесләр тәрбияләү тора. Бүгенге мәгълүмати технологияләргә нигезләнгән мәгарифнең нәтиҗәлелеге файдаланыла торган технологияләрнең төренә генә түгел, ә бәлки педагогик эшчәнлекнең сыйфатына да бәйле. Укыту барышында яңа педагогик технологияләрне куллану яңа ысул һәм алымнарны үстерүгә, укытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә.

Тел – милли мәдәният белән кызыксындыруда төп чараларның берсе. Элегрәк телгә өйрәтүдә фәнни материалга күбрәк басым ясалган булса, хәзер исә гамәли якка игътибар артты.

Телгә өйрәтүнең башлангыч этабында укытучы алдында торган төп бурычларның берсе – әлеге процессны мөмкин кадәр кызыклы итү, аңа карата мәхәббәт тәрбияләү. Кече яшьтәге балалар эмоциональ һәм хәрәкәтчән булганлыктан, аларның игътибарын бер ноктага җәлеп итү зур көч сорый. Кагыйдә буларак, мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары беренче чиратта аларны кызыксындырган әйберләргә игътибар итәләр. Уен исә бу яшьтәге балаларның төп эшчәнлек төре булып санала. Телгә өйрәтүдә уен формасын куллану уку-укыту барышын җиңелләштерә, укучылар өчен кызыклырак итә.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларны үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, укыту һәм тәрбиянең бердәмлегенә ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда уеннарның әһәмияте зур. Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар укучыларны активлаштыра, аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә һәм иҗади атмосфера тудырырга ярдәм итә. Уеннар вакытында, фән нигезләрен үзләштерү белән

биргә, укучы үз фикерләрен дәлилли белү күнекмәләре дә ала.

Уен технологияләре телгә өйрәтүдә уникаль формаларның берсе булып тора. Шартлы уеннар истә калдыру, кабатлау, ныгыту яки мәгълүматны үзләштерү эшчәнлеген бертөрлелектән коткарырга, ә эмоциональ уеннар укучыларны активлаштырырга ярдәм итә. Уенның тагын бер уңай ягы дип үзләштергән белемнәрне яңа ситуациядә куллану мөмкинлеген атарга була, ягъни төрле рольләргә кереп, бала, реаль тормыштагы кешеләрнең эш-гамәлләрен кабатлый, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, эмоцияләрне һәм кичерешләрне уенга күчерә.

Укыту методикасында, Н.А. Короткова, Н.Я. Михайленко, А.И. Сорокина, Н.Р. Эйгес һәм Ф.К. Блехер, А.С. Ибраһимова, Н.М. Конышева, М.Т. Салихова хезмәтләренә нигезләп, мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен уеннарга зур игътибар бирелә. Бу педагоглар уенны нәкъ менә әлеге яшьтәге балаларны өйрәтүдә үтемле ысул буларак аңлаталар. Хәзерге заман педагогларыннан П.П. Блонский, Л.С. Выготский, С.Л. Рубинштейн, Д.Б. Эльконин һ.б. мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлеге буенча махсус тикшеренүләр уздыралар. Урта белем бирү мәктәпләрендәге үзенчәлекләр буенча бу юнәлештәге фәнни хезмәтләрдә В. Арутюнян, О.С. Газман, В.М. Григорьев, О.А. Дьячкова, Ф.И. Фрадкина, Г.П. Щедровицкий кебек галимнәрнең кызыклы гына фикерләре бар.

Бүгенге заман шартлары бала шәхесенә якын килү, анда иң яхшы сыйфатлар тәрбияләү һәм күпкырлы шәхес формалаштыру белән характерлана. Бу мәсьәләне гамәлгә ашыру балаларны яңача укыту һәм тәрбияләүне таләп итә. Укыту укучыларның танып белү сәләтен формалаштыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. «Уен – әйләнә-тирә мохит төшенчәләрен баланың рухи дөньясына алып кергән зур якты тәрәзә ул. Уен – кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган учак ул», – ди В.А. Сухомлинский [Сухомлинский, 1974].

Педагогика һәм психология өлкәсендә укыту ысулы буларак, уен XX гасырның 70 нче елларында киң тарала. Укыту барышында уен технологиясе максатчан булуы белән гомуми уен эшчәнлегеннән аерылып тора. Хәзерге көндә мәктәпләрдә уен эшчәнлеге уку-укыту процессын активлаштыру һәм интенсивлаштыру максатыннан

1) фәнне өйрәнүдә мөстәкыйль технология,

2) нинди дә булса технологиянең бер состав өлеше,

3) дәрес яки аның бер этабы (кереш өлеше, яңа теманы аңлату яки ныгыту, күнегүләр эшләү яки контроль эш һ.б.),

4) дәрестән тыш эшләр технологиясе буларак файдаланыла.

Дәресләрдә уен технологиясе уенга корылган төрле ситуацияләр аша тормышка ашырыла һәм уку эшчәнлегенә кызыксындыру, эшкә дәртләндерү чарасы буларак файдаланыла. Уен технологиясе укучыларның танып белү активлыгын үстерә, акыл үсешен

активлаштыра, аларда яңа сыйфатлар булдыруга ярдәм итә. Уен вакытында фән белән кызыксыну көчәя, мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, игътибарлылык арта, хәтер яхшыра, уйлау күнекмәләре камилләшә.

Уен барышында, вакытны күңелле үткәрү белән бергә, бала алдагы тормышта кирәк булачак үҗәтлек, моторика, телдән санау, карар кабул итү, ораторлык осталыгы һәм башка күнекмәләрне дә үстерә. Сабый өчен уен – бик җитди шөгыль. Шуңа бәйле рәвештә әти-әниләр яки тәрбияче-укытучылар уеннар сайлауда аеруча игътибарлы булырга тиешләр.

Укытучы уенның төп асылын белеп эш иткәндә уку белән уенны аралаштыру процессы уку-укыту эшчәнлегендә уңай нәтиҗәләргә китерә. Уенга карата педагогик тәэсир итүнең максаты – балаларда уйный белү күнекмәләрен формалаштыру, сюжетның эчтәлеген аңлату һәм аралашу әдәбен булдыру. Биредә укыту һәм тәрбия бурычларын гына уңай хәл итеп калмыйча, шул ук вакытта укучы белән аралашуны да җайга салырга була. Димәк, балалар коллективын берләштерүдә, туплауда, дусларча мөгамәлә урнаштыруда да уенның әһәмияте зур.

Галим-педагог Г.К. Селевко уеннарны берничә төркемгә бүлә:

– дидактик уеннар;
– тәрбияви уеннар;
– үстерелешле уеннар;
– социальләштерүче уеннар [Селевко, 2005].

Бу хезмәттә төп игътибар дидактик уеннарга бирелгәнлектән, шушы төргә киңрәк тукталып үтү урынлы булыр.

Дидактик уеннар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтә һәм тәрбия бирә торган көчле чараларның берсе. Мондый төр уеннар өлкәннәр тарафыннан уйлап чыгарыла. Дидактик уеннарны классификацияләүнең берничә төре бар. Аларның авторларыннан беренче итеп Фридрих Фребель һәм Мария Монтессорины атарга була. Совет педагогикасында дидактик уеннар системасы сенсорлы тәрбия теориясенә нигезләнеп, З.М. Богуславская, О.М. Дьяченко, Е.О. Смирнова тарафыннан уйлап табыла.

Дидактик уеннарның балаларга акыл тәрбиясе бирүдә роле зур. Уйнау вакытында баланың сөйләме үсә, сүз байлыгы арта.

Эш барышында бала телне өйрәнү бурычын куймый, ул уйный, моның өчен аңа бу сүзләрне белү кирәк. Күп тапкыр ишетеп, балада аралашу өчен кирәк булган телнең образы барлыкка килә.

Теләсә кайсы уен фикер эшчәнлеген активлаштыра, белем дәрәҗәсен киңәйтә, белем һәм осталык күнекмәләрен камилләштерә. Аларда бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге уяна. Балалар уйнаганда шатланырга, эшләгән эшләреннән риза һәм канәгать калырга тиешләр. Уен барышында балаларның төрле яклап сәләтләрен үстерү өстендә дә эшләргә кирәк. Уенчыда җиңүгә кызыксыну уянырга тиеш, шуңа күрә дә укучылар

биремнәрне төгәл үтәргә тырышалар, кагыйдәләрне саклыйлар.

Галимә С.Л. Новоселова телгә өйрәтә торган дидактик уеннарны 5 төргә бүлеп карый:

– автодидактик-предметлы (предметлы яки уенчыклы уеннар);

– сюжетлы-дидактик;

– өстәл уеннары;

– сүзле уеннар;

– хәрәкәтле уеннар [Новоселова, с. 83].

Бүгенге көндә баланың социальләшүе, үсеше һәм тәрбиясендә үтемле чараларның берсе булып заманча өстәл уеннары тора. Алар баланың игътибарын, хәтерен, ассоциатив һәм абстракт фикерләвен формалаштырып һәм үстереп кенә калмыйча, аңа уен формасында үз эшчәнлеген билгеле бер кагыйдәләргә нигезләргә дә өйрәтә. Бу төр уеннарны телгә өйрәтү барышында куллану уңай нәтиҗәләргә китерә. Методик яктан дөрес уйланылган уен, бер яктан караганда, укучыда өйрәнелә торган телгә карата мәхәббәт тәрбияли, сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләм эшчәнлеген табигый нормаларга якынайта, икенче яктан, тел материалы өстендә нәтиҗәле эшләргә ярдәм итә, белем бирүдә коммуникатив юнәлеш таләпләренә җавап бирә [Айдарова, б. 5].

Бүгенге өстәл уеннары арасында төрле телләрне өйрәнүгә йөз тотылганнары күп. Татар телен өйрәнергә яки бу өлкәдә белемен камилләштерергә теләгәннәр өчен исә өстәл уеннары бик аз. «Сәяхәт» интерактив өстәл уены әлеге ихтыяҗны тулыландыру максатыннан булдырылды да.

«Сәяхәт» – әйләнә-тирә дөнья предметы эчтәлегенә туры китереп төзелгән сораулар һәм биремнәрне берләштерә торган татарча интерактив өстәл уены. Төркемнәрдә яки индивидуаль рәвештә биремнәрне башкару башлангыч сыйныф укучыларында әлеге фәнне үзләштерү барышында формалашкан белем һәм күнекмәләрне куллануга юнәлтелгән. Биремнәр Федераль дәүләт белем бирү стандартын исәпкә алып төзелгән. Әлеге интерактив уен балаларда конкрет психик процессларны һәм күнекмәләрне формалаштыруга, әйләнә-тирә дөнья аркылы татар теленә өйрәнүдә һәм үзләштергән белемнәрен тикшерергә ярдәм итә. Бу уен белемнәрне үзләштерүдә дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә дә кулланыла ала.

«Сәяхәт» дөньябызны интерактив форма аша белергә һәм өйрәнергә ярдәм итә. Сорауларга җавап биреп, бала флора белән фаунаны яхшырак аңлый башлый, география һәм биология буенча шактый белем туплый.

Шул ук вакытта әлеге өстәл уены укучыларны татар теленә өйрәтүне, әйләнә-тирәгә җайлашуны да күздә тота. Укучылар уен барышында мәгълүматны истә калдыру, анализлау кебек күнекмәләрне дә булдыралар. Әлеге проект, предмет, метапредмет һәм шәхси нәтиҗәләр формалаштырудан тыш, баланың иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә дә зур роль уйный. Уен кыры 5 төрле өлешкә бүленгән: шәһәр, урман, диңгез, чүл һәм таулар. Уенда катнашучы фишкалар урнашкан өлкә темасына караган

сорауларга җавап бирергә тиеш. Уен җирәбә салудан башлана. Төрле сынаулар үтеп, финишка беренче барып җиткән уенчы җиңүче дип табыла.

Йомгак ясап, шуны әйтергә була: дидактик уеннар, аерым алганда югарыда атап үтелгән «Сәяхәт» өстәл уены укучылар өчен программада каралган материалны, татар теленең лексикасын үзләштерергә ярдәм итә һәм, әлбәттә, татар телен өйрәнүгә кызыксынуны арттыра.

Укыту эшчәнлегендә файдаланылган теләсә кайсы уен методикасының нигезен дидактик материалның актуаль булуы һәм дөрес сайлануы тәшкил итә. Балалар тәкъдим ителгән мәсьәләне уен рәвешендә кабул итеп, төрле җавап яки чишелеш табарга омтыла. Әлеге процесс үзлектән генә башкарылып калмыйча, төркемнәргә берләшүне дә күздә тота. Әнә шул рәвешле коллективта эшләү сәләте камилләштерелә. Төркемнәр арасында ярышып эшләү балаларны эшне тизрәк һәм башкаларга караганда нәтиҗәлерәк тәмамлауга этәрә. Бу, бер яктан, билгеле бер мәсьәләне чишүгә бирелгән вакытны кыскартса, икенче яктан, тел өйрәнүдә дә ачык нәтиҗәләр бирә.

**Әдәбият**

*Айдарова С.Х., Сәлимуллина Й.Р., Әхмәдиева Э.З.* Татар телен укытуда уен технологиясе һәм дидактик уеннар // Саммит языков и культур: сборник тезисов международного саммита языков и культур. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. 200 с.

*Новоселова С.* О новой классификации детских игр // Дошкольное воспитание. 1997. № 3. 122 с.

*Селевко Г.К.* Великая иллюзия. Игра как метод обучения // Учительская газета. 2005. № 40. URL: http://www.ug.ru/archive/9599 (дата обращения: 15.02.2018).

*Сухомлинский В.А.* Сердце отдаю детям. Киев: Радянська школа, 1974. 288 с. URL: http://www.6lib.ru/books/serdce_otdau_detam-20228.htm (дата обращения: 15.02.2018).

***Хаббанов Илмир Илгизәр улы,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы 2 нче номерлы лицей-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

УДК 792.09

***Р.Р. Солтанова***

# ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ «БАНКРОТ»Ы: ЗАМАН РУХЫНДАГЫ КОМЕДИЯ-ФАРС

В статье анализируется сценография одного из популярных современных спектаклей ТГАТ им. Г. Камала. Раскрываются особенности пространственного решения, костюмного облика персонажей.

**Ключевые слова:** татарский театр, сценография, сценический костюм, балаган, цирк, клоунада.

Татар театрының бүгенге этабы, барыннан да бигрәк, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының милли-мәдәни тәңгәллекне саклап, аның иҗтимагый әһәмиятен тирәнтен аңлап иҗат итүче баш режиссер Фәрит Бикчәнтәевнең тынгысыз эзләнүләре белән бәйле. Ул театрның эшчәнлеген элеккеге традицияләрен кире кагу юлы белән түгел, ә 90 нчы елларда формалашкан, һәр сәхнә әсәренә иҗади якын килеп һәм аны бүгенге чынбарлык белән үрелдереп үстерүне кыю күтәргән яңа буынга йөз тотып оештыра.

Бүгенге татар театры спектакльләрне тамашачыларга я кәмиткә әйләндереп (Г. Камалның «Банкрот»ын), я җырлы-биюле күренешләр белән баетылган тамаша рәвешендә (Т. Миңнуллинның «Диләфрүз-Remake»), яки геройларны радио-тамаша алымнары белән гәүдәләндерү (И. Зәйниевнең «Мәхәббәт-FM») аша тәкъдим итеп, «югары мәдәни» чишелешле формаларга күчә баруын раслый.

Ф. Бикчәнтәевнең постановкалары оста куелышы белән әсәрләрне бик нык җанландырып җибәрә, алар тамашачыларга кәмит, ярминкә һәм цирк күренешләрен хәтерләтә. Режиссер Ф. Бикчәнтәев бүгенге сәхнә тормышының элеккеге кысаларын күпкә киңәйтте, артистлар уенын фантазиягә баетты, образларны гәүдәләндерүдә кыюлык, тәвәккәллек, иреклелек элементлары өстәп, спектакльләргә фарс рухы бөркеде. Г. Камалның «Банкрот» пьесасы буенча сәхнәләштерелгән спектакльдә, мәсәлән, гадәти булмаган кыланышлар (трюклар), очышлар, киемнәрне үзгәртү, үтә ачык төсләр белән бизәү, кинохроникалардан файдалану, бер-берсенә һич тә тәңгәл булмаган киемнәр һәм, ниһаять, артистизмны көчәйтеп җибәрерлек сәхнә бизәлеше (рәссам-декоратор Сергей Скоморохов) тамашачыларны тагын да җәлеп итә (Г. Камалның бу әсәре буенча куелган спектакль 2011 елда «Алтын битлек» («Золотая маска») премиясенә тәкъдим ителгән иде).

Күренешләр ике киңлектә – сәхнәдә һәм тамаша залы белән ачыктан-ачык аралашу аша бара.

Ягъни ике чорда (XX йөз башында һәм бүген) яшәгән персонажлар, Г. Камал идеяләрен үстерү белән бергә, үз образларыннан чыгып, актер халәтенә күчәләр, зал белән элемтәгә керәләр. Әйтик, Сираҗетдин (Р. Бариев) рампа янына утыра да тамашачыдан газета алып укый башлый яки, залга төшеп, тамашачының телефонын тартып алып, актер буларак, үзен фотога төшерә (селфи алымы куллана). Ике кодагый – Гарифә (Ф. Әкбәрова) белән Мәликә (Р. Юкачева) залдагы рәтләр буйлап бүгенге байларның «Крутушка» һәм «Бәкер» шифаханәләрендә типтереп ял итүләре хакында гайбәт сатып йөриләр. Монда «Банкрот» постановкасында тасвирланган көнкүрешнең вакытлар циклы бозыла, спектакль барышында ике чор кара-каршы очраша. Сираҗетдин һәм башка персонажлар залга мөрәҗәгать итеп, өй атмосферасыннан икенче бер киңлеккә күчәләр. Мондый мизгелләрдә сәхнә күренеше өзелеп тора, аннан соң яңадан җанланып китә. Шулай итеп һәр киңлекнең үз чоры, үз вакыты үзенчә дәвам. Өйдәге эшләр тукталып тора. Әйтерсең, спектакль геройлары арасындагы Сираҗетдин алар белән сәхнәдә яшәми, ә, һәр чорга хас уйдарма банкротлык белән бәйлелектә, үз тарихын гәүдәләндерә. Шулай итеп, төрле яссылыкта – тамашачының да, актерларның да, партнерлар буларак, үзара мөнәсәбәтләрен яктырткан параллель күренешләрдә Сираҗетдин Туктагаев образы үзенә бер типтагы геройга әверелә. Чынбарлыктан, көндәлек тормыштан ерак торган бу герой үзен чолгап алган дөньядан өстен итеп һәм конкретлаштырып гәүдәләндерелә, чөнки ул Г. Камал дәвере вәкиле генә түгел: Сираҗетдинне үз чорыннан, бигрәк тә, бүгенге заман аерып тора. Сәхнә бизәлеше күренешләрен алыштырып, сәгать механизмы кебек әйләнеп торучы тәгәрмәч тә актерлар уены янәшәсендә символик әһәмияткә ия. Моннан тыш, Казанда беренче трамвай барлыкка килүне, басмаханәләр эшчәнлеге үсешен яктырткан 1920 еллар кинохроникасыннан ак төстәге трамвайның баруын экранда күрсәтү, сюжетка кертелгән географик күчешнең (Казаннан Мәскәүгә, ярминкәгә һ.б.) хыялый охшашлык кына булмыйча, вакытлар аралыгындагы сәяхәт икәнлеген дәлилли. Сираҗетдинның бертуганы 1913 елдагы акчалар курсын 2013 елгы сумнарга (52 млн.) күчергәч, банкротлык белән бәйле вакыйга бүгенге заман характеры ала. Рельслар өстендәге вагонга сәхнә артыннан курантлар тавышын, тәгәрмәчләр шакылдавын өстәү, стадиондагы алкышлар һ.б гөрелте ишетелү театрның мөмкинлекләрен кинематографиянеке белән янәшә куя.

Спектакльдә сәхнә мәйданчыгы, немец драматургы Б. Брехт методы нигезендә, актерлар уенына яңача иркен хәрәкәтләр өстәү юлы белән баетыла. Персонажлар бөтен кирәкле әйберләре белән трамвайда киләләр һәм тамашачылар күзалдында Сираҗетдиннең өен көйли башлыйлар: үткән гасыр шәһәре татар гаиләләренә хас булганча, сәгать,

люстра урнаштыралар, хәтта читлектә мәчене дә элеп куялар. Хезмәтчеләр төрле савытларга утыртылган ямь-яшел гөлләр, граммафон күтәреп керәләр – болар Г. Камал спектакльләре өчен хас элементлар. Рельслар түгәрәк буенча хәрәкәт итеп, сәхнәне цирк аренасына әверелдерә. Сәхнәгә барабан рәвешендәге зур өстәл тәгәрәтеп чыгаралар. Ул әле мәҗлескә килүчеләрнең аш өстәле, әле әңгәмәләшеп утыру өстәле вазифасын үти. «Акылдан шашкан Сираҗетдин», маймыл кыяфәтенә кереп, тамашачыларны көлдерә башлый: я кәгазь чәйнәргә тотына, я кәгазь ертыкларыннан үзенә битлек ясый, кара савытындагы сыеклыкны эчә. Ул да түгел, Сираҗетдин маймыл кебек кыланып, үзенең кире беткән хезмәтчесенең алдына менеп утыра да аның колагын тешли; табибның аркасына утырып, ат өстендәге җайдак сыман кылана. Гөлҗиһан кунаклары җыелгач, зур өстәл шамакайлык мәйданчыгына әйләнә. «Акылдан шашкан Сираҗетдин»не, бөтенләй тыя алмый башлагач, кош кебек, читлеккә утыртып куялар да өстенә яулык бөркиләр. Спектакль ахырында Сираҗетдин, юләргә сабышудан туктап, кесәсеннән пропеллер чыгара да читлекне дирижабльгә әйләндерә һәм, очып, сәхнә өстенә күтәрелә. Ерактан халыкның аны алкышларга күмүе ишетелә. Ягъни дирижабль Сираҗетдинне башка (галәми) киңлеккә тоташтыручы символга әйләнә.

Персонажларның характерын ачуда киемнәрнең үзенчәлекле төс-формалары да зур роль уйный. Вакыйгалар башланганда үткән гасыр татар сәүдәгәрләренең гадәти киемендәге Сираҗетдин, «акылдан шашкан»нан соң, зур-зур кесәле һәм күп төймәле, җиңсез, билле киемнән чыга. Ул инде ак күлмәкле, киң балаклы аксыл буйлы штанын алыштырган. Персонажларның теленә генә түгел, киенү манераларына да француз темасы үтеп керә. Көлкеле кыяфәт тудыру максаты белән сайланган татар катыш европача киенү үрнәге (париклар, мех-мамык шарфлар, каурыйлы эшләпә һ.б.) байбичәләрнең зәвыксызлыгын күрсәтү өчен бик оста кулланылган.

Бүгенге татар театрының төп казанышы – рухи-мәдәни киңлектә үз урынын дөрес сайлау, заман таләп иткән үзгәрешләргә тәңгәл җавап бирү. Театрда драматургия хакындагы калыплашкан күзаллауларны җимерү белән бәйле җитди үзгәрешләр булды. Н. Якубова сүзләре белән әйтсәк, «важна заявка на некое равноправие или по крайней мере на отстутствие иерархии между разными проявлениями “пьесы” и спектакля» [Якубова, с. 8]. Кыскасы, текст, еш кына, режиссерның актив катнашлыгы белән театрда туа, ә кайвакытта ул спектакльне әзерләүнең төрле этапларында актерларны да җәлеп итеп тормышка ашырыла. Моңа мисал итеп нәкъ менә Г. Камалның «Банкрот»ын сәхнәләштерүне китерергә була. Бу спектакльдә режиссер белән рәссамның үзара аңлашуы һәм бер-берсенә ышанып эшләве дә яңача образлылык тудыруда зур роль уйный. Баш режиссер Ф. Бикчәнтәев белән

баш рәссам-декоратор С. Скомороховның әнә шундый нәтиҗәле хезмәттәшлеге татар театрын заманча яңа биеклеккә күтәрде.

**Әдәбият**

*Султанова Р.Р.* Сценография произведений Г. Камала: особенности художественного пространства // Научный Татарстан. 2004. № 3. С. 149–152.

*Султанова Р.Р.* Особенности татарского пластического мышления в сценографии татарского театра // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов. Серия «Искусство тюркского мира», вып. 1. Казань: Заман, 2009. С. 109–114.

*Sultanova R.* The peculiarities of Tatar Plastic Mentality in the Scenograpie of the Tatar Theatre // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов. Серия «Искусство тюркского мира», вып. 1. Казань: Заман, 2009. С. 115–117.

*Якубова И.О.* Театр эпохи перемен в Польше, Венгрии и России, 1990–2010-е годы. М., 2014. С. 8.

***Солтанова Рауза Рифкат кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 745

***Л.М. Шкляева***

# ЧҮКЕП НӘКЫШЬЛӘҮ ОСТАСЫ АЛЕКСАНДР ИВАНОВ ИҖАТЫНДА СӘНГАТИ ОБРАЗЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

В статье раскрываются творческие приемы современного мастера-чеканщика А. Иванова. Он является восприемником традиционных способов художественной обработки металла, характерных для ремесленников Волжской Булгарии и Казанского ханства. В его работах нашли отражение мотивы татарской народной культуры.

**Ключевые слова:** прикладное творчество, чеканка, рельефные композиции, татарский орнамент.

Татарстанның Тукай районындагы Александр Иванов туып үскән Мартыш авылында да, Ивановлар гаиләсендә дә нәселдән килгән нәкышьчеләр булмый. Чүкеп бизәкләр төшерү остасына бу һөнәр буенча башлангыч та, урта белем дә алырга туры килми, аның таланты күктән иңгән, үҗәтләнеп үзлегеннән өйрәнүгә нигезләнгән. Нәкышь остасы сюжет сәнгате серләренә мөстәкыйль ирешә һәм үз әсәрләрендә, реализм таләпләрен саклаган хәлдә, халкыбызның татар әдәбиятында һәм төрки эпоста күтәрелгән темаларны чагылдыра. Аның яңалыгы металл панноларны чүкеп бизәкләүдә Согд, Бәлх, Мәрв көмеш савыт-сабалары өчен характерлы булган алымысулларны, төрле формаларны файдаланудан гыйбарәт. Металл өслеген чүкеп бизәкләү күп гасырлар элек барлыкка килеп, болгарларда, XX йөзнең беренче чирегендә татар халык декоративгамәли сәнгатендә (аеруча зәркән эшләнмәләрдә) киң таралган булган. 1970 елларда чүкеп бизәкләү белән кызыксыну нык көчәеп китә, шәһәр һәм авыл интерьерларына чүкеп бизәкләнгән паннолар элү популярлаша.

Бу традицияләрне дәвам итүчеләр сафында бүген металлны сәнгатьчә эшкәртү остасы Александр Ивановны атый алабыз. Ул сәнгать дөньясы белән беренче тапкыр, армиядән кайткач, Түбән Кама химия комбинаты каршында эшләүче танылган рәссам Г.В. Арчуашвили остаханәсендә таныша. Анда ул металл панноларны кул көче белән эретеп кою, коелган өслеккә чокып (төрткеләрдән гыйбарәт, күпертеп, югары рельефлы итеп) рәсем төшерү процессын күзәтеп кенә калмый, ә бу авыр хезмәтне үзе дә өйрәнә. Бу эшнең техник алымнарын ул бер елда үзләштерә, шуннан башлап, менә 40 ел инде А. Иванов ял дими, бәйрәм дими, тәүлегенә 12 сәгать буе эшли. Бакыр паннолар өстендә эшләү өчен өч айдан башлап, ел ярымга кадәр вакыт таләп итела. Бу вакыт эчендә авторның техник чаралардан виртуозларча

файдалануы белән беррәттән, рәсемне, аның композициясен оста итеп сурәтләве дә мөһим роль уйный. Өслеккә чүкеп бизәк төшерү, бер яктан, монументаль характер алса, икенче яктан, динамик пластиканы хәтерләтә.

А. Иванов иҗаты һәр детальнең нәфис эшләнеше белән җәлеп итә. Стилендә рәссам буларак үзенә генә хас сыйфатлары ачыклана, ягъни әсәрләрендә яктырткан «Зодиак тамгасы» сериясеннән «Кучкар» образы аша «Мин кем?» дигән сорауга җавап бирә. «Мин – максатыма ирешү юлында үҗәт бер Кучкармын, мөгеземне төбәп, Марс һәм Кояш яклавы астында алга барам. Туган елым – Аждаһа. Мине Алиһәм һәрвакыт күзәтеп, озатып йөри. Ут юлымны яктырта». Александр Иванов туган көннең йолдызлык тамгаларына чын күңеленнән ышанып, алар кешеләрнең үз-үзен тотышына йогынты ясыйлар, дигән фикердә тора. Шул ук вакытта ул: «тормышта ничек яшисең, язмышың да шулай формалаша. Менә мин җаным-тәнем белән иҗатка бирелдем. Хатыным белән улым кайчагында әрлиләр дә. Чөнки күпләрнең хәзер машиналары, гаражлары бар. Теләсәм, мин дә аларны алган булыр идем, әмма мин алардан баш тарттым. Иҗатыма комачаулар дип уйладым», – дип тә куя.

Иҗатчының әсәрләре күп юнәлешле, әмма аларның һәркайсы халык язмышы белән бәйле. А. Иванов 1985 елда «Куликово сугышы» сериясен эшли. Шул панноларның берсендә рус сугышчысының православие гыйбадәтханәсе фонында көрәшкә әзерләнүе тасвирлана. Рәссам: «Без – чукындырылган татарлар. Өебездә һәрвакыт икона булды, әни аның әйләнәсенә үзе чиккән ак пәрдә элеп куя иде. Авылда чиркәү булмады, беркайчан да гыйбадәтханәгә керергә туры килмәде. Шулай да мин кечкенәдән христиан бәйрәмнәрен яраттым, аңа бөтен авыл әзерләнә иде», – ди. Александр христианнарча «дөрес итеп» яшәргә өйрәткән әбисен рәхмәт хисләре белән искә ала. Ул аңа туксанынчы елларда илдә хөкем сөргән дуамаллык шартларында кешелек сыйфатларын саклап калырга ярдәм иткән. А. Иванов 1994 елда иҗат иткән эшен дә «Дуамаллык» («Безумие» – «Человеческие пороки» сериясеннән) дип атый, һәм анда үзгәртеп кору галәмәтләренең тискәре якларын чагылдыра. Әмма моның белән чикләнми, аны тетрәндергән бер төн аның иҗади юнәлешен дә үзгәртә. А. Иванов шундый төш күрә: янәсе ул туган авылы урамыннан барганда бер өйгә керә, анда озын гына буйлы, ак киемдәге бер карт була. Ул аны армиядә хезмәт иткәндә дә төшендә күргән була. Ул чакта ак киемле бу карт Александрга әтисенең үлгәнен хәбәр итә, ә иртән йокыдан торуына шушы хактагы телеграмманы ала. Ә бу юлы кайгылы кыяфәттәге карт Александрга өйнең уң почмагына – гадәттә икона куелган якка карарга куша. Караса – анда гарәпчә язылган кәгазь битләре ята, шуларның соңгысына «Мөхәммәд пәйгамбәр» дип язылган. Бу төшеннән соң Александр үзенең электән

мөселманнар нәселеннән булуын аңлый. Һәм Болгарга китә, андагы һәйкәлләрне игътибар белән карый һәм үзенең ерак үткәнен күзалларга тырыша. «Татарстан» сериясеннән «Болгар ханлыгы» («Булгарское ханство», 1996) һәм «Шомлы еллар» («Тревожные годы», 1998) әсәрләре шуның йогынтысында иҗат ителә. Автор анда Идел Болгарстаны металл эшләнмәләре өчен хас булган зооморф һәм үсемлекләр мотивларыннан файдалана.

Нәкышьченең чынбарлыкны тагын да киңрәк күзаллавына борынгы болгар чорына караган татар бәетләре һәм хикәятләре сюжетлары да Габдулла Тукай шигърияте кебек үк тәэсир итә. Осталыгы белән шактый танылып өлгергән автор яраткан шагыйре иҗатын «Балачагым әкиятләре» («Сказки моего детства» (2000 елларда) сериясендә гәүдәләндерә. Горизонталь киңлеккә сузылган бакыр паннолар Густав Доренең график сәнгатен хәтерләткән чүкелмә «рәсемнәр» белән бизәлгән. Аларның берсендә кыю авыл егетенең ничек итеп урман пәрие – Шүрәлене җиңеп чыгуы сурәтләнгән. Анда төп персонажлар тирәлегендәге агачлар, әйтерсең, җанланган, алар ыргак сыман бөгелгән ботакларын җилпиләр. Кәүсәләр арасыннан бу күренешкә гаҗәпләнгән кеше йөзләре карап тора. Хәтта урман җәнлекләре куркып калган. Ерткыч кошлар да көрәшнең азагын ләззәтләнеп көтәләр. Куркыныч көч белән «бил алышу»га күтәрелгән Батыр үзенең дошманы каршына баскан. Әкияти коточкыч зат образы махсус рәвештә чиктән тыш озын куллы итеп сурәтләнгән. Аның зур-зур «агач бармаклары» егетне эләктереп алырга үрелгән. Александр Ивановның күңелендә әтисенең: «Куркуга бирешмә, батыр кебек кыю бул!» дигән сүзләре саклана. Татар авылларында мондый сүзләрне балаларына һәр гаиләдә әйтәләр. Шулай ук «Су анасы» экиятендә малайга аның әнисе әйткән сүзләр дә еш кабатлана. А. Иванов панносында бакага охшаган Су анасы озын чәчләрен алтын сыман ялтырап торган тарак белән тарый. Ул композициянең үзәк өлешен тәшкил иткән күл өслегендә, калкып торган басмада тамашачыга таба йөзе белән урнаштырылган. Рәссам җәйге аяз көндә күлдә яшәүчеләрнең тыныч кына үз эшләре белән мәшгуль булуларын оста итеп сурәтләүгә ирешкән. Ерактарак – авыл күренеше. Куркудан агачлар артына яшеренеп, басма өстен күзәтүче малайның аркасы күренеп тора. Бу күренеш аны бөтенләй әсир иткән, ул һич кенә дә китә алмый. Әсәрдә гөнаһ һәм намус капма-каршылыгы зур урын били. Авторга, барыннан да бигрәк, вакыйганың ничек тәмамлануы мөһим. Бу аның «Кәҗә белән сарык» экиятен гәүдәләндерүендә дә чагылыш таба: картаеп тешләре коелыган йорт хайваннары һәм аларны хәзер ашап ташларга җыенган ерткычлар «йөзгә йөз» сурәтләнгән. А. Иванов тормыш тәҗрибәсе һәм зирәк акылның ахмак көчләрне җиңеп чыгачагына тамашачыны да ышандыра. Бу күренешнең сүзсез шаһитләре рәвешендә

композициядә карт хуҗалар, мифик кошлар һәм арысланнар да урын алган. «Балачагым әкиятләре» сериясендәге һәр әсәрдә композицияне үсемлек-чәчәк орнаментлары бизи. Яфрак һәм чәчәк бөреләре ирекле урнаштырылган сабакларны тоташтан үрмәләтеп бирүе белән автор тормыш чылбырының өзлексез дәвам итүен символлаштыра. Андый бизәкләрне татар чигүчеләре еш кына сөлгеләргә, тәрәзә пәрдәләренә, кашагаларга төшерәләр. Александр Иванов туган йортта да мондый үзенчәлекле бизәлеш гадәти хәл була. Өй эчендә кулланыла торган тукымалардагы, Габдулла Тукай әкиятләрендә тасвирланганча, җете ачык төсләр белән чигелгән чәчәкләр балачактан аңына сеңеп калган.

Нәкышьче Александр Иванов туган ягына һәм татар мәдәниятенә булган мәхәббәтен панноларга чүкеп ясалган образлары белән мәңгеләштерә, ул аларда, милли тәңгәллекне берләштергән этик һәм эстетик нормаларны төгәл үтәве белән, үзенең иҗади мөмкинлекләрен раслый.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# АСЫЛ ТАМЫРЛАРНЫ БАРЛАГАНДА...

*(Фольклорчы галим Х. Мәхмүтовка – 85 яшь)*

Статья приурочена 85-летнему юбилею выдающегося учёного-фольклориста, доктора филологических наук, профессора Х.Ш. Махмутова. Его многочисленные исследования в области устного народного творчества по сегодняшний день находятся в действующем арсенале многонациональной российской науки.

**Ключевые слова.** Х. Махмутов, фольклористика, монография, исследования, изучение древнего слоя фольклора, афористический, татарский фольклор, устное народное творчество.

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Хуҗиәхмәт Мәхмүтов – безнең арабызда үзенең яше белән дә, башкарган эшләре белән дә олуг ихтирамга лаек шәхесләренең берсе. 2018 елның 15 февралендә 85 яшьлек зур юбилеен билгеләүче аксакал галим гомеренең алты дистә елдан артыграгы чын мәгънәсендә фидакяр фәнни-педагогик эшчәнлектән гыйбарәт.

Татар милләтенә Хуҗиәхмәт аганы халкыбызның җыргамоңга, күркәм гореф-гадәтләргә ифрат бай вә гүзәл табигатьле Мамадыш төбәге биргән. Ул 1933 елның 15 февралендә Түбән Ушмы авылында дөньяга килгән, шушында җидееллык, ә район үзәге Мамадыш шәһәрендә урта мәктәп тәмамлаган. Булачак галим үзенең хезмәт юлын да туган җирендә башлый. Өлгергәнлек аттестаты алгач, ике ел Көек Ерыкса җидееллык мәктәбендә математика һәм физика укыта.

Тырышлыгы, белемгә омтылучанлыгы тиздән аны мәркәзебез Казанга, университетның тарих-филология факультетына алып килә. Татар телен, әдәбиятын, тарихын максатчан өйрәнеп, яшьтән үк төп игътибарын халыкның рухи хәзинәләренә юнәлткән җитди холыклы егет 1958 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый.

Озын хезмәт юлының 50 елга якыны гел бер урын – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйләнгән. Ул әле студент елларында ук, вакытлы хезмәткәр сыйфатында, әлеге Институт оештырган фольклор экспедицияләрендә катнаша, андагы галимнәр белән берлектә халык җәүһәрләрен җыю, туплау белән шөгыльләнә башлый.

Университетны тәмамлап, елдан артык шушы абруйлы уку йортының татар теле һәм

әдәбияты кафедрасында өлкән лаборант, соңрак Буа районының «Яңа юл» газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркятиб, бүлек мөдире вазифаларын башкарып, шактый хезмәт тәҗрибәсе туплагач, 1966 елда Х. Мәхмүтов Тел, әдәбият һәм тарих институтына (хәзер Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә) янә әйләнеп кайта. Халык иҗатына мәхәббәте, хикмәтле фольклор дөньясындагы бетмәс-төкәнмәс рухи байлык белән кызыксынуы аны Институтның халык иҗаты бүлегенә бәйли. Биредә ул аспиранттан алып баш фәнни хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтә, «Татар халык табышмаклары» дигән темага кандидатлык, халкыбызның афористик иҗатына багышлап, докторлык диссертациясе яклый. Ул 1970 елдан Институтның Гыйльми советы әгъзасы, 1981 елдан – диссертацияләр яклау советы әгъзасы. Байтак еллар биредә профсоюз һәм партия оешмаларын җитәкләгән, Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре профсоюзының VII съездында делегат булып катнашкан.

Институтта эшләү дәверендә галим татарлар яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган күпсанлы фәнни экспедицияләрдә катнаша, үз замандашларыннан халык авыз иҗатын бөртекләп җыеп, аларны тәртипкә китереп, җыентыклар төзи, матбугатта бастырып чыгара. Х. Мәхмүтов – 30 китап, меңгә якын мәкалә авторы. Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган 13 томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасын әзерләүдә аның өлеше зур. Ул бу фундаменталь басманың редколлегия әгъзасы, биш томының фәнни мөхәррире, «Табышмаклар», «Мәзәкләр», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» томнарын төзүче, аларга кереш мәкалә һәм фәнни искәрмәләр язучы.

Борынгы ядкәрләребездә теркәлеп калган рухи кыйммәтләрне барлап, фәнни монографияләр чыгару – галим эшчәнлегенең аеруча әһәмиятле биеклеге. Ул бик күптәнге чорларга караган мәкаль-әйтемнәрне һәм башка афоризмнарны җентекле өйрәнә, аларның бүгенге көнгәчә үсеш-үзгәрешен күзәтеп, тирән анализлый, бу төр әсәрләрнең асыл хикмәтен, нәзберек шигърияте нечкә тоемлап яза. Х. Мәхмүтовның «Мәңгелек ядкәр» (2002), «Борынгылар әйткән сүзләр» (2002) кебек монографияләре – шушы өлкәне колачлый торган зур хезмәтләр. Болардан тыш, татар халкының фольклор мирасын ачуга галимнең уннарча саллы мәкаләләре багышланган. Мондый характердагы тикшеренүләре төрле хрестоматия һәм фәнни җыентыкларга кертелгән.

Табышмакларның жанр үзенчәлеген өйрәнүгә багышланган «Кечкенә дә төш кенә» (1980), халык календаре серләренә төшендерә торган «Ел тәүлеге – 12 ай» (1991), фольклорда әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышланган «Язылмаган кануннар» (1995), халык сөйләмендә очрый торган сүз-гыйбарәләрнең хикмәтен, тарихын, нинди уңай белән әйтелүен тәфсилле аңлатып-төшендереп, сүз эченә яшерелгән

энҗе бөртеген күрсәтеп бирә торган «Канатлы сүз – хикмәтле сүз» (1999), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008), «Изге китаплар кайтавазы» (2012) кебек китаплары фәнни-теоретик яктан да, киң катлам укучыларның гамәли ихтыяҗын истә тотып язылган булуы белән дә гаять әһәмиятле. Галимнең тырышлыгы, иҗат мөмкинлекләре һәм язу куәсе һәркемне сокландырырлык: аның каләменә гыйльми дә, үтемле һәм кызыклы да итеп язу сыйфаты хас.

Х. Мәхмүтовның хезмәтләре арасында әле алда телгә алынмый калганнары да шактый. Монографияләрдән башка, ул – «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр: ике томда» (1974, 1975), «Татар фольклоры жанрлары» (1978), «Татар фольклорында социаль мотивлар» (1986), «Поэтика татарского фольклора» (1991), «ХХ гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат» (2001), «Хәмит Ярми: галим һәм шәхес» (2004), «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр» (3нче том, 2005), «Халык җырчысы Абдулла Кротов» (2010) һ.б. җыентыкларның я җитәкчесе, я төзүчесе-мөхәррире, я төп авторларыннан берсе. «Энҗе чәчтем – энҗе җыям» дигән гомуми исем белән мәктәп-гимназияләр өчен татар халык иҗатыннан уку ярдәмлеге буларак чыгарылган 9 китапның дүртесе шулай ук аның тарафыннан әзерләнгән.

Галим буларак, Х. Мәхмүтовның эшчәнлеге күп еллар дәвамында фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясау һәм яшь галимнәргә гыйльми юнәлеш бирү белән тыгыз аралашып бара. Казан, Новгород, Тбилиси, Алматы, Бишкәк, Анкара һ. б. шәһәрләрдә уздырылган халыкара конференцияләрдә ул укыган докладлар җитди фикерле булулары белән игътибарны җәлеп итә. Галим җитәкчелегендә 2 докторлык, 5 кандидатлык диссертациясе якланган. Ул ун ел дәвамында Казанның филология профильле югары уку йортларында (ул еллардагы исеме белән телгә алганда – КДУ, КДПУ һ.б.) Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе булып эшләде.

Галим үзенең басма хезмәтләре, фәнни конференцияләрдә һәм матбугаттагы даими чыгышлары белән татар дөньясына күптән таныш. 1970 еллардан бирле аның исеме милләттәшләребезгә «Тел күрке – сүз» радиотапшырулары аша даирешеп торды.

Х. Мәхмүтовның киңкырлы гыйльми, әдәби, публицистик һәм педагоглык эшчәнлеге, алда саналган мактаулы исемнәрдән тыш, Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты, «Хезмәт ветераны», «Казанның 1000 еллыгы истәлеге», «Фидакяр хезмәт өчен» медальләре, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы президиумының, Татарстан Фәннәр академиясенең, Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре профсоюзының Республика комитеты (РСФСР) Президиумы Мактау грамоталары, Татарстан Президенты

Р.Н. Миңнехановның «Рәхмәт сүзе» белән бәяләнгән.

Хуҗиәхмәт аганың иҗаты, фәнни хезмәтләре, кылган гамәле, тапкыр сүзе, хәтта кайбер очракларда дәшми калуының тирән мәгънәгә ия булуы хакында гына да озак сөйләргә мөмкин. Яшәешенең төп мәгънәсен халык иҗатын барлауда, өйрәнүдә күргән асыл зат ул. Халкыбызның ерак үткәненә багып, бик тирәннән җәүһәрләр табуы, аларны өскә күтәреп, кабат балкыта алуы галимнең гомерен мәгънәле иткән.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 82-94

***Гаяз Исхакый***

# ЯПОНИЯДӘН КИТЕП БАРЫШЛЫЙ

*(әдип көндәлегеннән)*

При содействии организатора фонда «Аяз Тахир (Туркестан – Идель-Урал)» доктора Тулей Дурана из Турции на историческую родину было возвращено богатое письменное наследие классика татарской литературы Гаяза Исхаки. Часть этого наследия в настоящее время хранится в ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Среди этих материалов большое значение имеют электронные копии личных дневников писателя, которые он вел в период с 1919 по 1953 гг. Гаяз Исхаки в 1919 году, будучи делегатом Версальской конференции, выезжает через Дальний Восток в Европу, где и остается до конца своей жизни. В этих дневниках раскрыта тяжелая жизнь в эмиграции, выпавшая на долю Г. Исхаки.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Г. Терегулов, Ф. Туктаров, Учредительное собрание, Япония, Китай.

*1919 ел, 1 нче июль.*

Бүген Солых бәйрәме. Бөтен урам автомобиль берлән тулган. Һәммәсе дә төрле-төрле иттифакъчыларның байраклары берлән зиннәтләнгәнләр. Японча-инглизчә шигарьләр язганлар, урам тулы халык. Һәммәсе солых булганга шадлыкларын белдермәкче булалар. Диңгездәге япон крейсеры бер туктамаенча ата. Ләкин рух алай ук түгел. Һәр кешенең йөзендә шул солыхга бер ышанмау чыкган. Барысының да йөзенә бар да йөрегәч, без дә йөримез дигән мөһер басылган. Без дә урамга тамаша карарга чыкганда, урамда бик күп чех солдаты очратамыз, сорашамыз. Владивостокдан икән. Анда, дүртенче эшелонда, безнең якын танышымыз, Учредительное собрание әгъзасы, комитетның мәгариф нәзары булып торган Егор Егорович Лазарев[1] булырга кирәк иде. Чехлардан бармы, дип сорыймыз. Бар, дип җавап бирәләр. Кызулатып пристаньгә китәмез. Әллә никадәр чехдан сорашамыз. Кайсы бар, ди, кайсы юк, ди. Берсендән чакыртырга җибәрәмез, ләкин, юк, чыгып киткән, диләр. Без Йокоһаманың урамы буе эзләп таба алмагач, сәгать өчкә килермез дип, хат биреп китәмез. Безнең аны күрәсемез килүнең мәгънәсе бар. Чөнки алар бара торган пароход Америкага бара. Әгәр безне дә алса, мәсьәлә хәл ителгән була. Егор Егорович Харбинда вакытда безгә шулай барырга тәкъдим дә иткәнлеге, без ул вакытда үземезнең кәгазьләремезгә ышанып, бик соңга калачак дип, кабул итмәгән идек. Хәзер аны очрата алсак, бик кабул итү ягында. Сәгать өчдә тагын барамыз, җидегә

[1] Лазарев Е.Е. (1855–1937, тәхәллүсе – Бровинский,) – революционер, эсер, Учредительный собраниегә делегат итеп сайланган.

кадәр көтәмез. Һаман юк да юк. Ахырдан аның анда булмавы, пароходда комитетның икенче әгъзасы Брушвитның[1] гына булуы мәгълүм була. Аны күрергә тырышамыз. Ул да тугры килми. Иртә күрергә булып китәмез. Кичкә безгә Иван, Вафа һәм дә Окубо[2] күрешергә киләләр.

Бүген рамазан бәйрәменең өченче көне булса да, без бер әрмән, бер япон, бер төрек компаниясендә бәйрәм итәмез. Өченче көнгә иртәнге поездга билет алырга куштык. Бүген кичке телеграммада кытайларның солых могаһәдәсенә *(килешүенә)* кул куймаулары мәгълүм булды. Кытайның Токиодагы сәфире Токио шәһәр башлыгы тарафыннан бирелгән зыяфәткә дә килмәгән. Кытай – истикъляли *(бәйсез)* милләт. Киләчәкдә шәрыкдә зур роль уйнаячак.

*2 нче июль.*

Бүген озак йөрегәндән соң, Гомәр[3] чехлар пароходындагы кешеләрне күреп кайтды. Болар берсе Брушвит, икенчесе Климушкин[4] икән. Болар – Учредительное собрание комитетында зур роль уйнаган затлар. Хәзер чех булып, солдат киемендә, солдат боткасын ашап, Америкага качып китеп баралар... Без иртәгә китә алмыймыз, чөнки билет булмады.

*3 нче июль.*

Бүген вак-төяк әйберләр алгалап үткәрдек. Иртәгегә билет алдык. Насыйп булса, китәмез. Бүген акча курсы төшде. Себер акчасын бөтенләй алмыйлар. Омскида тагы үзгәреш бар, диләр. Колчак[5] берлән Дутов[6] тартыша имеш. Ни булса да, Колчакның вәзгыяте бик начарлана булырга кирәк.

*4 нче июль.*

Бүген, иртүк торып, поездга китдек. Поездымыз 9 сәгать дә җиде минутда Йокоһама стансасындан китде. Бик кызу бара. Болай барганда, иртәгә иртәнге пароходка барып җитәчәк. Көн бик бөркү, шуның өстенә, бик ягмурлы. Монда әллә нинди үзенә махсус йылы, вак ягмур ява. Болыт шулкадәр түбән, кул сузсаң, җитәчәк. Поезд тау буйлап барганда, тауның итәгенә китә торган башына менеп җитмәгән бик күп болыт агымларына очрыймыз. Бер йирдә, тау өстенәрәк менгәч, поездымыз ярты сәгать чамасы болыт эчендә бара. Көн шулкадәр бөркү, вагонда суга батып барамыз. Кичкә таба сәгать җиделәрдә безгә японча әллә нәрсә килеп сөйлиләр, ләкин без аңламыймыз. Бераздан безгә бер инглиз: «Поезд бара алмый, юлны ягмур юган, шуның өчен, теләсәгез, Кобеда каласыз,

---

[1] Брушвит И.М. (1879–1946) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы.
[2] Окубо Кочи – Комазава университеты профессоры, тюрколог.
[3] Гомәр Терегулов (1883–1938) – сәяси эшлекле, педагог.
[4] Климушкин П.Д. (1886–1969) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы.
[5] Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), патша Россиясе хәрби эшлеклесе.
[6] Дутов – Александр Ильич Дутов (1864–1921) – атаман, генерал-лейтенант.

теләсәгез, андан ике сәгатьлек йирдә Окаямага да туктыйсыз. Әүвәлгесе зур шәһәр булганга, номерлар-отельләр күп, икенчесе япон шәһәре генә, Яурупада отельләр юк», – ди. Без, төрле-төрле уйлагандан соң, Окаямага барырга буламыз. Кызу, ягмур астында сәгать төнге 12 ярымда Окаямага төшәмез. Вокзалда һичбер төрле русча белгән юк. Шалтыр-полтыр белгәнемез берлән инглизчә сөальләр бирәмез, аңарга японча җавап бирәләр. Ахырдан бер түрәгә бераз инглизчә сөйләп аңлатамыз. Юлымызны өч йирдән ягмур юган, поезд Симоносекига бара алмый, ләкин иртәгә таң берлән сәгать биш дә пароход Симоносекига китә, шулай булгач, без вокзалда гына көтәргә буламыз. Сәгать бишкә кадәр көтәмез, алтынчы була, тагы сорыймыз. Поезд сәгать унда китәчәк, пароход юк, диләр. Аңарга ышанмыйча, икенчесендән сорыймыз. Поезд сәгать дүртдә китәчәк, ди. Шундан соң, боларның сүзләренә өмет юклыгын күреп, тагын белешергә тырышамыз. Поездның кай вакыт китәчәге мәгълүм түгел, дип игълан иткән сүзне белгәч, номер эзләргә тотынамыз. Ерак түгел бер япон өе табып, шунда керәмез. Камыш намазлык, бүлмәнең идәненә урын салалар. Баш астымызга озынча йомры мендәрләр бирәләр. Пальтоларымыз берлән йокларга ятамыз. Сәгать унларда торып, тагы белешергә китәмез. Тагы кырык төрле хәбәр. Берсе кич сәгать җидедә китә, ди. Берсе сәгать унда, ди, сәгать унбердә, ди. Бер ресторанга кереп, чәй эчәргә утырамыз. Йомырка, күмәч, май, чәй сорыймыз. Элгәре май китерә. Андан чирек сәгатьдән йомырка китерә. Андан чирек сәгатьдән әллә нинди соры бер су китерә. Андан чирек сәгатьдән икмәк. Моңарга ачу килеп, йөдәп беткәч, үземез барып күрсәтеп, тагы белешергә китәмез. Анда беразрак русча белә торган япон офицерына очрыймыз. Ул юл бик нык бозылган, ягмур һич туктамый. Поезд өч-дүрт көнсез төшәчәк түгел, ди. Сәгать өч ярымда Кобега китәмез. Көн буе ягмур ява. Поездымыз бер туктамаенча су диңгезендән йөзә. Уң як, сул як су берлән капланган. Күкдән ягмур чиләкләп актарыла. Дөге кырлары су эчендә. Иң зур дөге саплары да күренми. Сәгать сигездә Кобега[1] киләмез. Билетсыз йөдәп бетеп, бер нәрсә эшли алмагач, бер япон номерына китәмез. Ашаганымыз-эчкәнемез юк. Өстемез башдан-аяк су, тир эчендә үземез. Чәй һәм йомырка китерергә кушамыз. Ике сәгатьдән соң йомырка, былчырак чәй эчеп ятып йоклыймыз.

*6 нчы июль.*

Бүген иртүк торып юынганның соңында пароход мәсьәләсенә керешәмез. Русча белә торган япон вәгъдәсенә килми. Аны бик тынычсызланып көткәннең соңында, ике сәгать кичегеп килә, пароход сәгать уникедә китә, ләкин икенче классда да, беренче классда да урын юк, фәкать өченчедә генә бар.

[1] Симоносеки, Кобе, Окаяма – Япониядәге шәһәрләр.

Дүртенчедә булса да ярый, ал гына. Бездән билет акчасы алалар, биш мәртәбә артык хак алганлар. Пароходка кереп утырамыз. Урыныбыз иң аскы катда, трюмда. Анда биниһая эссе. Эчәргә сорыймыз, бирмиләр...

Менә кич. Ай моңлы гына яктысы берлән диңгезне сөя. Диңгезнең төбендәге яшерен хәятләрен, диңгезнең эчендәге серләрен укымакчы була. Пароход әйтеп бетермәслек муллыкны ертып, һаваланып, йокларга яткан диңгезне ерып алга таба бара...

Төнемезне капитандан камыш намазлыклар сорап алып, баш астымызга пальтоларны салып йокларга ятамыз. Ике якдагы ачык тәрәзәләрдән диңгез һавасы безне сөя-сөя йоклата. Әнә таң сызылып килә. Диңгезнең әнә теге очында зур куәтле бер кызыл нәрсә чыгарга теләп маташа.

Берничә карт япон чыкканлар да кояш чыгышка карап басканлар. Күзләре кояш чыгышына текәлгәнләр. [...] дип кычкыралар да, кулларын берсенә-берсен борып, шарт иткән тавыш чыгаралар, андан әллә нинди сүзләр мыгырдыйлар. Шул эш берничә мәртәбә кабатлана да, куллары берлән йөзләрен сыйпап, борылып китәләр. Болар кояшка гыйбадәт итәләр. Безнең элекке төрк бабайлар кояшка ничек гыйбадәт иткән булсалар, болар да шулай гыйбадәт итәләр.

Юынырга төшәм. Юыну бүлмәсе ир-хатын берлән шыгрым тулган. Хатынлар һәммәсе дә билләренә кадәр бөтенләй ачканлар, тәнләрен акшарлыйлар. Ирләре дә шулай. Берсе-берсенә карамыйлар да, илтифат да итми. Мин боларның шул гадәтләренә, шул безнең канга сеңгән «оят», «оят булу» дигән мәгънәнең булмавына гаҗәпкә калам. Мин күлмәкләрне салмаенча гына юынырга керәм...

Пароход өстенә чыгам... Мин диңгез авыруындан курыкмаганга, пароход өстендә калдым. Бик күп кеше. Безнең пароход бик кечкенә булганга, дулкын бик куәтле булганга, ул тирбәнә, кайвакыт бөтенләй дулкын астында кала кебек була. Дулкынлар пароход өстенә менеп, йөгереп төшәләр. Мин һаман бер почмакдарак коры калып барам. Менә бер дулкын икенчесен куып җитде, алар бер-берсен кочаклап, мине су башымдан аягыма кадәр коендырды. Астымдагы урындык шуып китде. Мин суга батып, бүлмәгә кереп, урынга ятдым, юрган ябындым.

Урынга бик вакытлы килеп төшәмез.

*8 нче июль.*

Бүген иртәдән бирле без Корея буйлап барамыз. Кыр тулган халык. Һәммәсе без үле күргән кебек ак киемдән. Кырда эшли торган ирләрнең барысы да билгә кадәр бөтенләй ялангач. Хатынлар тәмам ук ялангач булмаса да, күп йирләре ачылган. Балалары да япа-ялангач. Кырдагы эшнең хәзергесе дөге сугару, икенчесе аны утау һәм дә төбен йомшарту. Ирләр төрле ысулда кораллар берлән үзләренең җыйнаган чүпләрен дөге түтәлләре эченә куялар, хатынлар тездән су эчендә дөге утыйлар, төпләрен йомшарталар. Монда әле урып бетмәгән бодай берлән солы

очраштыргалый. Көн буе шул бер төрле эш. Мескенләр, тамак туйдырыр өчен бик зур мәшәкатьләргә күрергә мәҗбүрләр...

*10 нчы июль.*

Без кичә кич берлән Чанчуньга[1] килеп җитдек. Монда безне көтеп торалар икән. Безне чакырган мәсьәләләре бик кечкенә вакыйга, сәяси тәрбиясезлекдән килеп чыккан бернәрсә генә булды. Аны ни дип тә тәгъбир итәр хәл юк. Кыскасы, мондан гыйбарәт: Нияз әфәнде үз эше берлән барганда, аны Семенов[2] берлән күрешдергәнләр. Семенов безнең мөселман эшләре берлән бик танышасы килә һәм дә безнең берлән мөнәсәбәткә керешеп, мөмкин булса, бергә хәрәкәт итәсе килә икән. Себер мөселманлары, Кытай мөселманлары хакында бергәләшеп бер эш эшләп булмасмы, дип уйлый икән. Шуңарга күрә безне күреп сөйләшәсе килә икән. Шуның өчен Нияз әфәндегә безнең берлә барып сөйләшергә әйткән һәм дә юлына акча да биргән. Сөйли торгач, эшнең артында японлар да барлыгы мәгълүм була. Без мәсьәләне мөзакәрәгә куеп, карарлар ясыймыз: беренче, Семенов берлән мөзакәрәгә керешергә ярый. Милли сәясәтне йөрткәндә, ноктаи нәзар фәкать милләтнең мәнфәгате генә булырга кирәк. Шул милли мәнфәгать өчен тартышуда кем ярдәм итсә дә, шул ярый. Сөйләшәчәк мәсьәлә мондан гыйбарәт: Семеновның сәяси даирәсендә безгә бер шәһәр бирелсен, шунда без үземезгә махсус төрк-татар гаскәре төзик. Семенов шул хәрәкәтемездә безгә ярдәм итсен һәм дә безнең мөшкилятемез фәкать шул үземезнең милли эшемез өчен генә тотылсын. Шул мәсьәләләр хакында Семенов берлән фикер алышырга без разый. Шундан соң хәзер үк Семенов берлән барып сөйләшү кирәкме, бераз соңракмы мәсьәләсе куелды. Ул мәсьәлә безнең солых сәфәремезгә барып төртелә. Безнең солых сәфәремез алты ай дәвам иткәннең соңында Япониянең диңгезенә терәлде...

*11 нче июль.*

Минем Окаямада калган чемоданларым бүген килде. Эчендә бик күп әйбер бар һәм дә яңлыш куелып калган уналты мең сум акча да бар иде. Һәммәсе саусәламәт килделәр. Японлар бу хасиятләрне тәкьдир кылмаска мөмкин түгел. Көн буе теге мөзакәрәләр дәвам итде. Ахырдан Нияз әфәнде Кытай эченә барып кайтырга, Габдулла берлән хәзрәт китәргә дә безгә кеше эзләргә, безгә Чанчуньда көтеп торырга булдылар.

*13 нче июль.*

Бүген бер ни дә булмады. Кызулыкдан, тузандан йончып, өйдә ятдык. Монда тору бик мәгънәсез. Һавасы начар. Кешесе юк. Эш юк...

Гомумән, эш, җәмәгатьнең иштираке берлән булмаганда,

---

[1] Чанчунь – Кытайның Гирин провинциясендәге шәһәр.

[2] Семенов Григорий Михайлович (1890–1946) – атаман, генерал-лейтенант.

бер ни чыкмый. Кечкенә генә бер мисал. Инглиз матбугатына бирер өчен русчадан мәкаләне инглизчәгә тәрҗемә итдергән идек. Шуны карап мәкалә ясап чыгарга Габдулла Газиздән үтендек. Шул ике сәгатьлек эш эшләмәде. Инглизчә белә торган кешеләремез бер-ике данә булып, алары да шулай милли саботаж ясаганда,ничек эшләргә кирәк.

*14 нче июль.*

Бер ни юк. Бераз ягмур яуды да, һавалар матураеп китде. Бүген газета да юк. Кичәге хәбәргә караганда, большевиклар Екатеринбургка һөҗүм итәләр.

*15 нче июль.*

Бүген иртүк Әмрулладан[1] мәктүб алдык. Шимбә көн киләм дигән. Шуңарга күрә, аны шактый озак көтәргә тугры киләчәк. Монда һичбер эш юк. Безнең бу сәфәрнең ундан тугызы көтәргә китде. Хат көт, җавап көт, телеграмма көт, иптәшләрне көт. Монда бүген бик зур тантана берлән Гириндан[2] Кытайның зур бер түрәсе килде. Аны каршы алырга бөтен гаскәре җыелган. Вокзал башына гаскәре караул куелган иде. Арбасына утырып мәйданга чыгуга атлы гаскәр бик күп сыбызгыдан кычкырта башладылар. Зур тавыш кубды. Миңа кечкенә вакытымда яңа сыбызгылар тотып, дәүрәк малайлар берлән сабан туендан кайтканны хәтерләтде. Бу арада Гирин губернаторы берлән Мукден губернаторларының аралары ачылып тора. Икесе дә Маньчжуриягә генерал губернатор булырга тырышалар. Бу эшне хөкүмәтләре берлән аңлашып эшләп булмый күрәсең. Ике губернатор да берсе-берсе берлән сугышмыйча мәсьәләне хәл кылырга уйлаганлар. Гирин губернаторы Япониягә бик күп йир саткан. Гомумән, Япония берлән эш итде, шуңарга күрә Кытай үзен яратмый, ди. Мукден губернаторын халык ярата, ди. Кыскасы гына, боларның берсе Кытайның истикъялен саклау тарафында булып, Япониягә дошман, берсе Япония берлән эш күрү тарафында булырга. Ике агым тартыша-тартыша сугышка барып җитәләр булырга кирәк. Гирин губернаторы җиңсә дә, Мукден губернаторы җиңсә дә, Япония шул сугышындан файдаланып, бармагын зурраграк тыгачак, бәлки Маньчжуриянең аерым бер дәүләт булуына эш җиткерәчәк. Бакалым, ни булыр...

*16 июль.*

Бүген яңа бер эш дә юк. Мәктүб булмагач, кичә үзем язып җибәрдем. Бу мәгънәсез көтү бик туйдырды. Бүген хисапларны карадым, әле расход бик аз тотылган. Шул акчалар берлән бик һәйбәтләп йөреп кереп булчак да бит, расходымызның очы-кырые булмады. Андан соң һичбер ярдәмче юк. Гомәр салам селкетми. Паспорт булса, Харбинга барып, андан Владивостокга бару уенда торам.

---

[1] Әмрулла Аги – Харбинда мәхәллә җитәкчесе.

[2] Гирин – Кытай провинциясе.

*17 нче июль.*

Бүгеннең иң зур вакыйгасы – большевикларның Златоустны алулары булды. Димәк, большевик Уралның бу ягына чыкды. Хәзер Омскига хәрәкәт башлана.

Көн бик эссе, өйдә утырып булмый. Кырык градусдан артык. Милли идарәне эзләргә вә табып, җавап китерергә бер кеше җибәрергә булган идек, Омскидан Колчак кача башласа, милли идарәне табуы бик авыр булыр кебек күренә. Газеталарга караганда, Омскига чит кешене кертмиләр, димәк анда зур паника башланган.

*18 нче июль.*

Бүген милли идарәгә озын мәгърузә *(доклад)* яздым. Томскида Нурулла Карповка[1], Петропаулда Мостафа Тумашевка озын-озын хатлар берлән мәсьәләне тәмамән ачдым. Һәммәсендән дә берничә соальләргә җаваплар сорадым. Бу мөрәҗәгать берничә мәртәбә булмаса да, бәлки берсендән-берсендән бер җавап килеп чыгар. Мәсьәлә, фәүкыльгадә, чуалчык дәвергә керде. Булмады дип эшне туктатсак, вөҗдан канәгатьләнми, дәвам итдерергә дип карар итсәк, ялгыз бер кеше һичбер бер ярдәмсез шул кадәр мөшкилят эчендә ни эшләмәкче буласың. Әгәр заграницага чыгып киткән бер-ике кешемез булса, әлбәттә, шуларга телеграмма, мәктүб берлән эшне аңлатып, алардан эшне дәвам итдерергә үтенер идек...

*19 нчы июль*

Бүген мобилизациягә баруның беренче көне. Монда Чанчуньда артык бер нәрсә булмады...

*20 нче июль*

Кичә кичдән яисә бүген иртә берлән Әмрулла әфәнде килергә тиеш иде. Мәктүбе дә, кеше артындан әйткән вәгъдәсе дә шулай иде, ни өчендер килмәде. Һәм дә сәбәпләрен күрсәтеп мәктүб дә булмады. Әллә мобилизация мәсьәләсе манигъ булды, әллә башка эш. Инде аны тагы көтәргә кирәк. Безнең бу хәерсез сәфәремез көтүдән гыйбарәт булып чыкды. Бүген мин авырый башладым. Дөресе, авырыйм дип курыкдым. Тамакга бака калыкды, баш авыртды, ангина була дип шөбһәләндем. Башка эш бетде кебек инде, авырырга гына калды, ди. Бер туктамаенча тамак чайкап торып чыкдым. Кичкә таба бака бетде. Бүген газетада Екатеринбургны алу хәбәрен укыдык.

*21 нче июль.*

Бүген без көн буе Әмрулланы көтдек, ахрысы килми торгандыр. Хәерле булсын. Нияздан хәбәр алдык. Артык хәбәр юк.

*22 нче июль.*

Милли идарәдән мәктүб алдым. Мәктүб 12 нче июльдә генә язылган. Безнең күп мәсьәләләргә җавап биргән кебек – бик күп эшләрне томанда да калдыра. Беренче конференциядә сайланган

---

[1] Нурулла Карпов – Томскида «Том сүзе» газетасы нашире.

эш башы Фуад[1], Солтанбәк[2] әфәнделәрнең килүе мәгълүм түгел. Алар рәсми рөхсәт алырга дип тотынган булганлар да, шуны дәвам итдергәнләре юк, мәгълүм булмаган. Солтанбәк солдатка алынган. Фуады Омскида торадыр, ди. Икенче, безнең виза мәсьәләмез хакында. Анда зур чуалулар чыкган...

Гомәр хакында бер сүз дә юк.

Бу мәктүбдән соң мәсьәлә тагын бераз үзгәрде. Бик күп уңгайсызлыклар бар. Берсе – мин заграничный паспортымның хөкеме югала. Яңадан алу бик авыр мәсьәлә. Бирмәү ихтималлары да бик якын. Бу – бер. Икенчедән, солдатка каралырга кирәк. Солдатка алулары да бик якын, ул вакытда бөтен план пыран-заран килгән була. Шуның өчен боларның берсе дә ярамый. Фәкать качып керергә, аның өчен минем кулымда нинди булса да паспорт булырга кирәк. Миңа Харбиндан җибәрергә вәгъдә иткән булсалар да, ул да килмәгән. Качып-посып чыгарга маташырга, ләкин бу вакытда тотсалар, зур күңелсезлекләр булу ихтималы бар. Ләкин мондый вакытда куркып торсаң, бер нәрсә чыкмый. Аллага тапшырырга, хәрәкәт итәргә...

*Текстны басмага әзерләде:*
***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

---

[1] Фуад Туктаров – Фуад Фәссах улы Туктаров (1880–1938) – журналист, язучы, сәясәтче.

[2] Солтанбәк – Солтанбәк Мәмлиев, Петроград Эшче-солдат депутатлар советының әгъзасы.

УДК 82-95

***Альберт Фәтхи***

# ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ ШИГЫРЬЛӘРЕ ҖЫЕНТЫГЫ

В настоящей статье представлено научное исследование известного археографа и библиографа Альберта Саитовича Фатхиева (1937–1992), написанное по поводу выхода в свет сборника стихов Габдельджаббара Кандалыя (1960). Сокращенный вариант данной работы был издан в 1961 г. в журнале «Совет әдәбияты», полный текст научной статьи публикуется впервые.

**Ключевые слова:** Альберт Фатхи, татарская литература, Габдельджаббар Кандалый, рукописи.

## Кереш сүз

Татар тарихына кагылышлы яңа материаллар эзләү һәм билгеле булган фактларга таянып яңа концепциялар тәкъдим итү, халкыбыз мирасын өйрәнү һәм аның тарихын барлау да иң мөһим бурычларыбызның берсе булып кала. Ни өчен дигәндә, вакыт үтү белән өлкән коллегаларыбызның архивлары да бәһасыз милли мирасның кадерле һәм аермасыз өлешенә әверелеп бара. Белгәнебезчә, күп кенә җитди язмалар үз вакытында фәнни мәйданга чыкмыйча архивларда ята. Бигрәк тә совет заманында төрле-төрле сәбәпләр аркасында шактый гына китап-мәкаләләр басылмыйча, татар фәненең үсешенә үз өлешен кертә алмаганнар. Алар арасында Габдрахман Таһирҗановның Ленинград университеты фарсы кулъязмалар тасвирламасы, Җәүдәт Алмазның «Кыссайи Йосыф» дигән тәнкыйди тексты һәм Зәйнәп Максудованың биобиблиографик белешмәсе кебек фундаменталь хезмәтләр һаман да дөнья күрә алмыйлар. Мөхтәрәм археограф Альберт Фәтхинең дә фәнни язмалары шул исәптән.

Галимнең тәрҗемәи хәле һәм фәнни эшчәнлеге берникадәр яктыртылды инде[1]. Шулай да, Альберт Фәтхи калдырган бихисап фәнни язмаларның әһәмияте әле тиешенчә танылмый. Минем фикеремчә, галимнең архивы белән тирәнтен танышмыйча, Казан дәүләт университының китапханәсендәге Көнчыгыш секторында саклана торган кулъязмаларны тулаем аңлап бетереп булмый. Фәтхинең бай тәҗрибәсенә таянып, аңа ышанып, ул күрсәткән юл белән Көнчыгыш секторындагы коллекцияне өйрәнүне дәвам итәр-

[1] Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төзүче Р. Мәрданов. Казан: Тамга, 2007; *Ахунов А.* Тропинка к книге: Археограф и библиограф Альберт Фатхи // Казань. 1999. № 12. С. 77–78; *Бостанов Ә.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 112–126; *Госманов М.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 46–55.

гә тиешбез, югыйса без Альберт Фәтхи эшләгән эшне кабат башкарырга мәҗбүр булабыз.

Түбәндә тәкъдим ителгән мәкаләдә Альберт Фәтхинең эшләү рәвеше, аның фәнни тел үзенчәлекләре һәм карашлары яктыртыла. Аның башка күптөрле язмалары кебек, бу мәкаләнең дә язмышы бик аяныч. Автор, 1960 елда ук, Хатип Госман һәм Җәүдәт Алмаз тарафыннан бастырылган Габделҗәббар Кандалый шигырьләр җыентыгына рецензия шәкелендә бер язма әзерли. Аның Фәтхи архивында берничә кулъязма һәм машинкада җыелган нөсхәсе билгеле. Нәтиҗәдә, бу текст, гади бер рецензия форматыннан үсеп, бай эчтәлекле, мөстәкыйль фәнни хезмәткә әверелде. Безгә мәгълүм булмаган сәбәпләр аркасында, ни кызганыч, тулы текст беркайчан да нәшер ителмәде. Нәтиҗәдә, Фәтхинең тәнкыйди мәкаләсе өч битлек язмага сыйдырылып, кыскартылып бирелде[1].

Галимнең архивында табылган мәкалә[2] ул бастырган кулъязма тасвирламаларында берникадәр чагылыш тапса да[3], аның тулы текстын басмага чыгару гаделлеккә туры килер иде, чөнки Габделҗәббар Кандалыйның соңрак чыккан шигырьләр мәҗмугасында да[4], шулай ук шагыйрьгә багышлаган махсус мәкаләләр җыентыгында да[5] [Габдельджаббар Кандалый...] Альберт Фәтхи керткән өлеш һәм аның табышлары искә алынмый.

*Әлфрид Бостанов*

Соңгы елларда элекке әдәбиятыбызның идея-художество кыйммәтенә ия булган истәлекләрен өйрәнү, киң массага җиткерү өчен бастырып чыгару эше бераз җанланып китте һәм нәтиҗәләрен күрсәтеп тора. Менә безнең кулда шундыйлардан берсе – Габделҗәббар Кандалыйның XIX йөзнең I яртысында яшәгән һәм иҗат иткән татар шагыйренең җыентыгы[6].

Әле күптән түгел генә Кандалый иҗаты буенча гыйльми эзләнүләрдәге соңгы ике ел эчендәге яңа табышлар хакында «Совет әдәбияты» журналында Х. Госманның зур мәкаләсе һәм шагыйрьнең яңа билгеле булган шигырьләре белән танышкан

[1] *Фәтхи Альберт.* Габделҗәббар Кандалый җыентыгы // Совет әдәбияты. 1961. № 3. Б. 144–147.

[2] Казан федераль университетының фәнни китапханәсенең Көнчыгыш секторы. 6 ф., 96 с.б., 147 кгз. (анда мәкаләнең берничә кулъязма һәм басма варианты саклана).

[3] Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш. Татар әдипләре һәм галимнәрнең кулъязмалары. Өченче бүлек / төзүчесе Альберт Фәтхи. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1968. Б. 52–57.

[4] *Кандалый Габделҗәббар.* Шигырьләр һәм поэмалар / төзүчесе Миркасыйм Госманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

[5] Габдельджаббар Кандалый: через призму современности / Ф.Ф. Хасанова, Л.Ш. Давлетшина; под ред. Р.Ф. Харрасовой. Казань: ИЯЛИ, 2015.

[6] *Кандалый Г.* Шигырьләр / төзүчеләре: Хатип Госман һәм Җәвад Алмаз; редакторы А. Гумеров. [Казан]: Татар. кит. нәшр., 1960. 186 б.

идек[1]. Бераз элегрәк Кандалый шигырьләре «Татар поэзиясе антологиясе» һәм М. Гайнуллинның «Татар әдәбияты. XIX йөз» исемле дәреслек-хрестоматиясендә дә бастырылдылар. Әмма болар гына җыентыкка мохтажлыкны каплый алмый иде. Кандалыйның тормыш һәм иҗат юлы буенча күп еллык тикшеренүләргә йомгак ясый торган, киң катлау укучылар өчен чыгарылган аерым җыентыкның кирәклеге күптәннән сизелә иде һәм моның өчен бөтен шартлар да күптән өлгереп җиткән иде инде. Менә, ниһаять, күптән көтелгән китап күз алдыбызда.

Кандалый хакында төрле чыганаклардан безгә шушы мәгълүматлар анык билгеле: Габделҗәббар Габделмәҗит улы Кандалый (1797–1860) бары шигырь язу белән генә көн иткән кеше булмаган. Ул, төрле мәдрәсәләрдә гыйлем эстәп йөргәннән соң, кайтып, үзенең туган җирендә – Самара губернасы Иске Кандал авылында (хәзерге Ульянов өлкәсендәге Иртуган исемендәге авыл) мулла булып торган. Мәдрәсәләрдә йөргәндә үк көчле рухы, сыешмас характеры һәм уй-тойгыларын шигъри сөйләмгә салып бирүгә һәвес булуы белән танылып өлгергән. Тынгы белмәс, омтылучан күңеле, ташып торган ихтыярына бик үк туры килми торган руханилык эшенә бәйләнгәч тә, тиз әсәрләнүчән йөрәгенең ялкынын баса алмаган: вакыт-вакыт авылындагы һәм тирә-юньдәге чибәр кызларга үзенең яшерен хисләрен уртаклашкан – үзе әйтмешли, «эчне өзерлек гыйшык бәетләре» һәм шулардан төзелгән гыйшык дәфтәрләре юллап торган. Безгә әнә шул шигырьләр «Сахипҗәмал», «Фәрхисөрур», «Бәдыйга һәм Бәгыйдә», «Фатыйма» һ.б. шигырь теркәмнәре (әдәбият тарихчысы М. Гайнуллин аларны поэмалар итеп карый) рәвешендә мәгълүм.

Аның шулай ук үзе тормыш алып барган тирәлекнең караңгы якларын фаш иткән шигырьләре булуы хакында да кайбер фактлар билгеле иде. Болар үз дәверендә күңелдән күңелгә үтеп, кулдан кулга күчерелеп – халыкта киң таралган булырга кирәк. Кандалыйның менә шуннан әдәбият дөньясына алып керелүе һәм әсәрләре бастырылуның шактый тарихы бар.

Аның шигырьләре, «Мелла Г. Кандалый иншасы» дип, анык күрсәтелгән хәлдә, иң беренче тапкыр 1887 елда Каюм Насыйри тарафыннан төзелгән «Фәвакиһ әл-җөләсаэ» китабында бастырылган. Бу текст әдәбият тарихчыларына – Кандалый иҗаты буенча тикшеренүчеләргә бердәнбер һәм төп чыганак булып килде һәм хәзер дә шулай булып кала, әдәбият тарихы буенча күзәтүләргә һәм гыйльми хезмәтләргә нигез булып тора.

Кандалыйның тормыш юлына караган мәгълүматларны киңәйтү һәм билгесез шигырьләрен эзләү юнәлешендә 1920 елларның азакларында шактый эш эшләнде – болар безгә журнал

[1] *Госман Х.* Габделҗәббар Кандалыйның яңа табылган әсәрләре // Совет әдәбияты. 1960. № 5. Б. 134–142; Г. Кандалый шигырьләре // Шунда ук. Б. 143–148.

мәкаләләре рәвешендә генә сакланып калган. Гыйльми Үзәк тарафыннан шагыйрьнең җыентыгын бастырып чыгару эшенә керешелсә дә, тормышка ашмый калган. Бераз соңрак, 30 нчы елларда Кандалый тормышы һәм иҗаты хакындагы мәгълүматлар мәктәп дәреслекләренә дә кертелеп өйрәнелә башлады.

Габделҗәббар Кандалый шигырьләренең әдәбият тарихчысы Б. Яфаров тарафыннан 1940 елларның башларында төзелгән җыентыгы да дөнья күрә алмый калды. Соңгы ике-өч ел эчендә, шагыйрьнең дөньядан күчүенә бер гасыр тулу уңае белән, Кандалый иҗаты буенча эзләнүләр тагын да җанланып китте һәм күңелле нәтиҗәләрен дә бирде. Моңарчы фән дөньясында Габделҗәббар Кандалый шигырьләренең гыйлем ияләренә тикшерү өчен чыганак булырлык кулъязма күчермәләре билгеле түгел иде – ниһаять, берәүсе табылды. Бу дәфтәрдәге шигырьләр һәм Кандалыйның авылы, тирәюньдәге кешеләрнең мәгълүматлары тагын бер хәлне ачыкларга мөмкинлек бирделәр: Каюм Насыйрига кадәр үк, имзасы күрсәтелмәгән хәлдә, Кандалыйның кайбер шигырьләре С. Кукляшевнең «Диване хикаяте татар» (1859), «Рус география җәмгыятенең Оренбург Шөгъбәсе язмалары, I чыгарылыш» (1870), «Мәгъшукнамә» (1880) кебек җыентыкларда да басылган икән.

Кулыбыздагы китап, димәк, Кандалый шигырьләренең аерым җыентык итеп чыгарылган тарихта беренче басмасы булып тора. Җыентыкны төзүчеләр югарыда әйтелеп үтелгән бөтен материалларны исәпкә алганнар, текстка нигез итеп файдаланганнар һәм укучыга уңайлы, аңлаешлы рәвештә җиткерергә тырышалар. Тупланган шигырьләрнең бер өлешен, гәрчә болар эчтәлек һәм стиль ягыннан Кандалыйныкы икәне төгәл билгеле шигырьләргә бик якын торсалар да, хәзергә әле аларны аңа беркетерлек анык дәлилләр булмаганлыктан, «Г. Кандалыйныкы булуы ихтимал әсәрләр» дигән аерым бүлек итеп урнаштырганнар (173–180 битләр). Төзүчеләр, шигырьләрнең эчтәлек һәм стиль якларын исәпкә алып, кисәкләргә бүлгәннәр, исем биргәннәр, бу – шигырьләрне аңлауны җиңеләйтә.

Җыентыктагы шигырьләрдән фикере һәм аны сүзләрдә, шигырьдә бирү алымы үзенчәлекле булган һәм безнең төшенчәбездә бары аңарда – Кандалыйда гына булган шигърият дөньясы ачыла.

Бу «Сахипҗәмал», «Фәрхисөрур» кебек шигырьләрен үз тавышы, яңгырашы белән күңелгә ирештерүче җанлы Габделҗәббар. Аның күзе авылның конкрет бер шәхесенә – Сахипҗәмал исемле кызга төшкән. Кызның нәфис яратылышы, күркәм сурәте аның күңеленә кереп калган һәм шушы тойгы аны даими рәвештә күрешүгә, кавыштыруга карата сагышта тота. Гашыйк иясе – шагыйрь:

*Казан дик кайната бези*
*Синең яшь сылу чагың, –*

дип яза.

Матурлыкны сүз белән әйтеп бирүдә, тасвирлауда ул оста

сурәтләр таба. Кыз аның өчен гадәти соклану объекты гына түгел, ул аны үзенә каратырга, үзенеке итәргә тели. Бу ният аны тар хиссият кысаларыннан җәмгыятьнең киң тормышына алып чыга, яшәмәктәге тормышның реаль картинасына карашын юнәлтә һәм менә ул укымышсыз кеше, гади хезмәтче – бояр колының рәхәт күрмәс, «йөрәк маен сыздыра» торган көндәлек тормышын, күрешен, эшен бөтен ваклыклары белән гәүдәләндереп китә (мәсәлән, «Сахипҗамал» төркеменнән «Наданга барсаң», «Шул ярыймы?...», «Аның кеби була күрмә» шигырьләре). Шунда ук, ярының бөтен игътибарын биләп алыр өчен, үзенең дөньяга карашынча әйбәт дип исәпләнгән, укымышлы кеше тормышының да кабарынгы, купшы, якты буяулар белән ясалган сурәтен бирә. Шулай итеп бер-берсеннән кискен аерылып торган күренешләрнең алмашынуы шигырьдә билгеле бер дәрәҗәдә киеренкелек тудыра, тирән кичерешләр уята. Ә бу исә шигырьләр төбәлгән затка – мәгъшукага тәэсир итү өчен шулай эшләнгән һәм бүгенге укучыга да тәэсирсез калмый.

Кандалый үзенең рухи халәтен төрле мизгелләрендә тасвирлауның чын остасы – әле талгын гына матур кызны беренче күргәндә алган тәэсирләрен сурәтли, әле кабынган хисләрнең, сагышның моңлы көен сызып ала, әле күрешергә ашкыну, түземе бетү хәлен өздерә, әле мәгъшукасының кыланышларын күңелендә тергезә, әле төшкә кавышуларының керүен тасвирлап китә, әле гыйшык чабының – «яман атының» илләргә таралуын сөйләп китә, әле аның хисләрен уртаклашмас кызның соңыннан аңа карамавына үкенүен чагылдыра, яки, хәтта, аның әнкәсеннән муллага бирүен теләп инәлүен тезеп китә. Вакыт-вакыт каргышлы тон да ишетелеп куя, бик сирәк кенә булса да хисләрен яшереп соткан хәлдә, коры акыл белән генә үгет-насыйхәт биреп куйган чаклары да була. Гомумән, «Сахипҗамал», «Фәрхисөрур» кебек шигырьләрдән Кандалыйның әйтергә теләгән фикерне, куйган ниятне шигъри сүзләрдә җиткерү осталыгына ия булуы, чын шагыйрь икәнлеге күренә. Хәтта ул үзе үк осталыгын сизә:

*Хатымга итмәгел тәгъна,*
*Укы бик сагына-сагына,*
*Ачылыр сер белән мәгъна,*
*Булыр язган кеби ташка.*

Һәм күңелгә һичнинди рәхәтлек китерми торган «суык сүз»гә каршы чыга:

*Суык сүз җангадыр агу,*
*Түгел бу файдасыз ләгу,*
*Елан кеби йөрәк чагу*
*Бик ошамас, и җанкәй лә.*

Кандалыйның образлы фикер йөртү системасы, теле гаять бай. Аңарда, электән үк килә торган китап әдәби теле элементлары белән бергә, моңарчы иҗатчыларга әле бөтен хәзинәләрен ачарга өлгермәгән, татар халкының җанлы сөйләшү теле бөтен көч-куәте белән язмага ургыла. Бу ягы белән ул татар әдәби телен яңа нигезгә утыртуга башлангыч эшләрне кузгатып җибәргән шагыйрь. Бу тел халыкның мәкальләре, хикмәтле сүзләре һәм әйләнмәләреннән

тукылган бик тә образлы тел. Аңардагы «сырт каешын телеп алу», «камчы җүрмәсе ашату» (сугу, кыйнау), «сагыш киләбе сару», күңелнең «сары май тик эрү»е һ.б.ш. мәгънәле тел бизәкләре шигырьнең тәэсир итү көчен арттыра. Халыкчан сүзләрдән төзелгән җөмләләр һәм аның күптөрле формалары, кичерешле монологлар шигырьнең чын татарча аһәңле яңгырашын ишеттергән сыман була. Әмма җанлы сөйләшкә хас эшләнмәгәнлек, «чилек», хәтта вакыты-вакыты белән тупаслык та үзен сиздерми түгел. Әдәби телдә урын ала алмаслык, кирәксездән, бары шигырьнең форма җае, рифма таләпләре белән генә килеп кергән рус сүзләре (тутка, душка, мальчик, жар, горе, дура, чудо, так һ.б.), кайберләрендә гарәп-фарсы сүзләренең бераз чамасы артып китү (мәсәлән, «Я кояшсың яки айсың») кебек фактлар шигырьнең нәфислеген бераз ямьсезләтсә дә, болар гына Кандалый теленең төп агышын каплый алмыйлар. Ул халык теле хәзинәләренең иң тирәндә яткан катлауларын өскә, яктыга чыгаручы, кирәкле сурәт ясау өчен аны кабат тергезүче буларак безнең күңелдә кала. Нәкъ менә шушы үз заманында һәм гасыр буена популяр булуына төп сәбәпче булган булырга тиеш.

Җыентыкның 37–78 битләрендә нигездә соңгы вакытларда табылган яки Кандалыйныкы итеп карала башлаган шигырьләр килә. Безнеңчә, «Сахипҗәмал», «Фәрхисөрур», «Бәдыйга һәм Бәгыйдә» кебек шигырьләрне, иң билгеле һәм Кандалый өчен иң характерлы булуларын искә алып, җыентыкның башында бирергә дә мөмкин булыр иде. Җыентыкның бу баштагы өлешендәге шигырьләр Кандалый иҗаты турындагы төшенчәләрне тагын да киңәйтәләр. Шул ук гыйшкый эчтәлектәге шигырьләрнең матур гына үрнәкләре күренә («Шәфгый», «Гөлстанга», «Әминәгә», «Камиләгә»). Шул ук темага багышланган «Беләлмадым», «Җаным корбаның улсын», «Бер нәзарда», «Сән һәм бән», «Сәламнамә» шигырьләре дә гаять образлы булулары белән әсир итәләр. Бу өлештәге шигырьләрдә Кандалыйның тематика киңлеге, сурәтләү чараларының төрлелеге күренә. Менә «Җен иблистән дә битәрмен» шигыре – ихтыяр көче ташып торган егетнең үзеннән ятсынган тирәлеккә соңгы катгый монологы. Ә «Йөрепмез гафләтә һәр ан» шигыре исә мәдрәсә шартларында белем бирелмәүне, яшьләрнең надан калуга дучар ителүен тасвирлый. «Мулла белән абыстай» шигыре хезмәт ияләре җилкәсендә кәеф-сафа сөрүче сорыкорт муллаларны фаш итә. «Кара кол тик» шигыре бояр коллыгындагы мужик кызының – Җәмиләнең газаплы тормышын бик җанлы итеп гәүдәләндерә. Кандалыйның, олыгайгач, солдаттагы улына язган шигъри хатында баласын сагынуы үзәк өзгеч итеп тасвирланган («Газиз балам», «Бу хәрсәтдер бетер микән»).

Җыентыктагы шигырьләрдән Кандалыйның кыска-кыска гына, әмма бик тә тапкыр шигъри парчалары да булуы («Вакыт һәм

якут», «Кайгыга дәва», «Белсә һәм белмәсә», «Аерма» һ.б.) күренә.

Җыентыкны төзүчеләр бик зур текстологик эш башкарып чыкканнар. Текстлар тәнкыйть белән күздән кичерелгән һәм аеруча «Фәвакиһ әл-җөләсаэ»дәге кайбер төгәлсезлекләр, бигрәк тә хәреф хаталары бетерелгән, аңлаешсыз урыннары анықланган. Татарның элеккеге язуында – искәлифтә язылган текстны хәзергегә күчергәндә текстның бөтен якларын (мәгънәсен, шул заманча әйтелешен) исәпкә алырга тырышалар һәм шуңа күрә, шигырьнең оригиналдагы аһәңле яңгырашы хәзерге көн укучысына ирешә. Бөтен текстның мәгънә ягына игътибар биреп укылышның (хәзергегә күчерүнең) менә бер мисалы:

*Төшемдә Парау илендә*
*Ки сәйран иттем оҗмахта,*
*Барып анда сәнең илә,*
*Ки сәйран иттем очмакта.*

Мондагы рифмадаш сүзләр – «оҗмах – очмак», «Фәвакиһ әл-җөләсаэ»дә (578 бит) бер үк төсле язылган. Монда, алдагы строфаларда җилгә утырып оҗмахка очып бару турында сүз баруын искә алганда, төзүчеләрнең икенче рифмадан сүзне «очмакта» рәвешендә укулары игътибарга лаеклы.

Әмма, мондый зур эшләрне башкарганда хаталарсыз үтеп чыгу кыен булганлыктан, текстта хәреф хаталары шактый гына күп киткән. Мәгънәгә зыян китерә торган кайберләрен күрсәтми үтми булмас:

*Киталмас, никадәр сузсаң*
*«Мәңа кил», ди-ди, кул гына*
(110 бит)

«Фәвакиһ әл-җөләсаэ»дә (573 бит) монда «Йитә алмас» сүзе килә һәм ул, һичшиксез, дөрес булырга тиеш.

Басылган: *Тузан, кер, зәррәгә орлык* (118 бит). Дөресе: *зөррәчә* («Фәвакиһ әл-җөләсаэ», 576 бит).

Басылган:

*Ошамас үзеңә ярап,*
*Рәҗәпләр сүзенә карап,*
*Була күрмәсенә харап,*
*Сүземне тот, и җанкәй лә*
.......................................
*Рәҗәпләр сүзенә оедың,*
*Ки бер мәхәббәтең койдың*
(119 бит)

Дөресе:

*Ошасам үзеңә ярап*
.................................
*Ки бар мәхәббәтең җуйдың.*
(«Фәвакиһ әл-җөләсаэ», 577 бит)

Басылган:

*Мәхәббәт булмасын барган йирендә,*
*Сафалар сөрмә һич барган йириндә*
(161 бит)

Дөресе:

*Сафалар сөрмә һич барган ирәндә*
(«Фәвакиһ әл-җөләсаэ», 579 бит)

Басылган:

*Уенны уйнай алмас дин уенча*
(162 бит)

Дөресе:

*Уенны уйнай алмасын уенча.*
(«Фәвакиһ әл-җөләсаэ», 580 бит)

Укылышта бердәмлек сакланмаган урыннар да очрый:

*Сәламемне* ***тикергәнсен***
*Сахипҗәмал абыстайга*
(98 бит)

*Ничә кәррә язам пуштым,*
*Сәңа **тигермәге** куштым.*
(111 бит)

Бүгенгәчә җанлы яңгырашны бирү ягыннан соңгысы ятышлырак һәм килешлерәк булса да, тарихи якны искә алып беренчесендәгечә калдыру әйбәтрәк булыр:

*Нисән сән аңа килмәйсән?*
*Колакка сүзен алмайсән,*
*И белмисән лә, белмисән,*
*Бик үк төядер, ай-һай ла.*
(98 бит)

Башка грамматик формаларның (килеш, зат кушымчалары) бирелешендә дә төрлечә киткән урыннар бар. «Белә алмадым», «түзә алмадым» формасындагы кушма фигыльләрнең кушылып язылышында да бердәмлек юк: «белалмадым» (37 бит) – «беләлмассың» (117 бит), «түзәлмадым» (103 бит).

Бу формадагы фигыльләрне бербөтен итеп биргәндә, безнеңчә, яки морфологик принципны кулланып, икенче сүзнең кушылмаган хәлдәге язылышын сакларга (белалмадым, түзалмадым), яки бөтенләй халык әйтелешенә ияреп, сингармонизмга буйсындырырга (беләлмәдем, түзәлмәдем) кирәк – икесенең берсен кануннлаштыру турында уйлап карарга ярый.

Җыентыкның ярдәмче аппараты да уңайлы эшләнгән – аңлаешсыз сүзләргә аңлатмалар бирелгән. Китапның азагында һәр шигырьнең чыганагы күрсәтелү дә җыентыктан алырга мөмкин булган мәгълүматларны киңәйтә.

Китаптагы Х. Госман тарафыннан язылган кереш сүз (4–34 бит) Габделҗәббар Кандалыйның тормыш һәм иҗат юлы, әсәрләренең бастырылу тарихы турында тәфсилле мәгълүмат бирә, татар әдәбияты, аерым алганда поэзия тарихында Г. Кандалый иҗатының тоткан урыны тикшерелә. Автор монда, кайбер әдәбият белгечләре кебек, җиңел юлдан – билгеле фактларны коры теркәү яки аларга берьяклы бәя бирү юнәлешендә китмәгән. Мәкалә укучыны бөтен күңеле белән Кандалый поэзиясенең фикер һәм хис, мәгънә һәм нәфислек дөньясына алып кереп китә. Кандалыйның идея-художество дәрәҗәсе Идел буе төркиләренең борынгы әдәбияты һәм татар әдәбиятының үсеше фонында карала. Идея һәм сурәтләү чараларының үсешен күзәтергә мөмкинлек бирә торган күп фактлар нигезендә, тикшеренүче төп игътибарны Кандалый иҗатындагы яңалыкка юнәлтә. Кандалый иҗатындагы яңалыкны аллачыл принципларны җиңеп, кешечел принциаларны куәтләп, үстереп җибәрүендә күрә (11 бит).

Кандалый кешенең матурлыгын җырлаучы шагыйрь булуы, аның кешене имгәтә торган коллык тәртипләрен реаль картиналарда гәүдәләндерүе, дөньяга карашындагы чикләнгән яклар турында да нигезле күзәтүләр бар. Кандалыйның шагыйрь буларак осталыгы, шигырьләренең сәнгатьчә эшләнү үзенчәлекләре тикшерелә, элгәреге әдәбият һәм халык иҗаты белән бәйләнешләрен, образлар күчемлелеген раслый торган күп фактлар китерелә.

Китапның тышлыгы да ярыйсы гына матур эшләнгән, тик, китапның аркылысы җәенкерәк

булу сәбәпле, килеш-килбәтенә бераз зыян килгән, ямьсезләнгән. Шәкелен гадәти китаплар шикелле җыйнаграк иткәндә яхшырак булган булыр иде.

Китаптагы күрсәтелгән вактөяк кимчелекләр генә аның кыйммәтенә һич зыян китерә алмыйлар. Җыентык, һичшиксез, киң катлау укучылар өчен уңайлы һәм җәлеп итәрлек итеп төзелгән. Ул Кандалый иҗатын туплау һәм тикшерү буенча күп еллык хезмәтләргә нәтиҗә ясый һәм шагыйрьнең иҗатын бербөтен итеп күз алдына бастыра – шунысы белән ул укучыларга, шагыйрьләргә кызыклы материал бирер һәм алдагы гыйльми эзләнүләргә нигез булып торыр.

Бу китапны чыгаруы белән Татарстан китап нәшрияты XIX гасырның II яртысыннан элгәреге әдипләребезнең (югыйсә, бездә классик мирастан моңарчы XIX гасырның II яртысында яки аннан соңгы – XX гасыр башларында иҗат иткән әдипләребез әсәрләре генә басылып килә иде) дә аерым җыентыкларын бастырып чыгару эшен башлап җибәрә. Бу һәрьяклап игътибарга лаеклы эш һәм бу юнәлештә XIX йөздә генә туктап калмый, тарихның тагын да элгәрерәк дәверләренә төшү, ул дәвер истәлекләрен дә дөньяга күрсәтүдә Кандалый җыентыгының кул арты җиңел булсын иде, диясе килә.

Җай чыкканда бу китап басылып ятканда билгеле булган Кандалый иҗатына бәйләнешле кайбер материалларны китереп үтү артык булмас.

Югарыда аңлашылганча, фән дөньясында Кандалый шигырьләре күчерелгән берничә генә язма истәлек (Зирекле Куак дәфтәре һәм җыентыкны төзүчеләр искә алган, аерым кулλардагы бер-ике күчермә) билгеле һәм файдаланыла иде. Казан университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Көнчыгыш кулъязмалары секторындагы татар язма истәлекләренең әле тикшерелмәвен искә алганда, болар аркасында да Кандалыйга бәйләнешле материаллар булу мөмкин иде һәм, чыннан да, төрле язма җыентыкларны күздән кичерү нәтиҗәсендә, Кандалый шигырьләренең уннан артык күчермәсе булуы беленде.

Бу күчермәләр шагыйрьнең популярлык казануына, кулдан кулга күчерелеп йөртелүенә тарихи таныклык булып торалар, билгеле текстларга кайбер аныклаулар кертәләр.

Төрле эчтәлектәге материаллар теркәлгән ике җыентык эчендә «Шәфгый» шигыренең күчермәләре бар. Беренчесе 699 т (4039) номеры белән саклана торган бу җыентык 10,5×16 см зурлыкта, төрле вакытта төрле кешеләр тарафыннан язылган төрле эчтәлектәге язулы кәгазьләрнең теркәлмәсеннән гыйбарәт. Кәгазе күкшел-зәңгәрсу, бик искергән, каралган, таушалган, җыентыкның ахыргы кәгазьләренең почмаклары ертыклы. Җыентык төркичә (элекке татар әдәби телендә) шигырьләр белән ачыла, аннан соң «Хасияте чәй» исеме астында әдәбият тарихчылары тарафыннан авторлыгы Г. Кандалыйга нисбәт бирелә торган билгеле «Чәй бәйте» күчерелгән (2б–3а кәгазьләрдә). Өченче урында:

*Китәм имди, сәламәт бул,*
*Ки тәхсыйл гыйлемчөн мән кол,*

дип башлана торган авторы билгесез бер шигырь.

Кандалыйның Шәфгый исемле кызга атап язган шигырьләре җыентыкның дүртенче урынында килә.

Моннан соң җыентыкка «Шорут әс-салат» исемле гарәпчә бер әсәр, «Каһарман Катыйль» кыйссасының башы, фарсыча бер көйле әсәрнең башы, төрекчә «Карабаш тәҗвиде», догалар һ.б. кертелгән. Җыентыкның бер төшендә дә кисәкләренең кайда, кайчан, кем тарафыннан күчерелүе турында мәгълүмат юк. Кандалый шигырьләре күчерелгән өлеше XIX гасырның урталарында язылган булырга кирәк.

Кандалый шигыре:

*Сәламләр әйләдем, Шәфгый,*
*Сәламәт итсен ул әгъла*[1]*,*
*Тулун ай дик йөзең кыйлсын*
*Һәмишә көн бә көн әҗла*[2]

дигән строфа белән башлана.

Бу шигырьне Кандалыйның басмага әзерләнгән шигырьләр җыентыгындагы тексты белән чагыштырып караганда, бу күчермәдә кайбер артык строфалар күренә. Мәсәлән, мәгъшукасының буй-сын нәфислеген гәүдәләндерә торган:

*Билең нечкә, буең һәм төз,*
*Тәнең саф гуяки акбүз,*

дип башланган строфадан соң шушы ике строфа китә:

*Гаҗәптер, белегез анча,*
*Ләбең ләгыйль*[3]*, дешең гонча*[4]*,*
*Юк ирди күрәсем бонча,*
*Күрүбән күп кәмаләти*[5]*.*
*Үзең сылу, йөзең күркәм,*
*Нәчә дисәм дә улыр кәм,*
*Язарга йитмәер дә һәм*
*Кәгазь – кара мәкаләти*[6]*.*

(5б кәгазь)

Гыйшык газабыннан шагыйрьнең хыялланып Мәҗнүн хәленә төшүе белдерелгән юллардан соң язмада:

*Сәнең өчен, әя җаным,*
*Тәнемдә калмады каным,*
*Бетептер дәрде дәрманым*[7]*,*
*Күрчәк ошбу халәти,*

дигән строфа килә.

Авторның Шәфгыйга гыйшкыннан җаны өзгәләнүе, сагышын тасвирлаган җиде строфа да басма текстта юк. Боларның берсендә шагыйрьнең образлы фикер йөртү системасында сөйгән ярының җанлы сурәтен ясау омтылышы чагылып китә:

*Әгәр улса иде мокътәд*[8]*,*
*Сурәтләр кыйлмага остад,*
*Сурәтеңне ясап һәфтад*[9]*,*
*Идәрем халкара мәшһүр.*

---

[1] Әгъла – бөек (бу урында Аллаһ күздә тотыла).

[2] Һәмишә – һәрвакыт; көн бә көн – көннән-көнгә; әҗла – матуррак, нурлырак.

[3] Ләбең ләгыйль – иренең кызыл якуттай.

[4] Гонча – чәчәк бөресе.

[5] Кәмаләт – камиллек, җитешлек, тулылык, бөтен яктан килгән.

[6] Мәкаләт – сүзләр.

[7] Дәрд – газап, авыру, сагыш; дәрман – дәва, дару.

[8] Мокътәд – үзе артыннан ияртә алырлык, үрнәк булырлык кеше, җитәкче, баш кеше.

[9] Һәфтад – җитмеш (тапкыр).

Басмада текст:

*Колак салып ишет, Шәфгый,*
*Ки сөйләем сәңа бер дөш,*
*Ирәм багында ирмеш сән,*
*Ки сайрарсың булып бер кош,*

дигән строфа белән өзелә (51 бит), димәк нигез итеп алынган язма нөсхәдә дәвамы, азаккы өлеше булмаган. Ә бу күчермәдә исә дәвамы шушы рәвештә китә:

*Сүземне сөйләем баштыйн,*
*Хәбәр биреп каләм каштыйн,*
*Гашыйк улып кече яшьтин,*
*Йөрер ирдем улып сәрхуш*[1].

*Кыныңыздин китәр чакта,*
*Илеңездин*[2] *үтәр чакта,*
*Өеңезгә йитәр чакта,*
*Үтәр ирдем улып мәдһуш*[3].

*Сагышында нәчә елым,*
*Үтәр ирде, әй былбылым,*
*Илеңездин иде юлым,*
*Сәне белсәм иде дип туш*[4].

*Гыйшыкны дотып эчтә,*
*Йокым килмәс иде кичтә,*
*Дәхи көндезләрем һич тә,*
*Сагыштин булмадым мән буш.*

*Ки бер кичне оер ирдем,*
*Йокымда билә*[5] *төш күрдем:*
*Һавадин кош булып йөрдем,*
*Сәзә варып имешмен уш.*

*Варым иркән очып ялгыз,*
*Сәне эстәп, әя мәхбүб,*
*Юлымны язган имешмен,*
*Буран чыгып, улып мәхҗүб*[6].

Бу кулъязмада шигырь шунда өзелә. Икенче күчермә дә шул ук Шәфгыйгә багышланган шигырьдән гыйбарәт. Монысы 238 т (2707) номеры белән саклана торган, 11×17,5 см зурлыкта 24 кәгазьле (48 битле) җыентык эчендә. Инвентарьга һәм каталогка: «Фәтхулла. Халык арасындагы хыялый хикәяләр» дип теркәлсә дә, асылда ул төрле шигъри һәм прозаик материалларны эченә алган җыентык. Алар арасында да бер бәет, догалар, Мөхәммәд белән яһүдиләрнең сугышын тасвир итүче көйле хикәя өзеге, сукыр солдат турында халык әкиятенең азагы бар. Җыентыкта, тәртип ягыннан бишенче буларак, «Илаһи бәйте гыйшык» исеме астында, Кандалыйның Шәфгыйга багышланган шигырьләре килә (26–38 битләр). Моннан соң «Удельный бәете», Таз турында халык әкияте, берничә вак көнчыгыш хикаяте китә. Җыентыкның кайда, кайчан күчерелүе күрсәтелмәгән, тик 38 нче биттә генә мелла Исхак өчен Фәттәхетдин исемле кеше тарафыннан күчерелүе турында мәгълүмат бар. Күчермә XIX гасырның урталарында эшләнгән булырга кирәк. Җыентык Татарстанның Балтач районында табылган. Күчерүче үземе, әллә җыентык итеп теркәүчеме, әллә башка берәүме – һәр биткә дә һинд цифрлары куеп чыккан, Кандалый шигырьләре шул тәртипнең 20–28 битләренә туры килә.

[1] Сәрхуш – әсәрләнеп, кәефләнеп йөрү.

[2] Ил – бу урында: авыл.

[3] Мәдһуш – курку, шүрләү.

[4] Бу сүз каты т (той), вау, ше хәрефләре белән язылган. Мәгънәсе аңлаешлы түгел. Русча точь сүзе түгелме икән.

[5] Билә – болай, мондый.

[6] Мәхҗуб улу – капланып калу (адашу).

Шигырь беренче күчермәдәге шикелле үк башлана, тик монысында тарихи конкрет бер шәхеснең – Кандалыйның мәгъшукасының исеме – «Шәфгый» урынына гомуми төшенчәне тәгъбир итүче «җаный» сүзе куеп чыгылган. Шигырьдәге Кандалый җирлегенә генә бәйле бу моментның алыштырылуы бу шигырьне башка мәгъшукаларга да каратырлык итәргә теләүдән, яратыштырырга тырышудан килеп чыккан булырга кирәк. Бу хәл бөтен күчермә буйлап үтә. Күчермәнең орфографиясендә дә кайбер үзгәлекләр күренә. Мәсәлән, беренчесендә «тулун ай» диелгән булса, монысында «тулан ай» рәвешендә язылган. Беренчесендә

*Авазың итде былбыл дик,*
*Идеп фазлы гыйнаяти, –*

рәвешендә дөрес язылган булса, икенчесендә ачык беленеп тора торган төгәлсезлекләр җибәрелгән:

*Авазың диде былбыл дик,*
*Идеп фаслы гыйнаяти*
(27 яки XXI бит)

Башка урыннарда да кайбер аерымлыклар күренә. Беренче күчермәдәге уртадагы 13 строфа монысында төшеп калган, ягъни:

*Улып мән инди Мәҗнүн дик,*
*Идеп гыйшык хыяләти, –*

дип тәмамлана торган юлдан соңгы строфадан башлап, /72/

*Сүземне сөйләем баштыйн,*
*Хәбәр биреп кара каштыйн, –*

дип башлана торган юлларга хәтле булган строфалар бу нөсхәдә юк. Әмма монысының безнең өчен кыйммәтле ягы – тегесендә тасвирлана башланган төшнең дәвамы булуда. Шулай ук, төшне тасвирлар алдыннан килгән строфалар рәтендә дә, беренче күчермәдәге белән чагыштырганда, монда бер артык строфа бар,

*Сәне белсәм иде дип туш –*

дип тәмамланган строфадан соң килә.

*Юлыгып бернича ирләр,*
*«Ки канда варасән», – дирләр,*
*Дидем: «Соң бу каю йирләр,*
*Юлым яздым улып һәмйуб.*

*Берсе: «Соң, – диде бәңа, –*
*Каю юлдыр кәрәк сәңә?»*
*Ишедәчәк идем кана:*
*«Ирәм багынадыр мансуб»*[1]*.*

*«Бу Шаһбан падишаһ тагы,*
*Моның алда ирәм багы».*
*Бакарсам сул белә сагый*[2]*,*
*Ирәм багы ирер мәкърүб*[3]*.*

*Күрәм ки багы ирәмдер,*
*Әчидә яхшы хәрәмдер*[4]*.*
*Бизәнеш бу кадәр имеш, /73/*
*Күңел яратку дик мәргуб*[5]

Шушы юллар белән 24 ле һинд цифры куелган бит тәмам була. Гәрчә моннан соңгы битнең «көлсәнә» сүзе белән башлануы күрсәтелсә дә – ул зәңгәр карандаш белән кемдер тарафыннан сызылган – һәм һиндчә бит исәбе

---

[1] Мансуб – нисбәт, бәйләнеш. Бу урында: юлым.
[2] Сагъ – уң. Уңга-сулга карасам.
[3] Мәкърүб – якында, ерак түгел.
[4] Хәрәм – өйнең хатын-кыз ягы яки хатыннар гына тора торган өй, гарем.
[5] Мәргуб – әйбәт, яхшы эшләнгән.

дөрес барса да, моннан соңгы бит төшкән булырга кирәк, чөнки икенче бит күрсәтелгән сүз белән башланмый, сүз сөрешендә дә оч очка ялганмый. Ул бит (31 яки XXV) шушы строфалар белән башланып китә:

*Хисап итдем – улдым хәйран,*
*Әя җаный, ки бу эшдин.*
*Кичә ятсам чыга белмәс,*
*Буең – төсең сәнең һушдин. /74/*

*Я сурәт кыйлгучыларга,*
*Сәнең өчен варыйм микән,*
*Сөеп йөргәнләрең, җаный,*
*Китә белмәс күз алдымдин.*

*Әнҗерә иленең*[1]*…*
*Сылу йөзлүк, нәзек биле,*
*Нитә тикермәйдер сәңа*
*Сәламемне саба йиле.*

Моннан соң шул ук рухта тагын 22 строфа күчерелә. Шагыйрь боларда да бөтен көчен мәгъшукасының күркәм сыйфатларын тасвирлауга куя, аны үзенә каратырга тели. Образлы фикер йөртү системасында артык яңа сурәтләр, бизәкләр ялтырап китмәсә дә, Кандалый поэзиясе өчен гадәти образлардан да шигырьнең бик тә нәфис үрелүе сизелеп тора:

*Нәчә мәдх илә язсам да,*
*Төсең-буең, әя җаный,*
*Гыйшыкың утыда һәргиз*[2]*,*
*Табалмадым дәва рәфгый*[3]*.*

*Нәчә мәдх әйләсәм*[4] *бетмәс,*
*Гакыл дәхи фәһем итмәс,*
*Кәгазь дә һәм кара йитмәс,*
*Язарга сорасаң, җаный*

*Ефәк сакчле башың иму,*
*Яңа айдай кашын иму,*
*Һәм унбишдә яшың иму,*
*Нә мәдх илә идәм дәфгый*[5]

*Ак энҗү кеби дешеңе,*
*Сәйре әҗна*[6] *йөрешеңе,*
*Ак алмадай йитешеңе,*
*Каю берен язам җаный.*

*Билең нәзек, буең тулы,*
*Үзең гөлдәй, йөзең айдай,*
*Күрәчәк сабрымы алды,*
*Дәвалар йитмәер нәфкый*[7]*.*

*Шикәр – бал дик делең иму,*
*Дәхи нәзек билең иму,*
*Йитеш игәкең иму, –*
*Каю берен язам җаный.*

*Йөзен тулан айдай,*
*Ике кашың ике майдай*[8]*,*
*Сачең тарафы исәң, малай,*
*Булыр гуя карар нәгый*[9]*.*

*Тулсаң буең, әя җаный*[10]
*Каю берен язам җаный.*
*Табалмассыңыз сани*[11]
*Сурәткә бакып җаный.*

---

[1] Моннан соң ниндидер сүз төшеп калган булырга кирәк.
[2] Һәргиз – беркайчан да.
[3] Рәфгъ – котылу, җиңеләйтү, бетерү.
[4] Мәдх әйләү – мактау.
[5] Дәфгъ идү – яклау, сурәтләү.
[6] Сәйр – йөреш; әҗна – һуштан яздырырлык, искитәрлек.
[7] Нәфкый – бу очракта: үткәреп җибәрерлек (дәва), сабырын басарлык.
[8] Бу юл ачык танылмый.
[9] Бу юл да ачык танылмый. Болай укыганда: нәгый – еларлык, зарланырлык, үлем турында хәбәр итә.
[10] Бу юл да ачык танылмый.
[11] Бу урында тиңе мәгънәсендә.

*Кызыл алтын яңакларын,*
*Ләгъле мәрҗан дудакларын*[1]
*Делә керде кочакларың –*
*Каю берсен языйм, җаный. /76/*

*Әя, оҗмах хуры идеңмү,*
*Булу йиргә иңдеңмү,*
*Дияргә монда килдеңме,*
*Ирәм багындин, ай җаный.*

*Делең фасыйх, сүзең датлу,*
*Бәдыйга кеби сурәтлу,*
*Җиһанда сәндәй сыйфатлу,*
*Ки зәррә тапмадым сәмыйг*[2].

(31(XXV)–
33 (XXVII) битләр)

Болар шул ук Шәфгыйгә җибәрелгән шигырьләрме, әллә башка бер мәгъшукага багышланганнарымы – ансын әйтү кыен, шулай да соңгысы ихтималрак, чөнки шигырьдә ниндидер Әнҗерә авылы телгә алыну шагыйрьнең бу авылда безгә моңарчы билгесез мәгъшукасы яшәгәнлеге турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Бу күчермә 34 нче (яки XXVIII) биттәге өч строфа белән тәмамлана,

*Бу мәхрүмлекдә куйгынча,*
*Гашыйклар тыйгыны куйгыл,*
*Сәнең кулыңдин үтәем,*
*Кәлеп газиз башып йуйгыл.*

*Исем китәр сәңа, җаный,*
*Делең каты икән ташди,*
*Тәрәххем*[3] *берлә бакмазсән,*
*Гыйшыкым хәддин ашти.*

*Ки ачыйгланмагыл, җаный,*
*Нәчән хат яза дип бәңа.*
*Әгәр белсәң иде гыйшкым,*
*Калдырдың шул заман хәлгә*[4].

Өченче күчермә – 11×18 см зурлыктагы 4 кәгазьле дәфтәрчә. 1621т (5583) номеры белән саклана торган бу дәфтәрчә инвентарьга һәм каталогка «Борынгы татар шагыйрьләренең кызлар турында язган шигырьләре» дип, ялгыш исем белән теркәлгән, чынлыкта исә ул бөтенләе белән Кандалый шигырьләренең күчермәсеннән гыйбарәт. Дәфтәр заман үтү белән саргайган. Беренче кәгазе буш, тик икенче битендә генә «Илаһи бәйте гыйшык» дигән язу күренә. Икенче кәгазьнең а бите:

*Күреп әйтдем сәнең тулы йөзеңне,*
*Ишетдем бән сәнең татлы сүзеңне.*
*Әгәр булса бу хәл берлә күрешмәк.*

*Кочаклашып тел чоындин үбешмәк.*
*Әвәл күрдем мөбарәк буйгынаңны,*
*Беләлмадым вә ләкин уйгынаңны», –*

дигән строфалар белән башлана. Мондагы беренче һәм өченче строфалар «Совет әдәбияты» журналының быелгы 5 нче санында (143 бит) «Беләлмадым» исеме белән басылган шигырьдә дә бар, тик андагысы да, мондагысы да бер-берсеннән бераз аерылып торалар: шигырьнең журналдагы варианты бөтенләй башкача яңгырашлы – аннан күтәренке, мәһабәт интонация ишетелеп тора, ә бу күчермәдәге редакциясендә язма әдәбияттагы традицион олылап эндәшү формасын (йөзләреңне – сүзләреңне, буйларыңны – уйларыңны) гадирәк, көнкүрештәгечә тыйнаграк формасы белән алыштырылуы

[1] Дудакларын – иреннәрен.
[2] Сәмыйг – тыңлаучы.
[3] Тәрәххем – рәхимлек, шәфкать.
[4] Заман хәл – хроник авырудай газап.

аркасында тәэсире бераз үзгәргән. Боларның кайсысы авторның үзеннән үк килә, кайсысы күчерүчеләр тарафыннан гына кертелгән – моны берничә нөсхә нигезендә генә анықларга мөмкин.

Күчермә шул рәвешчә дәвам итә:

*Сәңа хат язмакым гәрчә языкдыр,*
*Вә ләкин сүзең сәнен сөчекдер*[1],

*Нә булса да гаҗәп кыйлма сүземә,*
*Озын гомер ходай вирсен үзеңә.*

*Сәна яр улмага бәнем теләгем,*
*Сәне алмый басылмыйдыр йөрәгем.*

*Әгәр мән карасам сәнең йөзеңә,*
*Газиз җаным сәнең илә өзелә.*

*Сәне бәңа насыйр итсен, ходаем,*
*Кочаклашып ятыр идек, җаныем.*

*Бу хәлемне әйтә күрмә кешегә,*
*Сагыш кыйлып укыгыл үз дәрдеңә.*

*Төрле тавыш берлә сайрар асыл кош,*
*Ходай язган микән бәңа матур кыз.*

*Матур кызның көмеш йөзек кулында,*
*Егет җәмалы матур кыз куенында.*

*Тубылгы дик кызыл бәнем туры атым,*
*Исән микән җаникәем, канатым. /80/*

*Аласым язса иде, күрсәм иде,*
*Билең кочып, иренеңдин үпсәм иде.*

*Каләм әйтде: «Имдид язмагыл күп,*
*Абыстутай юлига күрмәгәй хуп».*

2б кәгазьдән башка үлчәмдәге, соңгы юлы *«Диеп сөйләр матур кызлар»* җөмләсе белән тәмамлана торган 5 строфалы шигырь китә. Мәсәлән, шулардан беренчесе:

*Чүсәнә, абзый, чүсәнә,*
*Кысыбрак яхшы сәүсәнә,*
*Күп сәүгәч күңлем улыр», –*
*дип сөйләр матур кызлар*[2].

Бу шигырьдән соң «тәмам» дип куелса да, шул сүзнең өстеннән үк Сахипҗәмалга багышланган шигырьләрнең баштагы ике строфасы күчерелеп китә. Ләкин Сахипҗәмал исеме, күчерүче гаебе беләнме, Хәбибҗәмал исеме белән алыштырылган.

3а кәгазь 2а кәгазьдә өзелгән шигырь үлчәмендәге юллар белән башлана:

*Йөзең күргәч дидем: «Әл-хәмд-*
*лиллаһ»,*
*Буең күргәч укыдым «Кол һү аллаһ»!*

*Каләм алдым – тагын азрак язасы,*
*Китә төшсен абыстутай мазасы.*

*Сәнең буең гаҗәп хәйран икәндер,*
*Ходай сәне бәңа язган микәндер.*

*Сәне анда, бәне монда яратты.*
*Арамызда олуг урам яратты.*

*Сәне бакча эчендә гөл яратты.*
*Бәне сайрамага былбыл яратты.*

*Сәнең сайрамакың дидар өчендер,*
*Бәнем сайрамакым син яр өчендер.*

Болардан баштан өченче һәм соңгы ике строфа «Совет әдәбияты»нда «Җаным корбаның улсын» исемендә бастырылган шигырь эчендә дә күренә, тик андагы мондагыдан бераз аерыла.

Басмада:

*Сәнең йөзең кояш дик нур икәндер,*
*Ходай сине миңа язган икәндер.*

Язмада исә беренче юлга рифмадаш булып «микәндер» сүзе килә. Бу күчерүченең хатасы гынамы, әллә шагыйрьнең,

[1] Сөчек – төче, тәмле. Сөчүк сүзең – тәмле телең.
[2] Бу шигырь Г. Кандалый шигырьләре дә кертелгән «Мәгъшукнамә» исемле кечкенә җыентыкта басылган. Казан, 1880. 28 б.

мәгъшукасының ходай тарафыннан аңа язылуына катгый ышанып әйтүдән бигрәк, икеләнеп, шөбһәләнеп әйтүеме – моны ачыклау кыен. Ике арадагы строфа да «Сән һәм бән» исеме белән бастырылган шигырьдә башкачарак яңгырый:

*Сәне анда, бәне монда яратты,*
*Бәне сәңа, сәне бәңа каратты*[1].

Күчермәнең бу битендәге һәм 2а кәгазьдә күчерелгән шигырьләр шагыйрьнең кайсыдыр мәгъшукасына багышланган озын, эзлекле, бәйләнешле шигырь текстының чәчелдекләре, чүпләндекләре булырга кирәк.

Шушы ук биткә соңгы юлы «Ятар микән матур кызлар» дип тәмамлана торган 5 строфалы шигырь урнаштылырган. Мисал өчен, шулардан икенчесе:

*Мендәр куеп күкрәгенә,*
*Кулын куеп беләгенә,*
*Түзә алмый йөрәгенә,*
*Ятар микән матур кызлар.*

3б һәм 4 кәгазьләргә Сахипҗәмалга багышланган шигырьләрнең башы һәм шуннан ук мужик тормышы-көнкүрешенең, шагыйрь карашынча, иләмсезлеген тасвир иткән өлешләре күчерелгән.

Бу дәфтәрчәнең соңгы битендә (4б кәгазь) «1869» датасы тора. Моны шигырьләрнең күчерелү елы итеп кабул итәргә мөмкин булса, бу дәфтәрчә Кандалый заманына якын торган күчермә буларак игътибарга лаеклы була ала. /83/ Бу дәфтәр Кандалый шигырьләреннән күңеле хушланган берәр шәкерт тарафыннан күчерелгән булырга кирәк, – дәфтәрнең рәвеше һәм язу почеркы шуны күрсәтә.

Дүртенче күчермә 1696 т (5686) номеры белән саклана торган 8×11 см зурлыктагы 10 кәгазьле җыентык эчендә. Инвентарьга һәм каталогка «Җыентык. 1 – Бәдавам китабы, 2 – Кызлар хаты» исеме белән кертелгән. Тәртипле күчерелгән җыентык булудан бигрәк, төрле вакытта төрле кешеләр тарафыннан язылган, тетелгән, таркау кәгазьләрнең теркәлмәсеннән гыйбарәт. Шушы теркәлмәгә «Бәдавам китабы» һәм бер бәет (суга баткан Рабигага карата чыгарылган), җир сату килешүе һ.б. күчерелгән кәгазьләр арасына элеге «Кызлар хаты» исеме белән телгә алынган 15×20 см зурлыктагы урталай бөкләнгән кәгазь кыстырып тегелгән. Бу кәгазь яны белән тора һәм шул уңайда гына укыла. Кәгазьнең уң һәм аскы кырыйлары тетелгән, шуңа күрә аскы өлешендәге язулары җуелган. Кәгазьнең өске ягына Сахипҗәмалга багышланган /84/ шигырьләрнең баштагы 4 строфасы күчерелгән,

*Сәңа җанкәм, догам итүем,*
*Догам илән сәлам итдем,*
*Сәламләрнең соңы, җанкәм,*
*Язып гозер кәлам итдем, –*

дигән юллар белән башлана. Шигырьнең «Фәвакиһ әл-җөләсаэ»-дә басылган нөсхәсе белн чагыштырып караганда, монда бераз үзгәлек күзгә чалына: беренче юлда «дога» сүзенә тартым кушымчасы ялганган. Калган строфаларда мәгъшуканы югары

[1] Совет әдәбияты, 1960. № 5. Б. 140.

стильдә сыйфатлый торган «гүзәл» сүзе гадирәк, көнкүрештәгечә тыйнаграк «матур» сүзе белән алыштырылган. Басмадагы «Түзәр хәлем дә калмады» юлы монда «Түзәр дә хәлем калмады» рәвешендә килә. Аннан соң, икенче күчермәдәге кебек, Кандалый шәхесенең үз җирләге белән генә бәйләнгән исемнәр, төбәк-җир атамалары гомуми төшенчәләрне тәгъбир итә торган сүзләр белән алыштырылган. Нәтиҗәдә икенче һәм өченче строфалар шундый рәвеш алган:

*Матур сән – илләрдә бер,*
*Күңелләргә яраудa бер,*
*Матур сән күз карауда бер,*
*Дәхи сөйләргә телләрдә.*

*Мәхәббәтең лә дәрдендин,*
*Сәнеңчөн сәнең артыңдин,*
*Сәнең илеңә вардым мин,*
*Елап-сыктап сәбилләрдә.*

Кандалый текстының күчерүче тарафыннан үзгәртелүе шигырьне башка мәгъшукаларга да тәкъдим ителерлек гомуми мәгънәгә ия булган рәвешкә китерү максатында эшләнгән булырга кирәк. Шушы ук хәл кәгазьнең аскы яртысында да күренә. Анда Фәрхисөрурга багышланган шигырьләрдән азактагы 4 строфасы күчерелгән. Монда «Фәрхи(сөрур)» исеме урынына «җаным» сүзе куелган:

*Та сәлам биргәнчә, и җаным сөрур,*
*Кан кеби буынларымда тик йөрер.*

*Сормыйсын лә, җаный, үткән кичәми,*
*Йоклыймынму, я сагышлап кичәми.*

*Йокламыймын, каплап алды сагышың,*
*Җанашым, җанашым, җанашым.*

*«Хатыма каршы хат бирсәң, бәне сәүгәнләрең хак булыр... Бәс, бу хатны мәсхәрә тарыйклаян язмадык, сәни алмак нияте берлә яздык... Аллаһы тәгаләдин өмид идеп язучы үзеңезгә...»* – дигән юллардан да моның бер егет тарафыннан сөйгәненә күндерелгән мәктүп булуы ачык беленә.

Кәгазьнең уң кырыена 2 гыйшкый халык җыры язылган. Теркәлмәдәге кәгазьләр арасында шушы хатның ертыклары да бар. Аларда да, халык җырлары белән беррәттән, Кандалый шигырьләре («Ятар микән матур кызлар») күчерелгән булган. Бу факт шагыйрь иҗатына караган шигырьләрнең халык күңеленә тирән керүе турында сөйли.

Сүз уңаенда шуны әйтеп китик: элекке вакытта егетләрнең мәгъшукаларына җибәрә торган бизәкле-чуклы гыйшык хатларына, еш кына, Кандалый шигырьләре кертеп җибәрелә торган булырга кирәк. Алар гашыйкның кичерешле хисси хатында халык җырлары белән бергә үрелгәннәр. Мәсәлән, бер гыйшык хатында:

*Кызарып чыккан кояшка,*
*Каршы барма – пешәрсән,*
*Бәне ташлап җатны сәүсәң,*
*Сикреп утка дөшәрсән, –*

дигән халык җырыннан соң, Кандалыйныкы икәне ачык беленеп торган шигырь /87/ килә:

*Әя җаным, кылыл алмам,*
*Ки сәндин гайрене алмам,*
*Насыйп булса сине алам,*
*Килермүсән бәңа, җаный*[1].

Гел шигырь белән генә язылган гыйшык хатларына

---

[1] Көнчыгыш кулъязмалары фонды. № 480 т (3103). 11а яки 7б кәгазь.

(Көнчыгыш секторында алар 20 гә якын) да Кандалыйныкылар кереп киткәләгән булырга кирәк. Мәсәлән, бер шигъри хатта Кандалый шигырьләрен хәтерләтә торган шушы юллар бар:

*Сәлам яздым, җаный, сиңа, каләм каш,*
*Бу серемне кешегә әйләмә фаш.*

*Күреп, җаный, сәнең зыйфа буеңны,*
*Беләлмадым вә ләкин һәм уеңны.*

*Бу җалнумы бер таш та белер иде,*
*Берәү булса кызганып килер иде*[1].

Хәер, болар һәм мондыйларның шагыйрьнең рухына, үлчәменә ияреп язылган булулары да бик мөмкин.

Бишенче күчермә алдагыларга охшамавы, сәерлеге белән аерылып тора. Кандалыйның Сахипҗәмалга багышланган шигырьләре күчерелгән бу бер табак кәгазь 234 ф (1544) номеры белән саклана торган фарсыча кульъязмага тышлык хезмәтен үти. 15×22 см зурлыкта 12 кәгазьле бу дәфтәргә Баһаветдин Гамилинең «Сәваних фи сәфәр әл-хиҗаз» исемле фарсыча әсәр күчерелгән. 12 кәгазьдә мелла Биккинә углы Мөхәммәтҗан тарафыннан 1848 елда күчерелүе күрсәтелгән. Тышлык кәгазь дәфтәргә очраклы гына элеккән булырга кирәк. Ул бик иске, саргайган, каралган, төрле май таплары сеңгән, таушалган. Бик җентәкләп караганда гына монда рус хәрефләре белән нәрсәдер язылуын аерып була. Кәгазьнең бу хәлдә булуы аның озын юл үтүе, шактый озак гомер кичерүе турында сөйли. Кәгазьнең чит-читләре тетелеп төшкән, шунлыктан шигырь юлларының баштагы сүзләре танылмый. Бит тәртибе, Европа-рус язу культурасындагыча, сулдан уңга таба бара.

Шигырь юллары битне урталай бүлеп торган ике багана рәвешендә күчереп төшелгән 1а кәгазь:

*Дигел Кандалга бер хәзрәт,*
*Сәңа гыйшкы төшеп кәсрәт,* –

дигән юл белән башланып китә һәм: /89/

*Тутам вар ди-ди уйнама,*
*Көтәр дип тә һич уйлама,*
*Ходачөн җанны кыйнама,*
*Сәхипҗәмал абыстайла,* –

дигән строфа белән тәмам була. 1б кәгазьдә шуның дәвамы китә.

Бу күчермәнең рәвешен күз алдына китерү өчен 1б кәгазьнең башындагы берничә юлының хәрефкә-хәреф күчермәсен китерик (…кәгазьнең тетелгән өлеше):

| | |
|---|---|
| …булъгулъегачемъболъ | Ябылъбылъсандугачемъ бул |
| …мъгагелаземъбуъ | Сахепъзамалъ Абестайла |
| …илаоемъкунемъ | Саненъилаконемътунемъ |
| …илатушемъ унемъ | Утадуръи Абыстайла |
| …ташлапъ ебарсанъ | Сане мотъекетъбашлапъ ебарсенъ |
| …гаръ Санъбане ташлапъ | Санеберъ мотекетъбашлапъ |
| …Ат чекарипъ фашлапъ | Хор итсенъи Абыстайла |
| …зенъ Алмасенъ | Салепдахедасалмасенъ |
| …ъ Лекендакалмасенъ | Куненътунендаеглайла |
| …надан мажекъ | Санабулдемъдебанъгашекъ |
| …масенъулъфасыкъ | Ярармешулъ Абыстайла |

[1] Көнчыгыш кульъязмалары фонды. № 480 т (3103). 2а–3а кәгазьләр.

Бу шигырьләрне К. Насыйри бастырган нөсхәсе белән чагыштырып караганда, монда кайбер үзгәлекләр күзгә чалына, шулай ук басмада булмаган берничә строфа бар.

Шушы үрнәктән күренүенчә, бу ниндидер тәртипле, эзлекле, эшләнгән язу түгел. Татар телендә дә, рус телендә дә бердәй әйтелешле авазлар, аеруча тартыклар шактый төгәл билгеләнсәләр дә, татар теленә генә хас авазларга карата моны әйтеп булмый. Бу авазлар рус телендәге аңа теге яки бу дәрәҗәдә якын аваз хәрефләре белән бирелгәннәр. Бу үзе билгеле бер кагыйдә белән, эзлекле рәвештә үткерелми, мәсәлән, бер ук строфада көнем сүзе күнемъ, конемъ рәвешләрендә язылган. «Бул» сүзе «болъ» һәм «булъ» формаларында кабатлана. «Һ» авазы «г» хәрефе белән «җ» «з» белән, «ң» авазы «н» хәрефе белән бирелә. Ул заманның искәлифтәге имласында ике вау хәрефе белән языла торган сүзләр «оу» тезмәсе белән бирелгән. Мәсәлән,

Еларсанъичениоупъ *(еларсән эчеңни уып)*
Келепъсорадыгаръелда *(килеп сорады һәр елда)* (2а кәгазь)
Елама и занекай ла *(елама и җаныкай ла).*

Сүзләрнең бер-берсеннән аерылмыйча язылуы да каләм иясенең язу культурасы чамалы икәнен күрсәтеп тора.

Күчерүченең кем булуы хакында төрлечә фараз итеп карарга мөмкин. Язуны керәшен татарга (әйтик, алар өчен махсус алфавит төзелгәнгә кадәрге дәвергә) нисбәт биреп булмый, чөнки аның фарсыча кулъязмага тышлык булып керүе шөбһәле хәл. Татар телен белгән рус кешесе белән дә нәкъ шул ук хәл. Татар телен гыйльми тикшергән, руслар өчен татар хрестоматияләре чыгарган рус галимнәреннән калган дияргә дә урын юк, чөнки бу грамотасыз, академик мохиттан ерак тора торган язу. Аннан соң кулъязманың көтепханәгә керү юлы да анык билгеле: Казан үзәк шәрык көтепханә-музеена Миргазиз Укмасый тарафыннан 1923 елда бүләк ителүе турында язу бар.

Язуның тышкы кыяфәте: «Бу татар язуында да, рус теле һәм рус язуында да аз-маз сукалый белә торган татар кешесе каләменнән чыкмадымы икән?» дигән уйга этәрә. Солдатта, туган җирдә читтән, рус арасында йөргән, аннан русның 32 хәрефен аера белеп кайткан кешенең буш вакытларда каләмен эшкә җибәреп каравы, каләмен күнекерү белән шөгыльләнүе, хәтта үз кирәкләре өчен кайбер нәрсәләрне я татарча, я рус хәрефендә күчереп куюы мөмкин булмаган хәл түгел.

Әгәр дә инде бу очракта Кандалый шигырьләре кебек җиңел аңлаешлы, җанга ягымлы, күңелне рәхәтләндерерлек күчергеч туры килгән икән, бу инде шагыйрьнең тәэсир итү көче турында сөйли.

Билгесез «писер» бик мавыгып күчергән. Күчергеч хезмәтен безгә билгеле булмаган ниндидер язма нөсхә (әлбәттә инде ансы татар язуында – искәлифтә булырга тиеш) үтәгән булырга кирәк. Күчерүче, югарыдагы үрнәктән

күреп киткәнчә, татар текстын рус хәрефләренә ярыйсы гына җаен белеп сала, урыны-урыны белән, үзе аңлапмы-аңламыйммы, хәрефкә хәреф күчерә. Мәсәлән, искәлифтә *әлиф, и, р* хәрефләре белән языла торган (сүз иске орфография турында бара) *ир* сүзе *айр* рәвешендә күчерелгән:

2а кәгазь:

*Газазилдик сөрелүбән*
*Китеп, булганда мәһҗүрә.*
*И тумачи буланмассән*
*Саваплы дәхи мәәҗүрә, –*

дигән строфа белән башлана.

Шигырьләрнең беренче кәгазьдә өзелгән строфа белән икенче кәгазьдә башланган строфа арасында К. Насыйри бастырган нөсхә буенча тагын да шигырьләр булырга тиешлеген искә алсак, бу бер табак кәгазьнең Кандалый шигырьләре күчерелгән бөтен дәфтәрдән кубып төшкән булуы хакында фикер йөртергә мөмкин.

2 кәгазьдә дә күчермәдә кайбер үзгәлекләр (шигырь юлларының саташтырылу, аерым сүзләрнең урыны алыштырылу) күренә. Боларның кайберләрен каләм иясенең язу культурасы, күчерү осталыгы түбән булудан килә дип карасак, бәгъзеләрен күчергечтәге төгәлсезлекләрнең кабатлануы дип карарга туры килә.

Күчермә:

*Бу сүзләрне сынап үзең*
*Мәгашең рәүнакын бозсаң,*
*Китәлмас никадәр сузсаң*
*Миңа «кил» ди-ди кул гына, –*

дигән строфа белән өзелә.

Бу күчермә XIX гасыр урталарыныкы булырга кирәк.

Әдәбият тарихчылары тарафыннан Кандалыйныкы итеп карала торган шигырьләр төрле язма китапларның өстәмә кәгазьләрендәге язулар арасында да очрый. Мәсәлән, 621 т (3740) номеры белән саклана торган «Гыймад әл-ислам» исемле язма китапның 1 кәгазенә, 1866 елга караган хроник истәлекләр һәм төркичә шигырьләр белән беррәттән, соңгы вакытта «Аерма» исеме белән басылган шигырь күчерелгән. Шул ук шигырь 1973 елгы шигырьләр җыентыгында да бар.

1487 т номерлы «Мөхәммәдия» китабының беренче кәгазендә Кандалыйның шушы билгеле строфасы тора:

*Әя җаным, абыстаем,*
*Кызыл алмам, тулан аем,*
*Сәнең өчен кышын-җәен,*
*Сызып агыла җөрәк маем.*

Әдәбият тарихчылары тарафыннан Г. Кандалыйга нисбәт бирелә торган шигырьләр 2119 т (3122) номеры белән саклана торган дәфтәр эчендә дә бар. Дәфтәрдәге шигырьләр «Бәйте әүвәл» исеме астында шушы строфалар белән башлана:

*Аһ бәнем шум хәлгымчөн*
*Тугмакың ай гөл газар.*
*Күрмәк өчен гөл йөзеңне,*
*Гаҗиз улдым бикарар.*

*Йөрер ирдем бер вакытта*
*Карьяңездә көндезем*
*Сәрви кад сурәтеңи*
*Күрде шул дәмдә күзем…*

Бу шигырьләрдә дә мәгъшуканың гүзәл сыйфатлары тасвирлана. Шигырьләрнең үлчәмендә халык җырларына һәм Кандалый поэзиясенә хас җиңеллек сизелә:

*Дөшем эчрә күредм сәни,*
*Буйларың – бәдәнең зыйфа,*
*Йөзеңә нәзар улдым*
*Һай җаным кыйлдым фида*

*Шул сәбәптин күрмәклеккә*
*Арзу кыйлдым бән сәне,*
*Күрдем ирсә кыйшык дәрде*
*Ирешде бәнем сары, –*

дигән строфа белән бу дәфтәрдәге шигырьләр өзелә.

Кандалыйга нисбәт бирелә торган шигырьләрнең күчермәләре 1973 номерлы язма шигъри җыентык эчендә дә очрый.

Көнчыгыш кулъязмалары секторындагы җыентыклар эчендәге әлегә һичкем тарафыннан өйрәнелмәгән шигырьләрнең кайберләре форма ягыннан да, эчтәлек җәһәтеннән дә Кандалый шигырьләрен хәтерләтәләр. Аларның Кандалыйныкымы, әллә бүтән шагыйрьләрнекеме икәнлеге ышанычлы чыганаклар нигезендә генә ачыкланырга мөмкин. Шундыйлардан, мәсәлән, 540 т (3201) номеры белән саклана торган җыентыкның 41–42 кәгазьләрендә күчерелгән шигырьне күрсәтергә була. Шагыйрь бер кызга мөрәҗәгать итеп, аңа галим иргә чыгуның кирәклеге турында сөйли. Шигырьдә галим ир белән булган тормышның рәхәтлеге бөтен ваклыклары белән гәүдәләндерелә:

*Дәер: «Җаный» тиз ук торса,*
*Самавари пархан кыйлса,*
*Кәтереп янмыза куйса,*
*Дәер бикәгә: «Әй җаный».*

*Бери-беринә кул салып,*
*Самаварга кул салып,*
*Ки чәйнеккә чәен салып,*
*Гыйшрәт кыйлса һәр ани*

*«Кушылдырды бези мәүла,*
*Китер чәй – балини алга*
*Куең һәм сән өстәлгә*
*Эчәек бик хозур ани»*

*Утырып икесе анда,*
*Самаварны алып алга,*
*Сузарлар кулларын балга,*
*Ки мәндин яхшысы кана...*

(41б кәгазь)

Рухы белән дә, тел-стиле белән дә бу нәкъ Кандалый. Шагыйрь мәгъшукасының наданга баруын теләми, хәтта, наданга барырга батырчылык иткән хәлдә, каргыш сүзләрен яудырудан да тартынып тормый. Шигырь:

*Нә мәгъкулдән хәбәр кәлсә,*
*Атаң бирмәгә кыйлса,*
*Мөһеренә милйун салса,*
*Аны кабул кыйлып алма.*

*Мөләем дәгелә барсаң,*
*Барып ташпулата керсәң,*
*Мәхәббәтсез билә торсаң,*
*Суган булыр сиңа алма, –*

дигән строфа белән өзелә. Бу шигырь билгеле мәгъшукаларга җибәрелгән хатларданмы, әллә башка бер мәгъшукага багышланганмы – анысы алдагы эзләнүләр нәтиҗәсендә генә ачылуы мөмкин. Үлчәме белән дә, рухы белән дә Кандалыйны хәтерләтә торган шигырь 1262 т (4816) номеры белән саклана торган дәфтәрдә дә, 649 т (3949) номерлы җыентыкта да бар (69а кәгазь). Көнчыгыш кулъязмалары секторындагы Г. Кандалыйга бәйләнешле әһәмиятле күчермәләр хәзергә әнә шулар. Әлбәттә, болардан башка да төрле җыентыклар эчендә, китапларның өстәмә кәгазьләрендәге төрле язулар арасында Кандалый шигырьләре очравы мөмкин. Әмма

хәзергә билгеле кадәресе генә дә шагыйрьнең халыкта киң таралуы, популярлыгы турындагы төшенчәләребезне киңәйтергә ярдәм итә, шигырьләрнең текстын аныклау буенча эшләүчеләргә – текстологларга материал бирә. Тагын да тулырак күчермәләрнең табылуы бигрәк тә әһәмиятле булыр иде.

Гомумән, Көнчыгыш секторындагы кулъязмалар арасында Кандалый шигырьләре шактый күп очрый. Дөрес, бер генә очракта да авторның күрсәтелмәве, күчерелү вакытының куелмавы болардан мәгълүмат алу эшен бераз кыенлата. Ләкин, язу үзенчәлеге, кәгазеннән чыгып, аларның нигездә XIX гасырның урталарына, II яртысына караударын билгеләп була.

Бу күчермәләр шигырь текстлары туплау, тикшерү белән шөгыльләнүчеләрнең кулга алырлык материалларын киңәйтәләр. Боларны һәм кулъязмалар эчендәге башка шигырьләрне җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә Кандалыйның һәм шулай ук элгәреге башка шагыйрьләрнең тагын да зуррак, тулырак, мәгълүматлырак җыентыкларын чыгарырга мөмкин булачак.

*Текстны басмага әзерләде:*
***Әлфрид Кашаф улы Бостанов,***
*Санкт-Петербургтагы Европа университетының тарих факультеты профессоры*

## Ф.К. САГДЕЕВА, Д.Р. ГАЙНАНОВА. ТАТАРСКИЙ КОНЦЕПТ КАК ОБЪЕКТ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО АНАЛИЗА

«Лингвокультурологик анализ объекты буларак татар концепты» («Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа». Казань, 2017. 248 с.) монографиясе 2017 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында нәшер ителде. Хезмәтнең авторлары – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гомуми тел белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ф.К. Сәгъдиева һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының чит телләр кафедрасы өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты Д.Р. Гайнанова. Фәнни редакторы – филология фәннәре докторы, профессор, академик М.З. Зәкиев, рецензентлары – филология фәннәре докторы, профессор И.Б. Бәширова, филология фәннәре докторы, профессор Л.К. Бәйрәмова.

Монографиянең исеменнән аңлашылганча, ул тел белеменең актуаль юнәлешләреннән саналган лингвокультурология мәсьәләләренә һәм аның төп категорияләренең берсе – концептның эчтәлеген ачуга багышлана. Бүгенге көндә әлеге терминнар татар филологлары тарафыннан да еш кабатлана, әмма аларның нәрсә аңлатуын без яхшы беләбез дип әйтә алмыйбыз. Хәзерге вакытта бу юнәлештә күп хезмәтләр языла, аерым мәктәп оешты дип әйтелә. Шуңа да карамастан, лингвокультурологиянең метод-методологиясе, терминнары, аның өйрәнү объекты тулысынча өйрәнелгән дип әйтеп булмый.

Китапны укып чыккач, аның авторлары куелган максатларына ирешкәннәр дигән тәэсир кала. Биредә лингвокультурология, концепт төшенчәләре җентекләп аңлатыла. Эш барышында билгеле бер система сакланып, күп кенә фәнни хезмәтләргә анализ ясала, аларга карата тәнкыйди фикер белдерелә, күпсанлы терминнар җентекләп аңлатыла, әлеге өлкәдәге яңалыклар күрсәтеп барыла.

Аерым алганда, монографиядә тема итеп алынган проблеманың куелышы һәм чишелеше аерым бер парадигма итеп каралырга тиеш, дигән фикер алга сөрелә. Мәгълүм булганча, хәзерге лингвистикада фәнни концепцияләр берберсен тулыландырып торучы өч парадигманы хасил итәләр: 1) чагыштырмалы-тарихи, 2) таксономик (системалы-структур), 3) антропоцентристик (когнитив). Бүгенгә кадәр татар тел белемендә фәнни тикшеренүләр чагыштырмалы-тарихи һәм системалы-структур планда алып барылды. Хәзер исә когнитив юнәлешкә күчеш бара. Монографиядә, иң беренче чиратта, нәкъ менә әлеге моментка игътибар бирелә һәм «концепт» дигән күренеш әлеге парадигма кысаларында аңлатыла.

Бүгенге көндә «Нәрсә ул концепт?» дигән сорауга галимнәр төрлечә җавап бирә: һәр телдә стандарт, гомуммәгълүм концептлар бар, концепт ул – төшенчә, концепт ул – лексема, концепт ул – символ һ.б. Монография авторлары, әлеге мәсьәләнең төрле телләрдә ничек тикшерелүен өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә киләләр: «...вопрос об изученности концептов до сих пор остается нерешенным, что в свою очередь обуславливает актуальность данного направления в лингвистике» (б. 9) һәм алга таба татар теле материалында «Акча» концептының өйрәнелешен тәкъдим итәләр.

Хезмәттә концептларны өйрәнүнең фәнни нигезләре «Теоретические аспекты исследования» дигән беренче бүлекнең «Концепт как проблема лингвокультурологии» һәм «Лингвокультурологическая модель концепта» исемле ике бүлекчәсендә җентекләп анализлана. Аларга кадәрге өч бүлекчәдә лингвокультурология фәненең фәнни аппараты, эчтәлеге, терминнары ачыклана, кешеләрнең әйләнә-тирә чынбарлыкны танып белүдәге тәҗрибәсен концептуальләштерүнең лингвокультурологик проблемалары күрсәтелә, аларның төрле авторлар тарафыннан ничек хәл ителүе ачыла. Биредә төрле хезмәтләрдә әйтелгән фикерләр дә тиешле урынында күрсәтелә бара. Мәсәлән, шәхеснең дөньяны танып белүен – дөньяны күзаллау системасын билгеләүдә милли тел картинасының шул телдә чагылыш табуы, яисә «Владение языком, предполагает владение концептуализацией мира, отраженным данным языком» һәм «Язык выступает как способ создания и преобразования мысли» дигән фикерләрнең мөһимлеге ассызыклана, ягъни адәм баласының дөньяны кабул итүе, хәтерендә калдыруы аның туган теле аша тормышка ашырыла. Нәкъ менә әлеге мәсьәләләр лингвокультурология фәненең теоретик нигезен тәшкил итәләр. Бу юнәлештә тел гомумкогнитив механизм буларак карала. Культурологик концептлар – әйләнәтирә дөнья күренешләрен концептуальләштерү нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, һәм ул тел берәмлекләренең мәгънә компонентларында чагылыш таба. Нәкъ менә шул нигездә фикер һәм тел күренешләре, телне өйрәнә торган фәнни тармаклар үзара берләшә һәм керешеп китә. Аерым алганда, лингвокультурологиягә караган тикшеренүләр тел һәм культура, аларның кулланылышы һәм өйрәнелеше системасы бирелгәнгә таянып башкарыла. Болар үзләре кеше феноменына, аның аң-фикерләренә, чынбарлыкны ничек күрүенә, инанушануларына һәм әйтеп бирү үзенчәлекләренә нигезләнә. Әлеге юнәлештә, язма текстларның телен өйрәнгәндә «тел шәхесе» (языковая личность) һәм «автор образы» (образ автора) дигән төшенчәләр файдаланыла. Димәк, лингвокультурология фәне үз эченә тел белеменең әдәби әсәрләр телен өйрәнә торган тармагы терминнарын да ала, аларны үзенә кирәк булганча тулыландыра. Үз чиратында, «тел шәхесе»

(языковая личность) дигәндә, автор әдәби әсәр кысаларындагы теге яки бу күренешне тасвирлаганда, тел берәмлекләрен файдалану үзенчәлекләре белән бергә, аның когнитив лингвистикага караган төшенчәләрен, идеяләрен күздә тотып, дөньяны күзаллау системасын, чынбарлыкны ни рәвешле аңлавын да игътибарга алырга тиеш була.

Алга таба лингвокультурологик тикшеренүләрдә милли һәм мәдәни яссылыкка караган факторларның әһәмияте ассызыклана. Нәкъ менә әлеге күренешләр концептның нигезен тәшкил итәләр дә инде. Хезмәттә концептлар ике төргә бүлеп карала: универсаль (фәлсәфи) һәм милли мәдәният категорияләре (мәдәни концептлар). Авторлар фикеренчә, мәдәни концептлар, халыкның аңында урын алган күзаллаулар һәм стереотипларга нигезләнеп, телдә сүзләр, фразеологик берәмлекләр һәм паремияләр ярдәмендә чагылыш табалар. Биредә алар фәнни кулланылышка тел белән мәдәниятне үзара бәйләп торучы ачкыч сүз (ключевое слово) төшенчәсен кертеп җибәрәләр.

Йомгаклап әйткәндә, хезмәттә фәнни чыганакларга анализ ясау нәтиҗәсендә лингвистика өлкәсенең эчтәлеген ачыклаган төп лингвокультурологик төшенчәләр һәм атамалар билгеләнеп, аларның эчтәлеге ачылган. Бу алар арасындагы иерархик бәйлелекне, үзара бәйләнешләрне билгеләргә мөмкинлек биргән. Нәтиҗәдә лингвокультурология фәне, аның фәнни аппараты, эчтәлеге, методологиясе ачыклана, татар теле материалында концептка анализ ясауның үрнәге күрсәтелә («Акча» концепты мисалында). Шуның белән бергә, әдәби язма истәлекләрнең телен өйрәнүче белгеч буларак, кайбер фикерләргә ачыклык кертү кирәк дип саныйбыз. Концептның лингвокультурологик моделе анализланганда аң-фикерләү, мәдәният өлкәләренә күбрәк игътибар ителеп, тел ягы читтәрәк кала кебек. Ул беренче бүлекнең алтынчы бүлекчәсендә урын ала һәм биредә сүзнең мәгънәсе турында гына сүз бара. Шуның белән бергә, хәзерге вакытта сүзнең мәгънәсе, аның типлары җитәрлек дәрәҗәдә аңлатылып бетмәгән дигән фикер дә әйтелә. Нәкъ менә әлеге мәсьәлә ачыклык кертүне сорый да инде. Лингвокультурология фәне яссылыгыннан караганда, ул, мөгаен, шулайдыр, әмма сүзнең, тел берәмлеге буларак, мәгънәсе һәм аның типлары хәзерге фән таләпләренә таянып, гомуми тел гыйлемендә ячтыртылганча, бик җентекләп, объектив нигездә аңлатыла һәм ул чынбарлыкка туры килә дип санала.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

## Д.Б. РАМАЗАНОВА. ТАТАР ТАРИХИ ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕНӘ МАТЕРИАЛЛАР

Соңгы вакытта филология фәннәре докторы, профессор Дария Бәйрәм кызы Рамазанованың татар лексикологиясе өлкәсенә караган берничә китабы дөнья күрде: «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» (Казан, 2013, 364 б.), «Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре» (Казан, 2014, 287 б.), «Татар тарихи лексикологиясенә материаллар» (Казан, 2016, 412 б.). Алар татар теленең сүзлек байлыгын, аның үсеш тарихын өйрәнүдә әһәмиятле хезмәтләр булып торалар.

Мәгълүм булганча, телнең лексикасын тарихи аспектта өйрәнү – зур көч куюны сорый торган эш. Д.Б. Рамазанованың «Татар тарихи лексикологиясенә материаллар» китабы нәкъ менә шул рухта башкарылган. Галим татар теле лексик фондының формалашу процессын төрле чорларга (ностратик, бабаалтай, монгол, бабатөрки, борынгы төрки) бүлеп өйрәнә.

Хезмәтнең беренче бүлеге ностратик лексикага багышлана. Автор ностратик телләргә түбәндәгеләрне кертеп карый:

1. Һинд-европа гаиләсе телләре (һинд, иран, славян, балтыйк, герман, кельт, роман, грек, албан, әрмән).
2. Урал гаиләсе (фин-угор, самодий төркемнәре) телләре һ.б.
3. Семит-хәмит (афроазиат яки афроазия) гаиләсе телләре. Бу гаилә бик күп тел төркемнәреннән һәм аерым телләрдән тора. Шулардан төрки телләргә туры мөнәсәбәте булганнары – гарәп һәм иврит телләре.
4. Алтай гаиләсе (монгол, төрки, тунгус-маньчжур төркемнәре) телләре.
5. Картвель гаиләсе (картвель, абхаз-адыг, дагыстан һ.б.) телләре.
6. Дравидий гаиләсенә Көньяк Азия субконтиненты халыклары телләре карый (Рамазанова, 2016, б. 23).

Әлеге телләр турында язганда Д.Б. Рамазанова күп кенә тарихчы һәм телче галимнәрнең хезмәтләренә мөрәҗәгать итә. В.М. Иллич-Свитычның телләрнең барысы өчен дә уртак булган меңгә якын сүз һәм грамматик элементлар ностратик чорда ук булган, дигән фаразын билгеләп үтә (Иллич-Свитыч В.М. Опыт сравнения ностратических языков (семитохамитский, картвельский, индоевропейский, уральский, дравидийский, алтайский). Т. I. М., 1971. с. 370; Т. II. М., 1976. с. 156; Т. III. М., 1984. с. 135). Алар кеше һәм аның көндәлек эшчәнлеген, табигый шартларны белдерәләр. Мәсәлән: *карын, куен, тел, ал, яка, кисү, кору, бору/борау, чалу, моң, ир, килен, кода* һ.б.

Шуның белән бергә, автор ностратик сүзлектә канкардәшлекне белдерә торган сүзләрнең бөтенләй теркәлмәгәнлегенә, туганлык атамаларыннан бары тик никахлашу туганлыгын белдерә торган сүзләр генә кертелүенә игътибар итә (*kälu* (килен), *küda, herä/ēr* һ.б.) (б. 50–51).

Матди мәдәният, табигать белән бәйле сүзләрдән ул түбәндәгеләрне күрсәтә: *büri* (хәзерге татар телендә *бөркәнчек, бөркәү* сүзләренең тамыр формасы), *majλ* (бал), *qoti* (ут, очкын), *taph<a>* (тап(т)ау), *bur(h)ʌ* (бур), *dalq/u/* (дулкын), *külä* (күл), *Ḳirʌ* (кар) һ.б. (б. 57–65).

Әйтергә кирәк, Д.Б. Рамазанованың хезмәтендә ностратик сүзлектә (Иллич-Свитыч, 1971, 1976, 1984) теркәлгән һәм татар теле белән уртак булган лексемаларның бер өлеше генә китерелә. Бередә шуны да искәртеп үтү урынлы булыр, ностратик характердагы лексемалар, фонетик күренешләр бүген дә табыла тора һәм ностратик телләрнең саны да арта бара.

Хезмәтнең икенче бүлеге бабаалтай чорына багышлана. Ул үз эченә безнең эрага кадәрге дәвернең X – VI меңьеллыкларын ала. Д.Б. Рамазанова Алтай чоры уртаклыгына шулай ук шактый күп мисаллар табылуын (Н.А. Баскаковта – 118, Ж.Г. Киекбаевта – 22, А.Х. Нуриевада – 21, Э.Ф. Ишбердиндә – 113 сүз) күрсәтеп уза. Болардан тыш, А.В. Дыбо, И.Г. Добродомов, К.М. Мусаев, Р.Г. Әхмәтьянов, А.М. Сәгыйтова һ.б. күп кенә галимнәрнең хезмәтләрендә бу җәһәттән бай материал бирелүен ассызыклый (б. 86–92).

Галим алтай телләре берлеге чорына карый торган лексиканы барлау юлында борынгы төрки тел, тунгус-маньчжур һәм монгол телләре өчен уртак булган, шушы өч төркемнең барысында да табыла торган сүзләргә мөрәҗәгать итә.

Кешенең тән төзелеше белән бәйле сүзләр тотрыклы, чит телләр йогынтысына бирешми торган лексик төркемне тәшкил итәләр. Хезмәттә кеше белән бәйле 250 ләп сүз тикшерелгән, шуларның 217 се гомумалтай чоры лексикасы булуы мөмкин дип фаразлый автор (б. 92–118). Карап чыккан сүзләрнең бер өлеше ностратик сүзлектә теркәлгән.

Д.Б. Рамазанова алтай чорында туганлык атамаларыннан ностратик *küda* сүзе *кода* һәм *кияү (күдәгү)* сүзләренә аерылган дигән фикерне уздыра, моның өчен ул татар диалектлары материалына мөрәҗәгать итә (б. 122–123).

Ул шулай ук көнчыгыш телләре белән уртаклык семантик параллельләрдә дә табылуын күрсәтә. Мәсәлән, *бармак* сүзенең килеп чыгышын ‘кул белән тотып алу, эләктерү’ мәгънәсендәге *бар* фигыленнән (ул монгол телендә әле дә кулланыла) килеп чыккан дип санйылар. Шундый ук мәгънә күчеше башка телләргә дә хас: маньчжур телендә *дай* ‘тотып алу, алу’, шуннан *дала* ‘кул’ сүзе ясалган; корея телендә *ка-* ‘алу’, *карак* ‘бармак’, ягъни *бармак* сүзенең нигез мәгънәсе ‘тотып алу, эләктереп алу’ семаларын белдерә торган лексемаларга кайтып кала (б. 140).

Шул ук вакытта кайбер алтай телләрендә *бармак* сүзе *тармаклану* семасы нигезендә барлыкка килгән. Мәсәлән, бабаалтай телендәге *дар* – ‘тармаклану’, *дармак* ‘бармак’, *чар* – ‘тармаклану’, *чарбу* ‘беләзек’; монголларда *сарба* – ‘тармаклану’, шор телендә *сарбаш* – ‘бармак’ (б. 140) һ.б.

Охшашлык *атсыз бармак* сүзендә дә күзәтелә: эвенк телендә *ач гэрбэлэ,* маньчжур телендә *гэбу аку симхун,* якут телендә *ӑтасуох*, алтай телендә *атыйак,* русча *безымянный* сүзләре барысы да ‘аты юк, атсыз’ дип тәрҗемә ителәләр (б. 142). Шундый характердагы уртаклыклар *көнбагыш, чәнчә бармак, борын, аяк* һәм башка сүзләргә дә хас. Әлеге күренешләр алтай телләре арасында уртаклыклар булуын дәлилли, дип яза автор.

Хезмәтнең өченче бүлеге татар-монгол янәшәлекләренә багышлана. Төрки һәм монгол телләре бер-берсеннән Алтай берлеге чорында безнең эрага кадәр IV меңьеллыкта аерылганнар дип санала. Алар арасындагы уртаклыклар хәзергә кадәр сакланып киләләр. Д.Б. Рамазанова татар телендәге татар-монгол янәшәлекләрен түбәндәге төркемнәргә бүлеп карый.

1. Себер ареалы татар сөйләшләрендәге татар-монгол янәшәлекләре: *саң* ‘йола, гореф-гадәт’; *торбаҡ* (бараба сөйләшендә), *торбок* (калмак сөйләшендә) ‘тана бозау’, ‘бер яшьлек тана’; *терәкә* ‘ефәк, йон тукыма’, *йала* ‘кикрик’; *конан, конаҗын* ‘өч яшьлек тай яки сыер’; *ҡойон* ‘өермә’; *тагым* ‘тез асты’; *сантала* ‘урындык’ һ.б.

2. Себер–Урал ареалында очрый торган татар-монгол янәшәлекләре: *булжал* ‘вакытны билгеләү, сүз куешу, срок’; *сагыдак* ‘шөпшә’; *савдак* ‘җәя’ (алтай, хакас телләрендә); *дулана* ‘дүләнә’; *коча* ‘тәкә’; *им-том* ‘өшкерү’ (том сөйләшендә), шуннан *томар* ‘амулет’ һ.б.

Татар сөйләшләрендә киң таралган татар-монгол янәшәлекләре: *чыба* ‘хатын-кызлар кия торган чигүле киндер җилән’ (керәшен, мордва-каратай сөйләшләрендә); *чупа* ‘хатын-кызлар кия торган чигүле, ак күлмәк’, *чуба* ‘яңгырда кия торган плащ’ (монгол телендә); *шыва тон* ‘җәйге милли халат’(тыва телендә) һ.б.

Гомумән татар әдәби телендә яшәп килә торган татар-монгол янәшәлекләре: *язау* ‘ябык, арык’, *ядара* ‘ярлылану’ (тыва телендә); *дадай* ‘фәкыйрьләнү, бөлү’ (якут телендә); *мәргән* ‘төз атучы’, *мәргә* ‘оста булу’ (алтай телендә) һ.б. (б. 159–173).

Хезмәтнең дүртенче бүлеге бабатөрки чорга багышланган. Бабатөрки чор дигәндә, төрки бабаларыбызның, монголлардан аерылып, мөстәкыйль үсеш-үзгәреш кичерә башлаулары күздә тотыла (әлбәттә, бу чор шартлы рәвештә фаразлана, ди автор). Төркиләрнең барысы да бер чорда формалаша башлаган дип әйтеп булмый. Галимнәрнең күпсанлы тикшеренүләреннән аңлашылганча, төркиләрнең аерым төркемнәре шул чорда ук булганнар: америка индеецлары, шумерлар, этрусклар, скифлар, хетлар, аланнар, болгарлар һ.б. Автор бу телләр турында, аларның лексик байлыгын туплаучы галимнәрнең (Ф.Р. Латыйпов, Ф.Р. Кляшторный, О. Сулейменов һ.б.) хезмәтләреннән кызыклы мәгълүматлар бирә. Аерым алганда, әлеге чорга караган сүзләрдән мисаллар китерә. Мәсәлән, этрусклар телендә үк яшәгән сүзләр: *es* ‘күз’, *el* ‘кул’,

*heśe/ceśe* ‘кеше’, *cileś* ‘кылыч’, *table* ‘табын’, *hara* ‘кара’ һ.б. (б. 222); хетт телендәге сүзләр: *atta* ‘ата’, *it* ‘үт (фигыль)’, *ais* ‘авыз’, *sal* (женщина) – төрк. *coly* (< сылу) хатын-кыз’, *qaisy* ‘кайсы’ һ.б. (б. 229–230); скиф сүзләре: *acy* ‘ачы’, *kainos* ‘каенана’, *qurčaq* ‘курчак’, *baqyr* ‘бакыр’, *inä* ‘ана’ һ.б. (б. 237); алан телендәге сүзләр: *memr* ‘тимер’, *kisi* ‘кеше’, *joq* ‘юк’, *őssa* ‘үссә’, *mes* ‘җиз, бакыр’, *bag(q)a* ‘бага, карый’ һ.б. (б. 243).

Китапның бишенче бүлеге бабаболгар һәм Болгар чоры лексикасы буенча материалларны барлауга багышлана. Кайбер галимнәр, болгарлар Идел–Урал буйларында безнең эрага кадәр IV меңьеллыкта ук яшәгәннәр, дигән фикер үткәрәләр.

Д.Б. Рамазанова борынгы болгар чоры лексикасын барлау юлында Ф.Р. Латыйпов, Ф.Ш. Фәттахов, Р.М. Кадыйров һ.б. галимнәр хезмәтләренең әһәмиятлелегенә басым ясый. Аларда протетик авазлар турында да материаллар бар, бу исә протезаның, чуваш телендә генә түгел, башка борынгы телләргә дә хас булганлыгын, аның алынма сүзләрне үзләштергәндә әһәмиятле роль уйнаганлыгын күрсәтә.

Автор татар телендә болгар сүзе дип каралган лексик берәмлекләрне шактый таба; М. Кашгарый, Р.Г. Әхмәтьянов, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, К.М. Мусаев, А.В. Дыбо һ.б.ның хезмәтләреннән, аеруча Р.Г. Әхмәтьяновның этимологик сүзлекләреннән мисаллар туплый. Бу өлкәдә Болгария галимнәренең (М. Москов, И.В. Шишманов, И.Г. Добродомов һ.б.) эзләнүләре кызыклы, алар бабаболгар суперстратын барлауга юнәлтелгән дип ассызыклап үтә.

Хезмәтнең алтынчы бүлеге борынгы төрки чорга багышлана. Биредә Д.Б. Рамазанова «Древнетюркский словарь» (1969) буенча борынгы төрки чор белән татар әдәби телен чагыштырып, үзенең күзәтүләрен тәкъдим итә һәм, нәтиҗәдә, татар теле лексикасының VIII–XIII гасырларда ук формалашканлыгын ача. Бүлектә кайбер сүзләргә кыскача аңлатмалар бирелә, кайберләренең диалектларда гына сакланганлыгы күрсәтелә. Аерым туганлык атамалары һәм йола сүзләрен тагын да тирәнрәк аңлату җитми кебек, чөнки бу китап тарихи лексикология дигән катлаулы фәнгә кереш буларак язылган хезмәт.

Билгеле булганча, «Древнетюркский словарь» VII–XIII гасырларны үз эченә ала. Әмма соңгы тикшеренүләр нәтиҗәсе буенча борынгы чорның вакытын бераз чикләргә мөмкин, ди автор һәм борынгы төрки чорны VIII–X гасырлар белән чикләп буладыр дигән фикерен дә белдереп уза (б. 279).

Хезмәттә сыйфатлар, саннар, алмашлыклар һ.б. буенча кызыклы күзәтүләр китерелә. Мәсәлән, күп кенә татар сөйләшләрендә әдәби телдәге *миңа/сиңа, минем/синең* алмашлыклары *мәңа/мага, сәна/сага, сәнең, мәнең* дип әйтелә (б. 293). Бу борынгы әйтелешләр белән дә бәйле булырга мөмкин, ди автор. Борынгы төрки телдә *beni* – мине, *beniŋ* – минем, яки *seniŋ* – синең формала-

ры булган. Татар теленең пермь сөйләшендә *минеңдән* – миннән, *сәнеңдин* – синнән, *минеңдә* – миндә дип сөйләүләр дә борынгы төрки телдә булганнар һ.б.

Хәзерге вакытта [*ы*], [*е*] сузыкларына тәмамлана торган сыйфатлар борынгы төрки телдә -*(ы, е) г* кушык авазы белән теркәлгәннәр: *катыг* – каты*, ысыг* – эссе, *йылыг* – җылы, *сарыг* – сары һ.б.

Борынгы төрки телдә кайбер сүзләрнең тамырлары гына чагылган: *сы* – сындыру, *jig* – җегерләү, орчык, *čïp* – чыбык, *tal* – талак, *öz* – үзәк, *tom* – томау, *sa-* – санау, *uz* – оста, *čït* – ситсы (б. 298) һ.б. Шушы ук рәттә кайбер борынгы төрки сүзләрнең хәзерге телгә килеп җитмәве дә күзәтелә: *qïrmačï* – столяр, *küvük* – салам, *salčï* – пешекче, *тизи tizig* – мәрҗән, *sarïm* – сөзгеч (саркыту, димәк *сар* тамыры булган) һ.б. (б. 301).

Хезмәттән күренгәнчә, хәзерге татар теленең төп лексик фонды борынгы төрки телдә үк формалашкан. Гомумән алганда, китапта татар теленең лексикасын тарихи планда тикшерү өчен мул материал тупланган. Ул, татар теле лексикасының тарихы белән генә түгел, гомумтөрки лексиканың формалашуы белән шөгыльләнүчеләр өчен дә кызыксыну уятырлык.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2018 елның 16 гыйнварында** күренекле татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, педагог, Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулды. Юбилей уңаеннан Татарстан Милли музеенда галимгә багышланган түгәрәк өстәл оештырылды, «Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның мирасы» дигән темага күргәзмә ачылды. Күргәзмә ачылышында Татарстан Диния нәзарәте вәкилләре, Татарстан Милли музее фәнни хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты галимнәре, укытучылар, язучылар, китапханәчеләр һәм башкалар катнашты.

Күргәзмәдә Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты фондларында саклаучы ядкәрләр урын алды.

**2018 елның 16 гыйнварында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Татарстан Республикасының халык рәссамы Михаил Кузнецов күргәзмәсе ачылды. Күргәзмә ачылышында Россиянең атказанган рәссамы Г.Л. Эйдинов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р.М. Сәлахов, Татарстанның халык шагыйре Р.М. Миңнуллин, «Казан» журналының баш мөхәррире Ю.А. Балашов катнашты. Татарстанның халык артисты, Башкортстанның атказанган артисты Рөстәм Маликов курайда халык көйләрен башкарды.

**2018 елның 31 гыйнварында** Яшел Үзән муниципаль районы 5 нче гимназиясендә XV республикакүләм Ризаэддин Фәхретдин укулары үтте. Укуларга Татарстанның 26 районыннан 160 мәгариф хезмәткәре чакырылган иде.

Барлыгы 4 секция утырышы оештырылды. Чарада Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Х.Й. Миңнегулов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары О.Р. Хисамов, Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире И.Г. Гомәров, танылган язучылар һәм шагыйрьләр Галимҗан Гыйльманов, Ленар Шәехов, Рифат Сәлахов һәм башкалар катнашты.

Укуларда катнашучылар Ризаэддин Фәхретдин хезмәтләренең бүгенге көндә дә актуаль булуын, укытучылар, тәрбиячеләр тарафыннан системалы рәвештә белем бирү һәм тәрбия процессында кулланылуын билгеләп үттеләр.

**2018 елның 2–3 февралендә** Россия Фәннәр академиясенең Тел гыйлеме Институтында (Мәскәү шәһәре) Россия тюркологлары комитетының еллык утырышы узды. Утырышта Хакасия Республикасы, Татарстан Республикасы, Төмән өлкәсе галимнәре катнашты. Сессияләр вакытында татар, башкорт, ногай, карачай, кумык, хакас, тыва филологиясе, шулай ук төрки халыклар тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре дә каралды.

Татарстан Республикасын әлеге чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының

фәнни эшләр буенча урынбасары О.Р. Хисамов тәкъдим итте. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының эшчәнлеге белән таныштырды.

**2018 елның 6 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Татар теле: зур электрон тупланма «TATZET» платформасын ачу һәм тәкъдим итүгә багышланган чара узды.

«Татар теле: зур электрон тупланма “TATZET” платформасы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Гамәли семиотика институты һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итә торган башка оешмалар тарафыннан эшләнгән электрон проектларны үз эченә ала. Платформа гуманитар юнәлештә фәнни эшчәнлек алып баруны җиңеләйтү, эш өчен заманча инструментарий булдыру, шулай ук тел, әдәбият, сәнгать белән бәйле фәнни материалларны интернет челтәре аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерү максатларын күз алдында тота. Әлеге платформа фәнни хезмәткәрләр, дәүләт органнарында эшләүчеләр, укытучылар, студентлар, укучылар һәм киң катлам татар теле мәсьәләләре белән кызыксынучыларга юнәлтелгән.

Чара кысаларында татар теле сүзлекләренең электрон фонды, татар матур әдәбияты корпусы, «Туган тел» татар гомумтел корпусы, Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогы, татар сөйләме синтезаторы, Microsoft Office, Microsoft Windows, Android, iOS операцион системалары өчен татарча локализация пакетлары һәм башка проектлар тәкъдим ителде.

**2018 елның 11–13 февралендә** Болгар ислам академиясендә I Халыкара Болгар укулары узды. «Россия мөселман халыкларының дини мирасы» дип исемләнгән чарада Россия һәм чит илләрдән галимнәр, иҗтимагый-сәяси һәм дин эшлекләре, югары дини һәм дөньяви уку йортлары студентлары һәм укытучылары катнашты. Делегатларның саны 100 дән артык иде.

Чарада катнашучыларны Болгар ислам академиясе президенты Камил Исхаков, Республика мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин, Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев, Мәскәү Ислам институты ректоры, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы Дамир Мөхетдинов, Россия Федерациясе милләтләр эше буенча Федераль агентлыкның мониторинг, анализ һәм фаразлау идарәсе консультанты Валентина Лаза, Россия Ислам университеты ректоры Артур Сөләйманов һәм башкалар сәламләде.

Конференция барышында дини эчтәлектәге язма мирас үрнәкләрен ачыклау, тикшерү һәм фәнни әйләнешкә кертү, Россия мөселман халыклары дини мирасының дөнья мөселман өммәтенең фәнни һәм иҗтимагый тормышына йогынтысы, дини белем бирү оешмаларын укыту-методик әдәбият белән тәэмин итү өчен классик ислам текстлары үрнәкләрен реновацияләү һәм адаптацияләү мәсьәләләре, Россия исламының җирле интеллектуаль традицияләрен Якын Көнчыгыш идеяләре һәм практикалары белән чагыштырма аспектта өйрәнүнең методик нигезләре, заманча мәгълүмати технологияләрне исәпкә алып, гарәп телендәге һәм гарәп графикасындагы кульязма чыганакларны исәпкә алу һәм аларның каталогын төзүдә мәгълүмати тәэмин итү проблемалары каралды.

**2018 елның 13 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2017 ел нәтиҗәләре буенча йомгаклау конференциясе үткәрелде.

Конференция кысаларында пленар утырыш һәм дүрт секция эше оештырылды. Чыганаклар белән эшләү һәм текстология, татар тел гыйлеме, халык иҗаты һәм әдәбият, хәзерге заманда татар һәм Идел буе халыклары сәнгатен өйрәнүнең актуаль проблемалары буенча 60 тан артык фәнни доклад тыңланды.

**2018 елның 13–15 февралендә** Казанда татар язучысы һәм әдәбият белгече Гали Рәхим истәлегенә багышлап «Идел буе халыкларының традицион мәдәнияте» темасына IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Оештыручылар – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Республика традицион мәдәният үсеше үзәге.

Конференциядә Казан, Яр Чаллы, Уфа, Ижевск, Йошкар-Ола, Саранск, Ульяновск, Чебоксар, Симферополь, Сургут, Мәскәү һәм Баку шәһәрләре югары уку йортлары һәм фәнни үзәкләре вәкилләре катнашты. «Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәнияте», «Традицион мәдәниятне дисциплинара аспектта тикшерү», «Төрки халыкларның этник тарихы һәм традицион культурасы» темаларына секция утырышлары оештырылды.

**2018 елның 21 февралендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» темасына багышланган IX Халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде.

Конференция филология һәм культурологиянең үзара хезмәттәшлеге нигезендә туган проблемаларны һәм перспективаларны билгеләү, аерым фәннәрнең кисешү нокталарын һәм теоретик-методологик үзенчәлекләрен ачыклау, югары, махсус урта һәм гомуми урта белем бирү уку йортларында укучыларны кызыксындырган уртак мәсьәләләр буенча тәҗрибә уртаклашу максатында оештырылды.

Конференциядә Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Удмуртия, Саха (Якутия) республикалары, Пенза өлкәсе урта һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы укучы һәм студентлар, моннан тыш, Япония, Төркия, Кытай һәм Казахстан студентлары һәм магистрантлары катнашты.

**2018 елның 21 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2017 елда әзерләнгән һәм нәшер ителгән фәнни-гамәли басмалар тәкъдим ителде.

Әлеге чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, башка учреждениеләр һәм матбугат вәкилләре катнашты.

Институт тарафыннан 2017 елда барлыгы 69 берәмлек фәнни-гамәли басма әзерләнгән (тел гыйлеме – 16, әдәбият – 12, халык иҗаты – 5, сәнгать – 12, рухи мирас һәм чыганакчылык – 18, башка оешмалар һәм читтәге башка белгечләр белән берлектә эшләнгән хезмәтләр – 6).

**2018 елның 28 февралендә** Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Ибрай (Чәтрән) авылында күренекле татар язучысы, публицист, журналист Галиәсгар Гафуров-Чыгътайның (1867–1942) «Галинең алтмыш еллык истәлеге» дип аталган китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Китап Яңа Ибрай гимназиясенең тарих укытучысы, «Туган як музее» җитәкчесе булып эшләгән Шәүкәт Кәбиров башлангычында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәрләреннән филология фәннәре докторы З. Рәмиев, филология фәннәре кандидаты Л. Гарипова тарафыннан әзерләнгән.

Чара Аксубай муниципаль районы башлыгы К.К. Гыйльманов, авыл җирле үзидарәсе вәкилләре, районның тарих, тел, әдәбият укытучылары, китапханә хезмәткәрләре, матбугат вәкилләре катнашында узды. К. Гыйльманов, Ш. Кәбиров, З. Рәмиев, Л. Гарипова, Ә. Моратшин, С. Гатина, С. Зайцев, Г. Идиятова һ.б. чыгышларында Г. Чыгътайның татар мәдәнияте тарихында тоткан урыны, аның әле дөнья күрмәгән әсәрләрен барлап, яңа басмаларын чыгару турында сүз барды.

Очрашуның икенче өлешендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнеп, 2017 елда дөнья күргән «Г. Тукай. Энциклопедия» басмасы тәкъдим ителде.

**2018 елның 17 мартында** Яр Чаллы шәһәрендә «Ак мәчет» мәдрәсәсе тарафыннан «Җәмгыять тотрыклыландыруда ислам диненең әһәмияте» дигән темага III Халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде.

Пленар утырышта «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Болгар академиясе укытучысы Әбдерразак әс-Сәгъди, Словакия Республикасыннан «Кеше һәм аның хокуклары» гражданлык җәмгыяте рәисе Эмиль Хәмидуллин, Мәскәү лингвистик университетының фәлсәфи фәннәр кафедрасы мөдире Айдар Каюмов, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире Алмас Шәйхуллов, Россия Ислам институты ректоры, Болгар академиясе ректоры, сәяси фәннәр докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин, академик Мирфатыйх Зәкиев, филология фәннәре докторы Марсель Бакиров, тарих фәннәре докторы Айдар Хәбетдинов чыгыш ясады. Секция утырышларында дин һәм фән, белем бирү һәм тәрбия мәсьәләләре, ислам тарихы, дин һәм традицияләрнең үзара бәйләнеше мәсьәләләре каралды.

**2018 елның 21–25 мартында** Казанда беренче тапкыр Халыкара төрки кинофестивале узды. Фестивальдә Төркия, Казахстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Кыргызстан һәм Россиядән Татарстан, Башкортстан, Якутия, Хакасия, Төньяк Кавказ кинематографистлары үз иҗат эшләрен жюри һәм тамашачы хөкеменә тәкъдим итте. Төрки кинофестивале көннәрендә фильмнар «Мир» кинотеатрында күрсәтелде. Халыклар дуслыгы йортында иҗади очрашулар үткәрелде.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме
– аннотация (рус телендә)
– төп сүзләр (рус телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2018. № 1

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 21.03.2018. Басылды: 27.03.2018
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла



Г. Исхакый портреты. Рәссамы – З. Гыймаев.
Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры





Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Татар теле: зур электрон тупланма «TATZET» платформасын ачу һәм тәкъдим итү





Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2017 ел нәтиҗәләре буенча йомгаклау конференциясендә

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2017 елда әзерләнгән һәм нәшер ителгән фәнни-гамәли басмаларны тәкъдим итү



Г. Ибраһимов исем.  Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәре Г.Д. Юнысова IV Бөтенроссия фольклорчылар конгрессында



Кунакчыл Татарстан. Фрагмент



Казан ханлыгы



Шомлы еллар. 1998



Рәссам Александр Иванов



Таһир белән Зөһрә



«Шүрәле» әкияте буенча. 2011



«Су анасы» әкияте буенча. 2011



Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында
Татарстан Республикасының халык рәссамы Михаил Кузнецов күргәзмәсе ачылу



М. Кузнецов. «Ак киндер» сериясеннән «Бизәкле иртә». Киндер, майлы буяу. 120×110. 2004



М. Кузнецов. «Өйдә» сериясеннән «Бизәкләр дөньясы». Киндер, майлы буяу. 110×120. 2005

---

Яңа китаплар




